Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

04
апрель 2017
ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

«ИЛЧЕЛӘР»

Әзһәр Мөхәммәдиев

6 нчы бит

РАВИЛ ЗАҺИДУЛЛИН. «КАЗАНСУ БУЕНДА»

КАДЕРЛЕ, ГАЗИЗ ТАТАР ТӨБӘГЕ

24-25 мартта Казан шәһәрендә I Бөтенроссия татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр корылтае узды. Корылтай кысаларында төбәк тарихына багышланган китаплар күргәзмәсе, «түгәрәк өстәл» оештырылды, «Золотая Орда в мировой истории» исемле китап тәкъдим ителде. Чараның мөхтәрәм кунагы – армия генералы Мәхмүт Гәрәев булды. Төп оештыручы – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС

12 +

4 (279)

апрель 2017

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

100

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 *Мәхмүд Кашгари*

ТАРИХИ МИРАС

4 **Болгар. Сәхабәләргә һәйкәл**
6 **Илчеләр.** *Ә.Мөхәммәдиев*
16 **Югары мәдәниятне саклау юлында: Габделбари хәзрәт Исаев.** *Ә.Бостанов*
22 **Ислам галәменең казык йолдызы.** *Х.Вәлиәхмәтов*
26 **Әтрәч авылы тарихы.** *Э.Сәлахова*
31 **«Шимбәчеләр» түгәрәге**
32 **«МИНЕМ АВЫЛЫМ» иҗади һәм фәнни эзләнү-тикшеренү эшләре конкурсының нигезләмәсе**
34 **Финляндиядә татар әсирләре.** *Ч.Сафиулла*
40 **Заман геройлары.** *Х.Насыйров*

ДИНИ МИРАС

44 **Ислам дөньясы.** *Г.Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

50 **Кутадгу билик. (Котайткыч белем).** *Й.Баласагуни*
54 **Чыңгызханның ак болыты.** *Ч.Айтматов*
60 **Кабердән тавышлар.** *Х.Ушаклыгөл*
66 **Тукай фәне үсәчәккә өмет зур.** *Р.Рахман*
68 **Атачак таңнарга багышланган гомер.** *Ф.Сәйфуллина*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

76 **Ачы алма суты — ирендә...** *М.Талипова*
82 **Утлы кисәү.** *Л.Гыйльфанов*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

88 **Кәрим Тинчурин**

СӘНГАТИ МИРАС

90 **Сагыну.** *Р.Шаһиева*
94 **Апас ягы — курай ягы.** *Э.Каюмова*

82 **АЧЫ АЛМА СУТЫ — ИРЕНДӘ...**
Миләүшә Талипова



90 **САГЫНУ**
Розалина Шаһиева

96 Илче күчтәнәче. *Р.Вәли*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

100 Миллият сүзлеге. *А.Тимергалин*
101 Дөрес яза беләбезме? *Г.Бәширов*

ХӘТЕР САГЫНДА

104 Әлмән шәхесләре. *Ә.Кидрасов*
107 Казан сөлгесе. *Г.Җәләлова*
108 Курсада – Курсавига мемориаль истәлек.
110 Ядкярләргә – бер гасыр. *Р.Садыйкова*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

112 «Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1917 елның апрель ае.

114 МИЛЛӘТ ХӘБӘРЛӘРЕ

ШАЯН МИРАС

116 Каһкаһәле өч мәзәк һәм парча. *Г.Тукай*
117 Апуш бәрәңгесе. *Г.Гомәр*

118 «Безнең мирас» елъязмасы. *Апрель*

119 Мирасворд

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Марат Закиров
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-91)

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Заказ №А-777. Тираж – 1700 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 28.03.2017
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең
Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин төшергән, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Казансу буенда». Киндер, майлы буяу.
Р.Заһидуллин рәсеме

МӘХМҮД КАШГАРИ
(1028-1126)

***

Батыр яуда беленер, телчән дауда беленер.

***

Бер карга берлән кыш килмәс.

***

Бер төлкедән ике тире тунамыйлар.

***

Арыслан картайса, тычкан өнен күзәтер.

***

Ике тәкә башы бер казанга сыймас.

***

Бүрене бүре ашамас.

***

Карт үгез балтадан курыкмас.

***

Бии белмәгәнгә идән тар.

***

Көмешеңне кояшка куйсаң, аягыңа алтын иярер.

***

Пычак никадәр үткен булса да, үз сабын юынмый.

***

Ташны тешли алмасаң, үбәргә кирәк.

***

Табагачың озын булса, кулың көймәс.

***

Көч капкадан керсә, гаделлек ишектән чыга; көч ишектән керсә, гаделлек тишектән чыгар.

***

Киң тун тузмас, киңәшле акыл бозылмас.

***

Колын коега төшсә, бака айгырга әйләнер.

***

Агач киссәң, озын кис, чаба-килә кыскарыр; тимер киссәң, кыска кис, сугакилә озаер.

***

Ахмак булса да, дус яхшы, әйләнгеч булса да, юл яхшы.

***

Тал – сыгылуы белән, каен катылыгы белән яхшы.

***

Тегермәндә туган тычкан күк күкрәгәннән курыкмас.

***

Тел белән төенләгәнне теш белән чишә алмассың.

***

Төтен чыгарган үзе ысланыр.

*Текстны **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №4 апрель 2017

Болгар.Сәхабәләргә һәйкәл

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара.

Р.Габбасовның янә бер эше

2012 елның 18 июнендә «Изге Болгар җыены» кысаларында сәхабә җирләнгән урында сынчы һәм рәссам Рөстәм Габбасов проекты буенча эшләнгән истәлек билгесе ачылды. Истәлек билгесе өстенә арка корылган сигез почмаклы плитәдән гыйбарәт. Терәкләрендә Мөхәммәт пәйгамбәрнең өч сәхабәсенең исемнәре татар, рус, инглиз һәм гарәп телләрендә язылган. Ә билгенең үзендә чалма, юл таягы һәм каурый каләмнең рельеф сурәте ясалган. Татар тарихчысы Хисабетдин ибне Шәрәфетдин Әл-Мөслиминең «Тәварихы Болгария» китабында 681 елда Болгар тәхетенә Айдар хан утыруы турында риваять бирелгән. Аның буенча, Мөхәммәт пәйгамбәр үзенең өч сәхабәсен – Габдрахман ибне Зөбәерне, Тальха ибне Госманны, Зөбәер ибне Җәгъдәне табиблар сыйфатында Болгарга җибәргән. Зөбәер ибне Җәгъдә, пәйгамбәр (с.г.в.) биргән юл таягына таянып, бу җирдә тәүге тапкыр вәгазь укыган. Унике елдан соң ике сәхабә Мәдинәгә кире кайткан. Ә Җәгъдә исә, хан кызы Туйбикәгә өйләнеп, Болгарда калган. Риваятьтә язылганча, ул соңыннан Ханнар төрбәсе төзелгән урында җирләнгән. ■

ИЛЧЕЛӘР

Әзһәр Мөхәммәдиев

Унбашы киез ишекне каерып керергә ярагангылыгын белдерү белән, тылмач һәм Бибарс эчкә уздылар. Түшәмдәге кечкенә төнлектән тирмәгә якты төшсә дә, Бибарс бертын берни дә күрми торды. Күзләре күнеккәч, түрдә төрекмән паласы җәелгән тәбәнәк юл сәкесе өстендә кыска аякларын баскычка куеп утырган зур вә түгәрәк тәкәббер йөзле, таза гәүдәле, урта яшьләрдәге кешенең Сүбәдәй баһадир икәнен абайлады. Аның артында тирмә киезенә бизәкле көмеш кыналы кәкре кылыч, ә аның янында ук тулы садак һәм җәя эленгән. Җирдә күннәре бизәүле ияр ята. Ә уң якта җыйнак кына тәбәнәк өстәлгә кымыз тулы чүлмәк һәм савытлар куелган. Ят кеше кергәнне күргәч, Сүбәдәй баһадирның ике ягында утырган нойоннар, сүзләрен бүлеп, тынып калдылар.

Тылмач алгарак чыкты һәм Сүбәдәй баһадир каршысына барып, ике тезенә дә тезләнеп монголча нәрсәдер әйтте. Бибарс аның сөйләгәненнән бары үз исемен һәм «болгар» дигән сүзләрне генә аңлады. Сүбәдәйнең карашы, юк-бар эш белән мәшәкатьләнергә мәҗбүр булган кеше йөзе буларак, караңгыланды. Ул уң ягында утырган кытайлыга охшаган кеше белән ни турындадыр киңәшеп алды. Аннары тотрыклы тавыш белән тылмачка карап сорау бирде:

– Болгар әмире Чыңгыз каган җибәргән хатны алмадымы әллә?

Тылмач сорауны тәрҗемә иткәч, остазы өйрәткәннәрне исенә төшереп, Бибарс, илчеләрдә кабул ителгәнчә, уң тезенә тезләнде һәм башын иеп сәлам бирде, сәламәтлек теләде.

– Алды, әфәндем. Шуңа күрә дә, дуслык белдерү йөзеннән, мине баз[1] илчесе итеп җибәрде дә.

– Шулай булгач, нинди илчелек турында сүз булырга мөмкин? Әгәр әмир киләчәктә Болгар иле белән хакимлек итәргә уйлый икән, ярлык сорап минем янга түгел, ә Чыңгызхан катына барып баш орсын!

Сүбәдәй баһадир янында утырган нойоннарына нәрсәдер әйтте һәм тегеләре көлештеләр. Аннары ул уң ягында утырган кытайлыга каерылып:

– Елюй әфәнде, юл ярлыгы язып бир. Илчеләр Чыңгызхан урдасына барсыннар. Мин бары тик каганның нойоннарыннан берсе генә һәм миңа мондый дәүләтара сәяси эшләрне башкару йөкләтелмәгән, – диде.

Ул, кулын ишарәләп, кабул итү беткәнлеген һәм чыгып китәргә ярагангылыгын аңлатты. Әлеге кытайлы урыныннан кузгалды. Бу – Чыңгызхан хезмәтенә күчкән, тумышы белән кытайлы, мәгълүм Елюй Чу-цай иде. Аны монголлар Елюй яки озын сакаллы булганга Урту – «озын» дип кенә йөртәләр иде. Ул күркәм ак йөзле, юка озын сакаллы, какча гәүдәле, утыз биш яшьләр тирәсендәге кеше булып, башына чуклы кара башлык кигән иде.

Елюй Чу-цай, кабул итү йоласын җиренә җиткерү теләгеннән чыгып булса кирәк, крәч чынаяк тутырып Бибарска кымыз салып бирде. Аның эчеп бетергәнен көтеп торды да, аннары үзе белән ияртеп алып чыгып китте.

Чыгып, беркадәр баргач, Бибарсны Сүбәдәй тирмәсеннән кечерәк һәм гадиерәк бер тирмәгә алып керде. Бусы аның үз тирмәсе иде булса кирәк.

Ахыры. Башы 1 нче санда. «Илчеләр» – «Чынгызхан хәйләсе» әсәренең чираттагы бүлеге.

[1] Баз – тынычлык.

– Тамагыгыз тукмы, карыныгыз тулымы? – дип сорады ул чиста төрки телендә, үз яныннан, зур булмаган сәкедән урын күрсәтеп.

Кичә көндез ашаганнан бирле тамак ялгаганы булмаса да, моның шул рәвешчә, кытай гадәте буенча, исәнлек-саулык сорашу гына икәнлеген Бибарс төшенде.

– Рәхмәт, тамагының рәте килер. Менә Чыңгызхан янына бару бик үк килешеп бетми. Без бит Болгар әмиренең хезмәтчеләре генә. Буйсынган кешеләр. Әмирдән мондый күрсәтмә алмадык. Сүбәдәй баһадир белән яңадан аңлашып булмасмы?

– Кабат сөйләшү мөмкин түгел. Монгол нойоннары, хәрби кеше буларак, кат-кат сөйләшкәнне яратмый. Күк йөзе астында яшәгән кешеләр хәзерге вакытта бер генә хөкемдарга – Чыңгызханга гына буйсына. Ярлыкка килгәндә исә, аның кирәге булмас. Мин монда вакытлыча гына... Бер-ике көннән үз кешеләрем белән Туранга Чыңгызхан янына юл тотачакмын. Юлдашың белән миңа гына ияреп барырсыз.

– Чыңгызхан урдасы кай урындарак, ерак урнашканмы? Төркичә бик чиста сөйләшәсез. Ничек өйрәндегез?

Елюй елмаеп куйды. Ул Чыңгыз каган басып алган җирләрдәге халыкларның көнкүрешен, гореф-гадәтен, тарихын өйрәнеп, «Си-ю ли» – «Көнбатышка сәяхәтнамә» дигән китабын язып бетереп килә. Шуңа күрә дә болгарлар турында бөртекләбрәк сораштырмакчы иде. Баксаң, илче егет үзе үк артык кызыксынучан кеше булып чыкты.

– Хан урдасының кайда урнашканлыгы турында әйтермен һәм күрсәтермен дә. Монда сер юк. Без барыбер шунда барачакбыз.

– Яхшы, әфәндем.

– Кайбер нәрсәләр турында миңа үзең сөйләсәң иде, егет. Мәсәлән, болгарлар авылларда яки шәһәрләрдә яшиме, ягъни утрак тормышлымы, әллә күчмә халыкмы, гореф-гадәтләре ничек, нинди бәйрәмнәре бар? Болгар шәһәре зурмы, кай җирдә урнашкан – боларның барысы да мине кызыксындыра.

Бибарсның ни дип әйтергә дә белми торуын күреп, ул:

– Син борчылма. Бу мәгълүматлар миңа патша хезмәте өчен түгел, ә гыйльми хезмәт өчен кирәк! – диде. Аннары болай да кысык күзләрен тагын да кыса төшеп, хәйләкәр елмаеп, җентекләбрәк Бибарска карады.

– Синең турыда, егет, мин болай да беләм, үз фикерем бар. Бәлки әйтергәдер?

Тәне эсселе-суыклы булып китсә дә, Бибарс тыныч кына җавап бирергә көч тапты:

– Белсәң, әйт, Елюй әфәнде.

– Җиту чәчеңә, зифа буеңа карап фикер йөрткәндә, син сабан артыннан йөреп, иген игеп үскән болгарлы түгел, ә кыпчак егете. Үзең артык яшь күренәсең, димәк, ат өстендә озак чабып, тиз урап кайтырга дип җибәрелгәнсең. Шуның өстенә зиһенле генә түгел, тыйнак һәм сөйкемле дә күренәсең...

– Бәлки мин олуг бер түрә улыдыр? – диде Бибарс, көлеп. Ул Елюйның чынлап та акыл иясе булуына инанган иде һәм аңа карата ихтирамы артты, ләкин саклыгын югалтмаска тырышты.

– Эш күреп үскән кулың һәм таза иңсәләрең башка нәрсә турында сөйли. Яшь булсаң да, астына кереп, шәп аргамакны күтәрә аласың. Хуҗага ярарга тырышкан һәм аңа хезмәт күрсәткән нөкәрләргә гадәттә мондый сыйфатлар хас түгел. Димәк, сине илче итеп җибәрүдә катнашкан кеше...

– Аргамак күтәреп караганым юк, Елюй әфәнде, сора, нәрсә кызыксындыра сине?!

– Кече Болгар белән Бөек Идел Болгары арасында нинди уртаклык бар?

– Кече болгарлар моннан биш йөз ел чамасы элек Дунай елгасы буена күченгәннәр һәм анда император динен һәм телен кабул иткәннәр. Шуңа күрә, исемнәре бер булса да, җисемнәре, ягъни телләре һәм диннәре башка.

– Ә Каф болгарлары?

– Каф болгарлары – исемнәре белән дә, телләре белән дә Идел болгарлары белән бер халык.

Елюй Чу-цай, шулай уртак телдә сөйләшә алырдай фикердәш тапканына эчтән генә куанып, әңгәмәне өзәсе итмичә, озак кына сөйләшеп утырды.

– Соравыңа килгәндә исә, – диде ул әңгәмә төгәлләнгәндә, – бу кадәресен син яхшы беләсеңдер инде илче буларак, Туранны бөтенләе белән басып алганнан соң, Чыңгызхан үзенең Алтын Урдасы[2] белән хәзер без барасы Талас һәм Чу үзәнлегендә сугышчыларын ял иттерә һәм үзе дә ял итә...

– Ул Һиндстанга яу чабарга җыена икән, дип ишеткән идек...

Елюй Чу-цай болгар илчесен ни өчен бу мәсьәлә борчыганын аңлады. Чыңгыз басып керүдән курка болгарлар, хәер, дөрес куркалар... Менә бишенче ел инде ул аңа хезмәт итә, каган хезмәтендә. Аның мәгънәсез ерткычлыгыннан гарык булынган. Шунысы кызык, каган моны үзе вәхшилек дип санамый. Киресенчә, башка илләрне, халыкларны авыр шартларда үткән яшьлеге өчен гаепле дип саный. Шуңа күрә дә аның яу чабуы, «Көнбатыш тарафны җәзага тарту», дигән шигарь белән атала да. Чыңгыздан да олуг һәм акыллы хөкемдар юк, мангул нойоныннан да батыр нойон юк, дип, төкерекләрен чәчеп, үз-үзен мактаган мангул нойоннары масаюына, тешен кысып, көчләп елмаеп: «Әйе, әйе», – дип килешеп өйрәнгән Елюй Чу-цайның күңеле киңлек теләде. Үзе белән уртак тел табарга омтылган бу билгесез бер егеткә барысын да җентекләп сөйләп, аңлатып бирәсе килде. Ләкин, ни кызганыч, бу һич тә мөмкин түгел иде...

– Еллар буе бертуктаусыз яуда булган нойоннар талчыккан. Хан үзенең төп көчләре белән ял итә. Ә Чабә белән Сүбәдәй – ат казанган чирү башлыклары. Элмәләре артык ишле булмаса да, нойоннары тәҗрибәле һәм җитәрлек. Алар Гыйракны һәм Кыпчакны тапаламыйча туктамаячаклар, чөнки Чыңгызханның теләге белән ул: «Көнбатыш тарафны җәзага тарту», – дип атала. – Бәлки Болгарга да җитешерләр. Әгәр дә урысларның көчләрен тиз арада җимерсәләр...– дип өстәде ул.

Куелган шартлар буенча, Чабә белән Сүбәдәй элмәләренең берләшеп Болгарны җимерергә тиешлеген ул, әлбәттә, белә иде, тик: «Бар белгәнеңне дә дошман илчесенә сөйләп бирергә ярамый бит инде!» – дип уйлап, эченнән генә көлеп куйды, чөнки аңлаган кеше өчен, болай да артык күп сөйләде.

– Җик патша Чыңгызханга баш оруга карамастан, Болгарга да бәреп керерләрме?

– Баш ору мангулча «мөргүкү» дип атала һәм бу йоланы тулысынча башкару өчен патшагыз Чыңгызхан урдасына бик күп һәм төрле-төрле бүләкләр алып барып, аның бусагасы төбендә ике тезенә дә тезләнеп, кулларына таянган хәлдә маңгаен җиргә терәп, үтенеп, идарә итү өчен ярлык кәгазе сорарга тиеш... Әгәр дә хан аның бүләкләреннән канәгать булса, үз тирәсендәге язу таныган уйгырлардан бер ел идарә итәргә ярлык – рөхсәт яздырып бирер.

– Төрле сәбәпләр аркасында, патша, баш ору йоласын тулысынча башкара алмаса, нинди чара кала?

Елюй Чу-цай мизгел эчендә бер ноктага текәлеп уйланып алды.

– Тарихта андый очраклар да билгеле. Төньякук исемле акыл иясе турында ишеткәнең юкмы? Чыгышы белән ул да сезнекеләрдән, төркиләрдән.

Бибарсның ишеткәне юк иде.

– Менә шул бер чара кала, – диде Елюй Чу-цай, хәйләкәр елмаеп.

Ул арада нindидер нойон килеп, Елюйны каядыр чакырды. Елюй Чу-цай үз телендә хезмәтчесенә нәрсәдер әйтте дә, Бибарска көтеп торырга кушып, чыгып китте. Бераздан ул әйләнеп керде, ләкин йөзе шактый караңгыланган иде. Моны күреп, Бибарс чыгарга җыенды.

– Яхшы, әфәндем, аңлашылды. Сүзләрегезне мин әмиргә алып кайтып тапшырырмын.

– Кайтырга яраса...

---

[2]Алтын Урда – хан ыстаны.

Бибарсның борчулы карашына җавап итеп, ул:

– Әйе, әйе. Сүбәдәй-баһадир икегезне дә аның кул астындагы кыргыз ярдәмче көчләренә нөкәр итеп билгеләргә куша. Әмма сөенечле хәбәр дә бар. Мин аны, шулай да, сине үз вазифаңны үтәү нияте белән миңа иярте, Чыңгызхан урдасына җибәрергә күндердем, – диде.

– Ә Тәкин?

– Үзеңнең ычкынып китә алуыңа куан, егет. Мине һәрдаим синең кебек егетләрнең беркатлы булуы, мангул нойоннарының холкын аңламаулары гаҗәпкә калдыра... Биредә исәп һәрвакыт баш хисабына бара. Ә баш исән булса, үзең беләсең, башлык табыла...

***

Бары берничә көннән соң гына, тәбәнәк кенә җөннәпәс монгол көчетенә[3] атланган Бибарс, Елюй Чу-цай төркеменә ияреп, көнчыгышка таба юл тотты.

Егетнең күңелен сагыш һәм борчулы уйлар чорнап алды. Тәңре аның ялгыз башын тагын үзе теләмәгән һәм бөтенләй билгесез бер якка җибәреп, тычкан белән уйнаган мәче кебек, язмышы белән уйный иде.

Елюй Чу-цай үз яраннары белән Хәзәр диңгезенә карап юл тотты. Диңгезгә якынлашып килгән көннәрнең берсендә Бибарс үзенең юл тирмәсен көйләп куеп, кичтән үк кереп ятты, ләкин йоклый алмады. Бу кадәр юллар гизеп Болгарга кайтасы урынга, Туранга таба юл тоту һич тә аның ниятенә туры килми иде. Тик качып китәргә дә мөмкинлек юк, чөнки йөз нойоны белән Елюй Чу-цайны озата барган йөзбашы Хорхосунның бертуктаусыз үзен күзәтүен тоя. Каравылчылар исә төннәрен аеруча дикъкать белән атларны бер тирәгә җыйнап саклыйлар, ә атсыз килеш өстәл кебек тигез һәм киң далада үзен тиз тотып алачакларын ул бик яхшы белә иде.

Шулай уйланып ята торгач, йоклап киткәнен дә сизми калды. Караңгы, ерак-ерак йолдызлы төн урнашты. Төн урталарында тартылган тирмә киндеренә нәрсәдер килеп бәрелгән тавышка сискәнеп уянды. Кыр чикерткәсе дип уйлап, ул аңа игътибар да итмәде. Бераздан шул ук тавыш тагын кабатлангач, моның кемнеңдер вак таш атуы икәнлеген абайлап, сикереп торды һәм акрын гына тирмәнең изүен чишеп, тышка чыкты. Ерак түгел генә чокырдан калкып торган камышлык буенда кеше гәүдәсен төсмерләп, аңа таба атлады. Якынайган саен йөрәге ешрак тибүен тойды һәм әлеге кешенең Тәкин чауш икәнлеген аңлап алгач, кочагына ташланды.

Якындагы тирмәдән кемнеңдер чыккан шәүләсен күреп, икесе дә җиргә чүгәләделәр, ә әлеге кеше «эш»ен башкарып кереп киткәч, ул каравылчыларның берсе иде булса кирәк, вак һәм сак адымнар белән йөгереп китеп бардылар.

Куе камышлык буйлап озак кына йөгергәннән соң, Тәкин чауш Бибарсны иярле тышаулы пар ат янына алып килде. Ул аларны алдан ук хәстәрләп куйган иде, күрәсең. Атлар баш калкытып борылып алдылар да, камышлы күл буендагы сусыл үләнне умырып ашауларын дәвам иттеләр.

Бераз тын алгач, Бибарс Тәкин чаушка карады. Караңгы булса да ул аның елмаюын тойды.

– Синең Сүбәдәй этләреннән котылуыңа шат мин, – диде ул, һаман да сөенечен баса алмыйча.

– Мин дә сине эзләп таба алуыма шат... Тик менә тирмәдә барлык әйберләрем калды, – диде ул пошынып.

– Башың үзең беләнме? – дип сорады Тәкин чауш, көлеп. – Баш сау булса, башлык табылыр. Ике көн инде сиздермәскә тырышып, сезнең арттан калмыйча киләм. Тирмәң янына якынаерга һич тә җаен китереп булмады.

[3] Көчет – кыска буйлы кыр аты.

– Ничек, мангул чирүе ошадымы соң үзеңә?

– Гаҗәеп тәкәббер кешеләр. Алардан да кыю, алардан да көчле кеше юк. Сүбәдәй кыргызларының ничек коралланган булуын игътибар белән күзләдем. Ук башлары беркадәр үзгә итеп эшләнсә дә, калганы, нигездә, шундый ук, бездәге кебек. Ә менә усаллыкның, явызлыкның чиге юк.

– Аларның көче дә шунда.

– Ярар, таң ата башлаганчы ычкыныйк. Караңгыда юл алып калу тиеш. Җәйге төн кыска. Үзең беләсең, мангуллар, сизенеп алгач, үзеңне эзләп җирнең астын өскә китерми калмаслар.

***

...Илчеләр, кояшта көйгән Кыпчак даласы буйлап көне буе атларын куганнан соң, кинәттән генә Идел ярына килеп чыкканнарын сизми дә калдылар. Аста – текә яр итәгендә талгын гына агып яткан елганы күреп, Идел-Йортка кайтып җитүләренә куандылар.

– Идел буйлап күтәрелсәк, тизрәк ямга җитәр идек тә, ял иткән көр атларга менәр идек, – диде Бибарс, үзенең уйларын белдереп.

– Ашыкмаган – арыслан тотар, каударланган – тычкан да тотмас, ди мәкаль. Безгә тизрәк Иделнең аръягына чыгып, эз югалтырга кирәк. Мангуллар «тәңре бирмәде» дип ята торган халык түгел. Дала бетереп эзлиләр алар хәзер сине, ә Идел буенда һич югында бер унлыклары булса да аңду да тора булыр.

– Шулаен ул шулай, – диде Бибарс, яр астына төшәрдәй урын эзли-эзли. – Тик игътибар иттеңме икән: Елюй Чу-цай үзенең кешеләре белән Магулистанга Тимер Капуг[4] аша түгел, ә Хазәр диңгезе тирәли юл тота. Бары бер Хорхосун йөзлеге белән ул, берәүдән дә курыкмыйча, сәяхәтен дәвам итә. Димәк, биредә Чыңгыз хан ягына авышкан азгын әмирләр бар.

– Булмас. Саксин әмире Басман – Сүбәдәйгә каршы сугышкан кеше. Мангуллар андый эшләрне кичермиләр.

– Һәр кабиләнең башбаштак үз әмире була. Алар һәммәсе дә Басманга буйсынмыйлар шул.

Идел ярының убылып иңкүләнгән урынын табып, атларын аска алып төштеләр. Талчыккан һәм сусаган атлар яр буендагы комлыктан тиздән суга кереп, озак итеп су эчтеләр.

– Беркадәр юл озыная инде, – диде Бибарс, баягы сүзен дәвам итеп һәм Тәкин чауш белән килешеп. – Хорхосунга эләксәк, исән калдырмас. Имин генә кайтып җитеп, йөкләтелгән эшне башкару тиеш. Мин каршы түгел.

Алар, өсләрен салып, киемнәрен төреп, ияр элмәгенә бәйләделәр дә, тезгеннәрен ычкындырмыйча, омтылып-омтылып йөзгән атларының ияр каешына тотынып, аргы якка чыгып киттеләр. Елганы кичкәннән соң, комлы сөзәк ярдан менеп, куак һәм ат биеклеге камыш белән капланган уйсулыкка юнәлделәр.

Идел тамагын тәшкил иткән Бәхтимер, Болга, Бүзән кебек елгалар арасындагы унар чакрымга сузылган чытырманлы урганлыклар, куаклар, билдән югары үлән белән капланган, кеше аягы басмаган күл буйлары, уйсулыклар Тәкин чаушны таңга калдырды.

– Биредә, чынлап та, мангул эзәрлекләвеннән качып, яшеренеп озаклап ятарга була икән, – диде ул.

– Атаклы Җидесу үзәнлекләре шушы инде. Язын аларны су баса, ә җәен мул булып печән уңа. Агынты тулы балык һәм киек кош-корт була. Сөйләүләре буенча, Хәзәр башкаласы Итил дә каядыр шушы тирәдә булган. Хәер, кайберәүләрнең әйтүенчә,

[4] Тимер Капуг – Дербент.



«Бачман»*. К.Нәфыйков рәсеме

Саксин шәһәре шул Итил үзе булса кирәк. Борынгылар, Идел җитмеш тармак булып диңгезгә коя, дигәннәр...

Илчеләр Иделнең бу ягында табигатьнең бөтенләй үзгә булуына игътибар иттеләр. Аръяктагы вак дала әреме һәм чәнечкеле дөя үләне белән капланган, уттагы табадай көйгән дала урынына биредә күз күреме җиткән елгага якын һәр җирдә яшел үлән, төрле-төрле дала чәчәкләре белән капланган киң үзәннәр, тугайлар, өсләрендә акчарлаклар очкан куе камышлы күлләр һәм вак-төяк агынтылар җәелеп ята иде.

Актүбәнең чираттагы борылышында Бибарс зур бер өянке төбендә иярдә торган атларны һәм яшь ирләрне күреп, аларның тоткаклар[5] икәнлеген абайлады. Киемнәренә караганда да болар мангул тоткаклары түгел иде. Якынрак килгәч, ул аларга ихтирам белән сәлам бирде. Каратут йөзле, таулыларны да, күчмәләрне дә хәтерләткән төз һәм матур гәүдәле бу егетләр Җидесуның җирле халкы иде.

– Сез кем җайдаклары буласыз? – дип сорады ул алардан.

– Басман бийнеке без. Ә сез үзегез кемнәр буласыз? – дип сорады үз чиратында яхшы коралланган таза гына унбашы.

– Без – Болгар илчеләре.

– Рәхим итәсез, әфәнделәр, без сезне көтәбез.

Бибарс аны шаярта дип аңлады. Унбашы янында торган җайдакка нәрсәдер әйтте. Тегесе исә аты янына барып тезгенен чиште дә, сикереп атланып, каядыр чабып китеп тә барды.

– Басман бий үзе кайда?

Тоткак гаҗәпләнебрәк карап торды.

– Сез, әфәндем, бернәрсә дә белмисез ахры?

– Гаҗәп тә түгел, без – юлдан гына...

– Яшенсуккан авылы янында барлык Җидесу йорты аксакаллары җыены бара. Төрле яклардан халык шунда җыелган. Бар да шул турыда гына сөйли.

– Рәхмәт. Без хәбәрдар түгел идек...

– Юлыгызны дәвам итеп, Актүбә буйлап күтәрелә торыгыз. Яшенсуккан дигән зур гына авылны күрерсез. Ул елга буенда урнашкан. Хәер, сез барып җиткәнче, бәлки Басман бий үзе дә килеп җитәр.

---

* Әс-Тархан улы Бачман (Басман) – Саксин әмире.

[5] Тоткак – дозор.

Яшенсуккан дигәне бу тирәләрдә сирәк очраган зур гына авылларның берсе булып чыкты. Анда барып җиткәнче үк илчеләрне үзенең бер төркем яраннары белән яхшы ат менгән, иярдә төз һәм горур утырган, таза сынлы бер бий каршы алды.

– Басман, – диде ул, тимер кыскыч кебек көчле кулы белән Бибарсның кулын кысып, – Саксин әмире.

– Бибарс. Болгар солтаны илчесе.

Бибарс Басманга игътибар белән карады. Куәт аңкып торган киң иңсәләр, сум итле көчле беләкләр, каратут йөз, карчыга борын, озынча зур күзләр һәм катгый җыерчыклы юка иреннәр. Аның аргамагы да затлы бизәлгән: ияр кашагаларына чүкеп сырчаланган көмеш өртелгән, җиз өзәңге баулары өстеннән калын күн каплавычлар асылган, ә ат койрыгына киертелгән божрага тоташтырылган ияр койрыкчасы һәм ат түшендәге түгәрәк калканга барып тоташкан ияр күкрәкчәсе каешларына көмеш тәңкәләр тезелгән.

Басман, күрәсең, яралы иде, япанча[6] эченнән муены белән берочтан сул як күкрәгенең дә бәйләүле булуы сизелә иде. Бибарсның үзенә игътибар белән каравын тоеп, ул кыска гына:

– Сүбәдәй тамгасы, – дип аңлатты. – Кызурак атлатыйк, җыенда сине көтәләр.

– Мине көтәләр? – дип гаҗәпләнде Бибарс. Аннары эченнән генә: «Мин болгар илчесе ләбаса!» – дип уйлады, ләкин нинди дә булса горурлану хисе тоймады. Басманның әйткән сүзләре дә аның күңелен сүрелдерде, сагайтты.

– Бәпәнәй морза мангуллар белән багланышка кергән булса кирәк, Чыңгыз хан ягына авышырга чамалый. Башка морзаларны да азгынлыкка котырта. Килеп җитүең яхшы булды әле.

– Бәкләр бәге, Җидесу – синең кулыңда! Ни кылсан да иркең бар. Мин генә нәрсә эшләтә алырмын икән ул морзаны?

– Фаш итәргә кирәк. Ул бит – солтанның туганы. Шуңа күрә дә миңа баш бирми! Иелгән башны кылыч кисмәс, дип уйлый ул. Чыңгызханның иелгән башны гына түгел, ана карынындагы баланы да йолкып алып бугазлый торган хөкемдар икәнлеген аңламый. Яшь булсаң да, Сүбәдәй урдасына барып, аны үз күзләрең белән күргән Болгар патшасы илчесе бит син, сөйлә күргәнеңне!

Авылга җиткәч, тукталып та тормыйча, гәпләрен дәвам иткән хәлдә Актүбә буена төшеп киттеләр. Ашыгып агып яткан елга күренгәч, Басман аргамагыннан төште, тармакланып үскән тирәк төбенә корылган алты канатлы тирмәгә таба атлады. Бибарс та, тезгенен Тәкингә биреп, аның артыннан ияреп китте. Тирмә артында утлап йөргән дөяләр, төтәп янган учаклар, таганнарга асылган, симез куй ите кайнап торган казаннар күренә. Тирмә янындагы зур карт тирәк ботакларында төрле төстәге тасмалар җилферди. Ислам динен ярты-йорты гына кабул иткән Җидесу халкының, бу мәһабәт агачның ботакларына төрле нәрсәләр тагып, төрки тәңресенә келәү келәүләп[7] табына торган байтирәк, ягъни бөек тирәк икәнлеген Бибарс белә иде.

Каплавычлары күтәрелеп куелган тирмә авызыннан тәбәнәк өстәл тирәли ак киез җәелгән идәнгә аякларын бөкләп утырган әмирләр һәм аксакаллар күренде. Тирмәгә якынлашкач, Басман бий алгарак узды һәм җыендашларына карап, көр тавыш белән:

– Идел йорт әмире, Болгарның алтын тәхете иясе Буян солтанның Чыңгызханга җибәргән илчесе Бибарс! – дип, кунак белән таныштырды.

Бибарс һәммәсенә сәлам бирде, сүз көрәштерү белән мавыгып, үзенә артык игътибар итмәгән кайбер бийләр белән дә кул биреп күрешеп чыкты. Аннары табын янына Басман янәшәсенә килеп утырды. Табынга агач табакларны тутырып ит салынган, ә чынаякларны мөлдерәмә итеп кымыз куелган иде. Житез баурчылар таганнарга асыл-

[6] Япанча – бурка.
[7] Келәү келәүләү – бик борынгы чорларга караган табыну йоласы (келәчү-сүз).

ган казаннарында ит пешерәләр, карабашлар исә өстәл белән учак арасында савыт-саба күтәреп йөренеп тора.

Бер-ике ел гына элек мондый олуг түрәләр белән бер табында утыру Бибарсны үтә дә гаҗәпләндерер иде. Алар – аның өчен янәшә утыра алмаслык аксөякләр, зыялылар. Әмма дә хәзер аның бу үз-үзеннән канәгать, масаюлары йөзләренә чыккан морзалар каршында нәзакәтләнеп утырырга вакыты юк иде. Аларның күбесе Буян солтанның, димәк, аның да дошманнары. Дөрес, монда төрле кабиләләрдән килгән аксакаллар да утыра, ләкин кайчандыр чын халык вәкилләре – аксакаллар киңәшмәсе булган җыеннар күптән инде морзалар мәҗлесенә әверелгән иде. Шуңа күрә дә, сөйләшкәндә ашыкмыйча гына, колакны сак тотып сөйләшергә кирәк тапты. Әйдә, башта үзләре сөйләсен, нәрсә әйтергә теләгәнлекләре ачыклансын.

Ләкин морзалар ашыгып сүз катмады. Өстәл тирәли утырышкан җирләреннән алар симез ит ашый-ашый, кымыз эчә-эчә әкрен генә үзара гәпләшүләрен дәвам итеп, Бибарсны каш астыннан гына күзәттеләр. Аның артык яшь булуы да, бернинди биргүсез, бүләксез килүе дә, яраннарының аз булуы да игътибардан читтә калмады, әлбәттә.

Басман бий, Бибарсны кымыз белән сыйлаган арада, үзара гына сөйләшкән тавыш ясап, хуҗалар белән таныштырып чыкты.

– Түрдә утырганы – атаклы Бәпәнәй морза. Аның уң кулында – әмир Тугыл, ә сул кулында – Толымбай. Бәпәнәй яраннары. Арык акыллы кешеләр. Теге гәүдәгә тазасы – Кучкар батыр – Каф тавында бәрелештә катнашкан кеше. Аннан бирерәк утырганнары – Таймас һәм Тайчын әмирләр – көр акыллы, үз фикерле кыю кешеләр. Боларын кулдан ычкындырмаска кирәк.

Бибарсның игътибарын чал кергән сакаллы, карап торуга ук күркәм йөзле Бәпәнәй морза үзенә ныграк җәлеп итте. Ул башкалар арасында яшькә өлкәнрәк булуы белән генә түгел, ә тоткан урыны, ягъни кабиләсенең, җир-суларының зурлыгы белән дә аерылып тора иде, күрәсең. Җыендашлары аңа сүз кушканда ихтирам белән дәшәләр, ә ул сүз башласа, сөйләшүдән туктап, юл куялар иде.

– Бәпәнәй кайсы кабиләдән, ни өчен морза дип атыйлар аны? – дип сорады ул Басманнан.

– Кыпчакның шактый зур кабиләләреннән берсе булган иштәкләрдән ул. Иштәк дигәне, Болгарга «иш» булып кушылуын аңлата инде. Әмир улы – Буян солтанның туганнан-туганы. Заманында Болгардан җибәрелгән, ә хәзер – азгын әмирләрнең башлыгы. Алтын тәхеткә дә өмете юк түгелдер, бәлки.

Бәпәнәй морза игътибар белән Бибарска күз ташлады. Майлы кулларын тезенә җәелгән сөлгегә сөртеп алды да, кымыздан авыз итеп куйгач, сүз кушты:

– Мине бернәрсә борчый. – Ни әйтер икән морза, дип, бар да тынып калдылар. – Бәлки, егет, син җавап бирә алырсың?

Аның сүзләре әдәпле булса да, карашы мыскыллы булып тоелды Бибарска.

– Җавап бирә алсам, рәхим ит, Бәпәнәй морза.

– Безне бернәрсә – Сүбәдәй баһадирның нияте, ни-нәрсә эшләргә җыенганлыгы кызыксындыра. Фикерем аңлашыламы?

– Ягъни Каф тавы итәгендәге бәрелештән соң мангул чирүе кай якка баскынлык итәр икән дисезме?

– Әйе. Дөрес чамалыйсың. Күп кенә кабиләләрнең язмышы, иминлеге шул мәсьәләне ачыклау белән бәйләнгән. Бәлки Сүбәдәй баһадирга дуслык тәкъдим итәргәдер? – диде ул, Басманга кырын карап алып. – Яуны яхшылык белән дә җиңеп була бит.

– Юк нәрсә сөйлисең, Бәпәнәй морза! – диде Басман кызып китеп. – Мангул чирүенең көч белән генә түгел, явызлык, икейөзлелек белән дә аерылып торганлыгын безгә Каф тавы итәгендә үз җилкәбездә татып карарга туры киде.

Бәпәнәй морза Басманның сүзенә игътибар итмәде. Күрәсең, алар арасында сүз көрәштерү Бибарс килеп җиткәнче үк башланган иде.

– Мин сине тыңлыйм, илче егет.

– Миңа мәгълүм булган кадәрлесе шул: Сүбәдәй Аладимер кенәзлекләренә баскынлык итәчәк.

– Яхшы, ә аннары?

– Дөрес сөйлиме илче егет, әллә дөрес түгелме? – диде Кучкар батыр, аның соравын бүлеп. – Ничәмә ел инде Чыңгызханның явызлыгы, морадына ирешү өчен ялганнан да җирәнмәве, җәйләүләрне туздырып, авылларны һәм шәһәрләрне хәрабә-хәкарә кылып, халкын кырып бетерүе, ә исән калганын тоткын ясап, кол итүе турында ишетәсез ләбаса! Сүбәдәе дә шул. Илче итеп безгә кыпчакларны җибәрде. Бер тел, бер кан, имеш... Алан йортын басканнан соң, барлык кыпчак җәйләүләрен туздырып чыкты. Менә сиңа дуслык. Шул туры сүз белмәс нойонга тагын ышаныйкмы инде?

– Мин соравымны илче егеткә биргән идем, – диде Бәпәнәй морза тыныч кына тавыш белән.

– Бу сорауга килгәндә исә, – диде Бибарс катгый итеп, – Чыңгызханның гаскәр башлыклары Сүбәдәй баһадирга, йә Чабә нойонга нинди максат куйганлыгын аныклый алдым кебек...

Бибарс, җыенда үзенә теләктәш әмирләр өстенлек алуын теләп, Кучкар батырның сүзен куәтләде:

– Сүзендә тормаган, мәрхәмәтне белмәгән дошманны, әлбәттә, дошманча каршы алып, бердәмлек белән генә җиңәргә мөмкин. Болгар солтаны Буян, дәүләте яр, гомере озын булсын, сезнең һәммәгезгә дә олуглап сәлам тапшырырга боерды. Кул астыгыздагы чирү белән туган йортыгызны сакларга чакыра. Барлык чирүне бер төбәктә туплау өчен болгар җирләренә – Самар, Агыйдел үзәнлегенә күтәрелергә тәкъдим итә. Сүбәдәй баһадирның Кыпчак даласында Чабә белән берләшеп алып, Идел йортка баскынлык ясаячагына аның шиге юк.

– Ак фикер бу. Моның белән килешәм мин! – диде Басман.

Җыендагы кайбер әмирләрнең һәм аксакалларның Болгар патшасына теләктәшлек күрсәтеп утыруларына үртәлгән Толымбай, ялтырап торган симез битен Басманга борып, аңа каршы төште:

– Син каршы килмәссең, әлбәттә. Саксин әмире, шәһәр кешесе буларак дим, ихтыяҗларыгыз бәлки тәңгәл килә торгандыр. Ә безгә нишләргә? Ни өчен халыкны кырдырырга? Корыган үләнле җәйләүләр өченме? Шундый ук җәйләүләр Җаек аръягында да, Себердә дә бар!

– Синең ихтыяҗың башка инде алайса? Ә Идел-Йортның калалары булмаса, син пулга[8] мохтаҗ ырудашларыңа кәфенлек тә таба алмассың бит!

Болай да башына ару гына кымыз суккан Толымбай, урыныннан сикереп торып, кынындагы бөктәсенә[9] үк ябышты. Ләкин Кучкар батыр көчле куллары белән аны тартып урынына утыртты.

– Дулама, чебен дулап тәрәзә вата алмый. Басман – Сүбәдәй нөкәрләрен йомычка турагандай туздырган, чапкан егет, ә алар, мин сиңа әйтим, сугыша беләләр!

Толымбай, ачулы күзләрен Басманнан алмыйча, мыгырданды:

– Миңа пул кирәкми. Мең баш елкым гына бар. Ә кәфенлек кирәк икән, Тураннан алдырырбыз!

– Иминлек булганда бар да дус, бар да кода булырга омтыла, – диде Басман ачу белән. – Ә каза яки илбасарлар килсә, кайберәүләр качарга чамалый. Качып кына калса, бер хәл, исемен дә дөрес итеп сакауламыйча гына әйтә белмәсә дә, безнең җирсуларыбызга хуҗа булып, бер бәдир[10] кымызга аны дошманга сата башлый!

Басман, артык кызып китүен чамалап, тынып калды.

[8] Пул – Болгар шәһәрендә хәлиф Насиретдин (1180-1225) исеменнән сугылган бакыр акчалар.
[9] Бөктә – хәнҗәр.
[10] Бәдир – савыт.

– Барча әмирләрне дә куркак, дип әйтмим мин, әлбәттә. Ир-егетләр дә җитәрлек. Чирү күрсә – алып ир көр арыслан булыр, ди. Әнә, сарычән[11] әмирләре гомер-гомергә ызгышып яшәгән Аладимер кенәзләре белән дуслашып, иш булдылар. Мангул субашы Сүбәдәйгә каршы бергәләшеп каршы торырга җыеналар...

Әмирләрнең сүз көрәштерүен сизмәгәнгә салышып кына күзәтеп утырган Бәпәнәй, бәхәскә кушылырга вакыт җитте, дип тапты күрәсең:

– Толымбай әмир, дөрес сөйләмисең, – диде ул, Толымбайны шелтәләгән булып. – Җаек аръягында да, Туранда да буш җәйләүләр юк хәзер. Җир йөзенең кеше яши торган һәр төбәге диярлек Чыңгыз каган кулында. Сүбәдәй баһадирга илче итеп бер малай җибәргән, үз илендә дә тәртип кертә алмаган Буян гына Идел-Йортын саклап кала алмас. Биредә без шушы мәсьәләне хәл итәргә дип җыелган. Кеме су тапмый эчмәгә, кеме күпер тапмый кичмәгә, ди мәкаль. Безнең ихтыяҗларыбыз башка...

– Фикереңне аңлый алмыйм, морза, кайсы якка боргаланмакчы буласың?

– Әйтсәм-әйтим, – диде Бәпәнәй үзенә теләктәшлек күрсәтеп, күзен дә алмаган әмирләргә һәм аксакалларга ярарга тырышып. – Кемнәр генә күчмә кабиләләр исәбенә тәхетен ныгытырга тырышып карамады. Хәзәре дә, Болгары да... Безгә бит үз язмышыбызны да уйларга вакыт. Бүгенгесе көндә күп илләрне һәм халыкларны буйсындырып, аларга нур биреп торучы патша бер генә – ул ак патша[12] – Чыңгыз!

– Сакалыңа чал төшкән, ә акылың арык килеш калган, – диде Басман ачу белән. – Үкенергә туры килмәсен! Идел-Йорт синнән башка да яшәгән һәм яшәр дә! Ә менә син аннан башка ничек яшәрсең икән соң, азгын морза?! Чыңгызның кем икәнлеген күз алдына да китерә алмыйсың әле син! Китерерсең, ләкин соң булыр!

Басман бий, Бибарсны һәм үзе яклы берничә әмирне ияртеп, тышка чыкты. Аның йөзе көзге болытлы көн кебек караңгы иде.

– Миңа китәргә кирәк, Басман бий. Атларыбызны алыштырсагыз икән.

– Бусын үзем башкарырмын, – диде алар белән бергә чыккан Кучкар батыр һәм китеп барды.

Басман, Бибарсны башка әмирләрдән аерып, бер читкәрәк алып китте.

– Бибарс, монда минем дә гаеп юк түгел, эшләр без уйлаганча ук барып чыкмады. Ләкин боларның кыланышын үз күзләрең белән күрсен, дип көттем мин сине. Бәпәнәйнең бер ялгызы гына түгеллеген үзең дә чамаладың. Күчмә халык, үзең беләсең, бөтен кабиләсе белән күтәрелә дә яуга чыга. Аларга мин үз көчләрем белән генә каршы тора алмыйм. Бу мәсьәләне солтанга ачык итеп сөйләп күрсәт, чөнки боларның Сүбәдәйгә ярдәм итүләре һәм болгар гаскәренә зур уңайсызлыклар китерүе мөмкин!

– Үзең аңлыйсың, Басман бий, вакыты шундый. Дөресен әйтим, синнән сер юк, исемем генә илче минем, чынлыкта исә – Солтан Буянның Сүбәдәй ыстанына җибәрелгән күзәтүчесе. Ә Солтан Буянның вәзире Җик остаз – атаклы акыл иясе. Ул, Болгарда күпсанлы чирү җыеп, коралландырып, оештырып ята. Олуг эшләр көтелә...

Басманның беркадәр йөзе ачылып китте. Ул, Бибарсның иңенә кулын куеп, әйтәсе сүзен әйтте:

– Сүбәдәйне күрдең инде. Ниятен яхшы аңлыйсың. Ул безнең өскә ябырылачак. Биредә кырагай әмирләренең дә кыланышын күреп китүең яхшы булды. Барысын да түкми-чәчми сөйләп күрсәт: Идел-Йортның бөтенләе белән диярлек хәтәр астында икәнлеген аңласын. Бусын да Солтанга сөйләп күрсәт: кулда көч бар чагында һич тә сынатмам! ■

---

[11] Сарычән – урыс елъязмаларындагы половецларның үзатамасы.

[12] Ак патша – бөек патша.

Югары мәдәниятне саклау юлында: Габделбари хәзрәт Исаев

Әлфрид Бостанов

XX гасыр – татар тарихында гаҗәеп бай һәм катлаулы чор. Бу дәвердә татарның югары шәһәр мәдәнияте шактый югалтулар кичерә. Һәрхәлдә, бүгенге көндә әлеге вакыйгаларның сәбәбе (чыны, уйдырмалары) төрле яклап өйрәнелә, яңа фактлар ачыклана.

Максатым – халкымның башыннан кичкәннәрен кабаттан торгызу түгел, ә татар җәмгыятенең үсешенә зур өлеш керткән, шундый катлаулы шартларда да милләт язмышына битараф калмаган күренекле шәхесләребезнең эшчәнлеген барлау. Динсезлек һәм үз асылыңнан ераклашырга мәҗбүр булган заманда яшәп тә, дин юлында актив эшчәнлек алып барган аерым шәхесләребезнең тормыш юлы, теләк-омтылышлары, изге ниятләре хәзерге һәм киләчәк буыннарның игътибарына, аларның уңай бәясенә лаек, чөнки бу кешеләр югары татар мәдәниятенең асыл җәүһәрләрен саклап кала алганнар.

Үз милли йөзеңне күрсәтү, туган телдә сөйләшү, милли мәсьәләләрне кайгырту кебек гамәлләр әле күптән түгел генә тыелган иде. Үзгә фикер белдерүдән куркып, гади кеше чын исемен яшерә, халык арасына кереп югала башлый. Һичшиксез, бу юл күпләрне үзгәртә: асылын оныттыра, халкыбызның гореф-гадәтләреннән баш тартырга мәҗбүр итә. Кыскача әйткәндә, совет заманы – халык өчен зур сынау чоры.

Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) хәдисендә әйтелгәнчә, кыямәт көне якынлашканда адәм баласы, уттан ерак торган кебек, диннән читләшергә ашыгыр. Совет заманында күпләр, диннән генә түгел, миллилектән дә котылу юлын эзләде. Әмма сүзебез ул заманда башка юлны сайлаган шәхес турында булачак. Максатыбыз – шул дәвердә яшәгән имамның тормышын өйрәнеп, дин һәм милләт тарихына күзәтү ясау, үткәндәге күпкырлы вакыйгаларга аның күзлеге аша карау.

Бу мәкаләбез халык хәтереннән җуелган һәм күптапкырлар гаделсез шартларга дучар ителгән күренекле шәхесләребезнең берсе – Ленинград мәчетенең имамы, гомеренең соңгы елларында Диния нәзарәтендә мөфти вазифаларын башкарган Габделбари Низаметдин улы Исаевка (1907-1983) багышлана.

Габделбари Исаев милләтебезнең иң атаклы галимнәреннән гыйлем алып, имам вазифасын үти, аннары большевиклар һөҗүменнән котылырга теләп, гаиләсе белән Урта Азиягә китә. Соңыннан Бөек Ватан сугышында катнаша. Күп авырлыклар күрсә дә, Габделбари хәзрәт дин юлын ташламый: Уфаның икенче мәхәллә имамы, Диния нәзарәте әгъзасы булып эшли, 1956 елда Ленинград мәчетенә имам итеп куела. 1975-1980 елларда Габделбари Исаев мөфти вазифаларын башкара. Хәзрәт үз гаиләсе белән утыз елга якын Ленинград шәһәрендә тора. Монда ул элекке татар традицияләрен дәвам итеп, хисапсыз дини шигырьләр яза, атна саен вәгазь сөйли һәм зур әһәмияткә ия булган ике-өч дини әсәр иҗат итә. Әлеге

бәһасез милли хәзинә бүгенге көндә хәзрәтнең туганнарында саклана. Шушы бай документаль чыганакларга таянып, хәзрәтнең тормыш юлын һәм иҗатын яктыртасым килә.

***

1950 елда Габделбари хәзрәт тарафыннан төзелгән гаилә шәҗәрәсенә күз салсак, Исаевларның тамыры Чыңгыз ханның гаскәр башы Майкы бигә барып тоташканын күрәбез. Бу башка шәҗәрәләр белән дә дәлилләнә: хәзерге Башкортстан җөмһүрияте чигендә урнашкан татар кабиләләренең күбесе югарыда искә алынган Майкы бине үзләренең төп бабасы буларак таный. XIX гасыр башында әлеге нәселнең бер өлеше хәзерге Башкортстан Республикасы Бәләбәй өязенең Югары Аташ авылына килеп урнаша. Габделбари хәзрәтнең әтисе Салих улы Низаметдин – Уфа шәһәрендә сәүдәгәр, әнисе Мөхәммәдхафиз кызы Фәхрелҗәмал мөселман киемнәре сата торган сәүдәгәрнең кызы була. Менә шушы гаиләдә 28 гыйнвар көнне ир бала дөньяга килә. Сабыйга исем кушу бәйрәменә Уфа шәһәренең өченче мәчете имам-хатыйбы, Диния нәзарәте әгъзасы Сабирелмөхсин хәзрәтләре чакырыла.

Габделбари хатыны Мөсәүвәмә һәм олы кызы Рәшидә белән

Малайга алты яшь тулгач, әтисе Низаметдин улын «земский ышкулга» укырга бирә. Күп еллар узгач, бу мәктәптә укыган елларын Габделбари хәзрәт үзенең истәлекләрендә («Тәрҗемәи хәлем»дә): *«Ул ышкулада иртән бер сәгать дин укытыла, аннан падишаһ дога[сы] булып, дәрес башлана иде. Моның соңында, унбер яшемдә мине әнкәй Башкортостанның Әсән мәдрәсәсенә Коръән[не] хифз [ятлау] итергә илтеп куя, анда, исемен белмим, әгъма [сукыр] бер кари [Коръән белгече] була. Ул бик усал, бик кыйный торган. Бу авылдан бер атна-ун көннән соң качамын. Шул җирдән 18-20 километр чамасы Түйлүгән дигән авылга Хәбибәриҗал Габделкадири кари хәзрәткә илтеп тапшыралар. Ул 35 яшьләрендә була. Бик гайрәтле һәм требовательный. Әлбәттә, ул вакыт гамәлгә куелган кыйнау монда да бар иде, ләкин мин үзем бер генә тапкыр кыйналдым, бәлки әткәйнең ярдәмле булуы файда иткәндер. Анысын ачык белмим»*, – дип яза.

Безнең кулыбызда Түйлүгән авылының беренче мәхәлләсе имамы һәм мөдәррисе Хәбибәриҗал хәзрәттән шәхси тәрбия алу буенча «Уку кануны программасы» бар. Бу кызыклы документ бер битлек кульъязмада сакланып калган. Аның язылу тарихы ачык күрсәтелмәсә дә, югарыда китерелгән



«Уку кануны программасы»ның икенче бите. Мөгаллим – Хәбибәриҗал хәзрәт. Укучы – Габделбари шәкерт

сүзләргә таянып, документның инкыйлаб вакытына караганлыгын фаразларга була. Битнең бер ягында дәресләр тәртибенең искесе (сызылып беткән), икенче ягында яңа җәдвал язылган. Әүвәлге дәресләр тәртибе буенча яшь Габделбари әл-Аташый белән тагын бер шәкерт – Габделхәй бине Габделхәлим әт-Түйлүгәни атна дәвамында көн саен укыган. Шимбә, дүшәмбе, чәршәмбе көннәрендә мөхтәсар, хисап, Коръән һәм гарәп теле (сарыф) укытылган; якшәмбе, сишәмбе, пәнҗешәмбе тәфсир, география, Коръән, гарәп теле өйрәнелгән. Коръән уку, аны ятлау һәм тәфсир өчен җомга көн махсус калдырылган.

Документның икенче ягында Габделбариның гына исеме язылган. Исеме янына «хафиз каләмуллаһ» дигән титулы да куелган. Димәк, Хәбибәриҗал хәзрәт җитәкчелегендә яшь шәкерт Коръән Кәримне тулысынча ятларга өлгерә. Моңа карамастан, алар остазы белән көн саен изге китапны кабат укып торганнар, мөхтәсар белән тәфсир көнаралаш өйрәнелгән, гарәп теленә дә игътибар зур булган. Соңыннан, бу фәннәргә өстәп, шимбә көнне «Мең дә бер хәдис» китабын укыганнар, якшәмбе, сишәмбе, пәнҗешәмбе көннәрендә «Мишкәт шәриф» хәдисләр җыентыгын, дүшәмбе белән чәршәмбе тагын хәдис өйрәнгәннәр. Атнаның башка көннәреннән аермалы буларак, җомга көне тулысынча Коръәнгә багышланган.

Ул замандагы шәкертләр тормышын төгәлрәк күзаллау өчен, Габделбари хәзрәтнең тәрҗемәи хәленә әйләнеп кайтыйк. *«Бу авылда дәрес тәртибе. Мин үзем бик фәкыйрь һәм бик миһербанлы Хәйруллаһ бабайларда тордым. Алар әби берлән икәү генә иде, ләкин мине «балам» дип йөртәләр иде. Хәзер дә, әлхәмдүлиллаһ, аларны һәр көн догадан калдырганым юк, Аллаһ кабул итсен. Иртә намаздан соң – Коръән тыңлату, аннан – дәрес алып кайтып китү. Дәрес һәр көн Коръәннән ике бит, бер «сөмен» [сигезе] бирелә иде, ягъни Коръәннең беренче яртысы 240 көндә узылды. Аннан соң икенче ярымы башланды. Ләкин инде бу вакытта әүвәлге ярымы тагын да бер «әрбагъ» – дүрт бит берлән тәкрар [кабатлау] башланды, ягъни алты бит хифз*


Центральное Духовное Управление Мусульман.

Свидетельство.

Габделбари хәзрәткә бирелгән шәһадәтнамә: «Башкортстан җөмһүрияте Бәләбәй кантоны Чакмагыш волосте Югары Аташ авылының Габделбари бине Низаметдин 1927 нче елда 22 нче декабрьдә, Диния нәзарәте хозурында кылынган имтиханында имам вә ибтидаи [башлангыч] дини мөгаллимлек дәрәҗәсенә лаеклы табылганлыктан, Диния нәзарәтенең ошбу 1927 нче ел 22 нче декабрьдә булган карарына муафыйк Габделбари бине Низаметдин мәзкүр Бәләбәй кантоны Рәҗәб волосте Югары Каряуды авылының беренче мәхәлләсенә имамлык мәнсәбенә [вазифасына] тасдыйк кылынып, канунның 8 нче фасыйл 7 нче маддәсенә муафыйк ошбу мәншур [указ] бирелде». **Документка Диния нәзарәтенең мөһере сугылып, ул мөфти Ризаэддин бине Фәхреддин һәм казый Мәһди Максуди имзалары белән расланган.**

[ятлау] итәргә туры килде. Бик авыр булды, хәтта хәзрәтемез миңа: «Бик авыр бара, син әллә туктыйсыңмы?» – диде. Мин: «Юк, Ходайга тапшырдым», – дип, дәвам иттем. (Шуны әйтергә кирәк, мин унбер яшемдә сарыф, нәхү укыган идем. Миңа бераз шул ярдәм бирде.) Шулай итеп, беренче ярымы тагын алтмыш көндә тәкрар [кабатлау] ителеп, икенче ярым әле ерак китмәгән иде. Моның соңында беренче ярымы ярты парә берлән тәкрар башланып, икенче ярым яртылаш башланган иде. Бер айдан беренче ярым бер парә берлән тәкрар башланып, әл-хасыйл [кыскасы], беренче ярым нык күңелгә беркетелде, икенче ярым бер тапкыр хифз ителеп чыкты. Минә моннан соң кичке белем алу дәресе башланды, ягъни ясигъ намазыннан соң хәтта ярты төннәр узганчы тәфсир, хәдис, гыйлме фикъһ һәм башка дәресләр кертелә башлады».

Димәк, 1921 елда, Габделбари Исаевка ундүрт яшь тулгач та, ул беренче тапкыр хәтем кыла башлый, ягъни Коръән Кәримне өч ел эчендә ятлый. Хәзрәт тәрҗемәи хәлендә үзенең тәрбия алу турындагы хатирәләрен дәвам итә: «*Моның соңында Уфа шәһәре Зыяэддин Камали хәзрәтләренең «Галия» мәдрәсәсенең программасы буенча дәрес алып, 1926 нчы ел Диния нәзарәте хозурында Ризаэддин Фәхреддинов мөфти хәзрәтләренә имтихан иттем. Имтиханда Зыяэддин әл-Камали, Мәһди Магъкули, Җиһангир Абызгилдин, Кәшшаф Тәрҗемани, Мөхлисә Бубый һәм башкалар катнаштылар. Ошбу имтиханда имамлык дәрәҗәсенә шәһадәтнамә бирелде һәм шул ел Башкортостанның Чакмагыш нәхиясенә [волостена] табигъ [урнашкан] Каряуды авылында хәтме Коръән итеп, шул җиргә имам булып калдым*».

Яшь имам авылга кайткач, гаилә

корып җибәрергә ниятли. Әтисе Низаметдин улы Габделбари белән тирәяктагы татар-башкорт авылларыннан кәләш эзләргә тотына. Иске Биккенә авылында мөәзин булып эшли торган Мирзашәриф Вәлидановның биш матур кызы була һәм аларның берсен Габделбари хәзрәт белән кавыштырырга уйлыйлар. Мирзашәриф үзенең иң олы кызын – Мөсәүвәмә исемлесен кияүгә бирергә тели, әмма беренче килүдән соң, ни сәбәпледер, ризалыгын бирми. Низаметдин бабай бу хәлне: «Ярый, инде, көмеш булмаса, алтын табылыр», – дип, хәерлегә юрап куя. Башка йортларда да Аташ авылы кодаларын кире борып җибәрәләр. Низаметдин белән Габделбари хәзрәт янәдән Мирзашәриф хәзрәтнең ишегалдына әйләнеп кайтырга мәҗбүр була. Мирзашәриф Вәлиданов, ниһаять, үз ризалыгын белдерә, тиздән никах укыла. Габделбари хәзрәт белән Мөсәүвәмә гаиләсендә бер-бер артлы ун бала дөньяга килә.

1927 елда хәзрәт укуын дәвам итә, фотоальбомында: *«...ыстудент идем, кулымда китап, галстук кидем...»* – дип язса да, аның кайда укыганлыгы турында мәгълүмат юк.

Тормышның бәхетле сәгатьләре авыр чорга туры килә. Билгеле, яшь Совет хөкүмәте баштан ук ислам диненә һөҗүм итми, үз көчләрен башка өлкәләрдә куллана. Әммә тора-бара шунысы ачыклана: диндар кешеләр, ислам диненә өйрәтүчеләр – алар яңа заманның дошманнары. Дингә һәм иркле фикер йөртүгә каршы илебездә репрессияләр, һөҗүм башлана. Иң тырыш һәм акыллы шәхесләрне юкка чыгаралар яки ватаныбыздан китәргә мәҗбүр итәләр.

Бу авыр хәлләр турында Габделбари хәзрәт үзе дә яза, ләкин кайгырып, нәфрәтләнеп түгел, ә ниндидер оптимизм, киләчәккә ышаныч белән: *«Бертөрле төзелештән икенче төрле төзелешкә күчү өчен күп көчләр кирәк һәм корбаннар да булуы мөмкин. Яңа фикер кертү өчен көрәш корбансыз булмыйдыр. Безләргә дә шушы кампаниягә туры килеп, 1929-1930 нчы елларда бераз авырлык күрергә туры килде»*, – ди.

1929 елда Габделбари Исаев пролетариат сафына басарга була. Фоторәсеме янына шигъри юллар белән: *«Десятник булып эш алып бардым // Яңа төзелеш – балта эшендә»*, – дип теркәп куя. Әмма эштә тырышлык күрсәтеп кенә эзәрлекләүдән котылу мөмкин булмый: 1930 елның 13 нче февралендә Габделбари Исаевны, дин әһеле булганлыктан, Аташ авылында кулга алалар һәм берничә ай «исправительная колония»дә урман кисеп үткәрергә мәҗбүр итәләр.

Дин галимнәренең остазы Ризаэддин бине Фәхреддин, тагын да куркынычрак хәлләр киләчәген белеп, яңа буынны кисәтергә тырыша: *«Бу вакытларда Диния нәзарәтендә мөфти Ризаэддин Фәхреддинов хәзрәтләренә барып иттифак иткәннән соң, бу затлар: «Сез яшьләрсез, сезгә киләчәк вакытында күп хезмәтләр йөкләтелер. Ошбуның өчен, саклану өчен, Урта Азиягә китеп торыгыз», – диде. Һәм шул киңәш берлән Урта Азиягә барып урнашып, анда да зур галимнәр аркылы хисап эшләре хезмәтенә кереп, имамлык эше дә алып барылды».*

Төрмәдән чыгып, бер ел үткәннән соң, яз җиткәч, Исаевлар (бер яшьлек Рәшидә белән) Урта Азия якларына, Кыргызстанның Ош шәһәренә юнәлә. 1931-1932 елның кышында Габделбари Казакъстанның Чемкент каласында, «яңа төзелеш төзү эшендә» балта остасы булып та эшли. Җирле халык, аның дин әһеле булганлыгын белеп, имам вазифасын үтәргә чакыра. Бу чакыручыларга ияреп барганда Габделбари басмачыларга юлыга һәм тиз арада качып китәргә мәҗбүр була. Кызганыч, хәзрәтнең кайда имам булганлыгы билгеле түгел.

1934 елда Исаевлар кире Уфага кайта. Сәбәбе – Мөсәүвәмәнең әтисе Мирзашәриф Вәлидановның кулга алынуы һәм 1934 елда әсирлектә ачлыктан үлеп китүе. Мирзашәриф төрмәгә эләгер

алдыннан хатыны вафат була һәм биш кечкенә бала өйдә япа-ялгыз кала. 1933 елда иң олысына – Мәсгудә апага 10 яшь тулган була. Бу баланы да башта этисе Мирзашәриф белән төрмәгә ябалар, ләкин тиздән азат итәләр. Җитмәсә, йортны да хөкүмәт файдасына дип тартып алалар, калган дүрт баланы авыл читендә утыртып калдыралар. Күршеләре, аларны кызганып, урамнан ала. Исаевлар, Урта Азиядән кайткач, ятимнәрне ялгызлыктан һәм ачлыктан коткарыр өчен үзләренә, Уфа шәһәренә тәрбиягә алып китәләр.

«1934 елларда Диния нәзарәтенең Ризаэддин хәзрәт берлән очрашу булып, нәзарәтнең әгъзасы итеп үткәрелдем. Аллаһның рәхмәтендә булсын». Бу вакыйгалардан соң күп вакыт узмый, бөек остаз мөфти Ризаэддин хәзрәт вафат була. *«1936 нчы ел мәрхүмнең дәфенендә [күмелүендә] әнзәл кылып [ирешеп] һәм Габдерәхман Рәсүл хәзрәтенә мөфти тәгәйин иттегендә [сайлаганда] әнзәл итә [килә] алдык. Әлхәмдулиллаһ!»* – дип яза Габделбари Исаев.

Уфада Габделбари Исаев янәдән төрле эшләргә тотына. Мәсәлән, ул вакытта төзәтү берләшмәләрендә эшли, аннан Утильзаготовитель артеленә урнаша.

Диния нәзарәте бу чорда бөтенләй буш тора: хәзрәтнең укытучыларын яңа хөкүмәт төрмәгә утырта, лагерьларга озата, күпчелеге шунда үтерелә яки төрле газаплардан үзләре бакый дөньяга күчә. Әлеге дәвердә ватаныбызда югары ислам мәдәнияте көчләп юкка чыгарыла. Билгеле, күп еллар дәвамында әлеге авыр хәлләр турында хәзрәт берни дә яза алмый диярлек. Аның язмаларында ул чорга кагылышлы: *«Бу вакытларда дәүләт хезмәтен дә, нәзарәт хезмәтен дә алып бардык»*, – дигән юлларны гына очратабыз.

***

Габделбари хәзрәт гомеренең беренче дәверенә, ул чорга бәйле тарихи фактларга күзәтү ясаганнан соң, мондыйрак нәтиҗәләр чыгарырга була. Беренчедән, гражданнар сугышына, ачлыкка һәм башка күптөрле кыенлыкларга карамастан, инкыйлабтан соңгы татар авылында дини тәрбия бирү тукталмаган. 1920 нче елларда чит илләргә, Бохарага яки Мисырга бармыйча да җирле галимнәрдән белем алып булган, Диния нәзарәте дә имамлыкка указ биргән.

Икенчедән, авырлык килгән чорда яшь татар зыялылары Урта Азиягә юкка гына китмәгән. Ул төбәкнең Габделбари хәзрәт искә алган «зур галимнәр»е Уфа белән тыгыз элемтәдә торган булса кирәк. Бәлки үзара хат язышып, берберсенә кунакка да йөрешеп, тыгыз бәйләнештә торганнардыр.

Өченчедән, без танышкан чыганакларда Габделбари хәзрәт «яңа тормыш төзү» процессын шома гына барган итеп тасвирлый. Ә хәзерге тарихи әдәбиятта ике ватан сугышы арасындагы вакытны караңгы итеп сурәтләү, милләткә һөҗүм ясау, китапларны яндыру, ислам динен юк итү чоры итеп карау киң таралган.

Габделбари хәзрәт, яхшылыкка өмет итепме, ислам диненең үсешенә ышаныпмы, нәзарәттә булган кайгы-низаглар турында язмый. 1970 нче елларда ул: *«Яңа төзелеш корбансыз булмый»*, – дигән сүзләрне теркәп калдыра. Монда, әлбәттә, хәзрәтнең «торгынлык» чоры күзлегеннән фикер йөртүе ачык булса да, бу сүзләрнең аерым әһәмияте бар. Алар безгә татар тарихында совет чорының ролен башкача күзалларга мөмкинлек бирә. Бу чорны, чыннан да, бары югалту-кайгыдан торган дәвер буларак, берьяклы гына бәяләп булырмы? Габделбари хәзрәтнең тормыш юлы әлеге сорауга җавап булып тора.

Дәвамы бар ■

Безнең мирас №4 апрель 2017

ИСЛАМ ГАЛӘМЕНЕҢ КАЗЫК ЙОЛДЫЗЫ

Хөсәен Вәлиәхмәтов

Февраль революциясен дә шатланып каршылый галим, «Әл-Мөнбәр» исемле үз газетасын ачып җибәрә. Мөселман халыклары тормышы, ниһаять, яхшырыр, сәясәт, икътисад, мәдәният өлкәсендә дә зур үзгәрешләр булыр, дигән өмет белән рухланып иҗат итә. Ләкин Беренче Бөтендөнья сугышы, түнтәрелешләргә ялганып киткән гражданнар сугышы ул якты өмет-хыялларның тормышка ашасына шикләндерә. Гражданнар сугышы чорында Петербургтан беркая да чыкмаган Муса Биги фатирында ярты еллап Һиндстанда укып йөргән чакларында ук танышкан, дуслашкан һинд галиме һәм язучысы Мәүләна Бәрәкәтуллаһ яши. Англия колонизаторлары эзәрлекләвеннән качып Россиягә килгән Һиндстан мөселманнарының милли азатлык хәрәкәте лидерлары Мәүләна Гобәйдуллаһ, Әбу Сәет Әл-Гарәби, Габделҗәббар һәм Габдәррабб кебек шәхесләр белән аралаша.

1920 елның сентябрендә Муса Бигиевкә Уфада узган Россия мөселманнары корылтаенда катнашу мөмкинлеге туа. Анда ул, Закир Камали (Чистайдагы «Камалия» мәдрәсәсендә Фатих Кәримине укытып чыгарган мәшһүр мәгърифәтче сәүдәгәр һәм ишан, Муса Биги аның кызы Әсмага өйләнә) һәм Кырым мөфтие Ибраһим белән килешеп, Россия мөселманнарын Хәлифәт канаты астына берләштерү тәкъдимен күтәреп чыга. Бу турыда Төркия Югары Милли мәҗлесенә мөрәҗәгать юлларга да чакыра. Мөрәҗәгатьне Муса Биги 1922 елны Мисырда Төркиянең Югары Милли мәҗлесе әгъзасы Суйсал Исмаил Собхига үз кулы белән бирә. Ул исә гозерне Төркия лидеры Мостафа Кемаль Ататөреккә тапшырырга тиеш була.

Әмма Ататөрекнең бу чордагы шәхси планнары турында тарихчыларга яхшы билгеле. Ул мөселманнарның бер канат астына берләшүеннән шүрли, Көнбатыш даирәләре сүзенә колак сала. Биги мөрәҗәгатенең киресен эшләп, Ислам Хәлифәтен тар-мар итүгә ирешә. Англия колонизаторлары исә моңа «дусларча ярдәм» белән җавап бирә – Төркиядә көрдләрнең үз дәүләтчелеген булдыру хыялын җимерергә булыша.

Россия мөселманнарын күпгасырлык сәяси изелүдән коткару, ирек даулау эшен дәвам иткән Муса Җаруллаһ мәсьәләне хәтта инкыйлаб юлбашчысы Владимир Ильич Ленин белән очрашу вакытында да күтәрә. Ленин да Бигидә яхшы тәэсир калдыра, Мусаның тәкъдим-планнары да Ленинны уйландыра. Шушы очрашу тәэсирендә Муса Биги «Ислам милләтләренә дини, әдәби, сәяси мәсьәләләр, тәдбирләр хакында» дигән мөрәҗәгатен (Ататөрек үз игътибарыннан читтә калдырган мөрәҗәгать турында сүз бара) 1923 елда Берлинда бастырып чыгара. Бу Николай Бухаринның «Коммунизм әлифбасы»на җавап рәвешендәге кебек яңгыраш алган «Ислам әлифбасы» буларак билгеле. Мөрәҗәгать-өндәмәне шулвакытта Берлинда яшәргә мәҗбүр булган Гаяз Исхакый «Яңа милли юл» газетасында үзе укып, редакцияләп, тулыландырып бастырып чыгара. Марксизм тәгълиматын,

Ахыры. Башы журналның быелгы 2 нче санында.

идеологиясен бик каты тәнкыйтьләгән, аның өметсез киләчәген алдан күргән фикерләре, карашлары өчен генә дә Мусаны берсүзсез атарга хөкем итәрләр иде. Бу өндәмә-мөрәҗәгать өчен дә галимне төрмәгә утырталар, әлбәттә. Аннан бары тик чит илләрдәге мөселман даирәләре, киң җәмәгатьчелек басымы астында гына котылып чыга. Ленинның үлеме дә биредә күпмедер роль уйный. Бигиевне, 3 ел дәвамында беркая да чыкмаска, беркем белән дә аралашмаска дигән чикләүләр белән, Мәскәүдә калдыралар.

1925 елның октябрь-ноябрь айларында, ниһаять, ул мондый хокук чикләүләреннән арындырыла һәм Кырымга ялга китәргә рөхсәт ала. Әмма ял иткәндә дә актив иҗат белән шөгыльләнә. «Аср'е мөселманлык» журналында «Мөскирәт мәсьәләсе» (Евпатория, Акмәчет) (спиртлы эчемлекләр проблемасы) дигән күләмле хезмәтен бастырып чыгара.

1926 елда Мәккәдә Бөтендөнья мөселманнары конгрессы уздырыла. Анда Уфа Диния нәзарәтенең 7 кешелек делегациясенә Муса Бигиев тә кертелгән була. Конгресстан кайтканда Муса, төркемнән аерылып, Истанбулга, аннан Анкарага керә. Анда исә Төркиянең тышкы эшләр министры Тәүфик Рушди белән очраша, Төркия парламенты утырышларында да сәгатьләр буе утырып чыга. Соңыннан галимне хәтта Төркия Премьер-министры Исмәт Паша да кабул итә. Шулчагында Каһирәдә узачак Хәлифәт Конгрессына чакыру ала.

1927 елда Муса Җаруллаһ Советлардан Хаҗ сәфәре кылырга рөхсәт сорый. Мәккәгә барышлый кабат Истанбулга кереп чыга. Анда үзенең Кырымда язган «Шәригать исламия назарында мөскирәт мәсьәләсе» (Проблема опьяняющих напитков с позиций исламского шариата) китабын басарга биреп калдыра. Хаҗ кылганнан соң Иерусалимдә Хәлифәтнең II Конгрессы эшендә катнаша.

Туган илгә әйләнеп кайткач та татар дөньясындагы мәдәни үзгәрешләр, фән, әдәбият яңалыклары, матбугат тормышы белән тирәнтен кызыксынуын дәвам итә галим. Ләкин татар иҗтимагый

Муса Бигиев. Документ өчен алынган фото. 1920 нче еллар

эшлеклеләре, коммунизм тәгълиматы йогынтысына бирелеп, буш хыялларга чумган, динсезлек сөременнән башлары әйләнгән яңа интеллигенция вәкилләре бөек мәгърифәтче һәм дин галиме идеяләрен кабул итә алмый. Муса бик күп тарафдарлары вә фикердәшләренең репрессия тырнагына эләгүен күреп-ишетеп тора. 1929 елда татар язучыларының зур төркеме СССР республикалары һәм төбәкләре буйлап сәфәр кылып кайта. Шул уңайдан язучылар Мәскәүдә киң җәмәгатьчелек каршында хисап тота. Бу чара белән кызыксынып килгән Муса Биги тамаша залында күренү белән яшь-җилкенчәк, дин галимен өнәмәүләрен белдереп, шаулаша-кычкырына, сызгыра башлый. Мәсхәрәләүгә, гарьлеккә чыдый алмаган галим залдан чыгып китәргә мәҗбүр була. Бу турыда «Кызыл Татарстан» газетасының 24.09.1929 санында Кави Нәҗминең отчет язмаларында бәян ителә.

Галим, Советлар Россиясеннән бөтенләй чыгып китүдән башка чара калмавын аңлый, ләкин аңа рөхсәт бирмиләр. Муса 1930 елның ноябрендә яшерен рәвештә Төркестанга таба чыгып китә һәм чик буендагы Симхане шәһәренә килеп эләгә. Анда исә, сәүдә кәрванына кушылып, Кашгарга юл тота. Бу төбәкләрдә патша заманнарыннан ук

татарлар күпләп яшәгәнлектән, Муса биредә бөтенләйгә төпләнеп калырга, җирле мәдрәсәләрнең берсенә укытучы булып урнашырга уйлый, ләкин Кытай хакимият органнары рөхсәт итми. Мусага атлар белән Кече Памир сыртлары аша дүрт айга сузылган күчеш ясарга туры килә. Ул Әфганстанга барып җитә. Илнең падишаһы Аманулла Надир шаһ мәшһүр дин галимен бик җылы кабул итә, аңа тиз арада чит ил паспорты эшләтеп бирә. Муса Һиндстанга китә, Бомбейда элек бергә гыйлем туплап йөргән дуслары белән очраша, кунак була, аннан инде гомеренең соңгы көннәренә кадәр яшәячәк Мисырга юнәлә.

Бөек гыйлем иясен чит илләрдә ихтирам итәләр, мөнәсәбәт Рәсәйдәге кебек начар булмый, әлбәттә. 1931 елда ул Анкарада Төркиянең беренче тарихи конгрессында катнаша, Финляндия, Германия кебек илләрдә яшәгән ватандашлары, фикердәшләре, дуслары янына баргалый. 1933 елда хәтта Берлинда үз нәшриятын булдыра, үз тирәсенә ислам зыялыларын тупларга уйлый. Һәм, әлбәттә, бөтенләе белән иҗатка күмелә. Зәки Вәлиди Туган тарафыннан Истанбулда чыгарылган «Тасвир гәзитәсе»нең 23.07.1948 санында Муса Бигиевнең 20ләп хезмәтен нәшер итәргә җыенуы хакында хәбәр бар.

Гомумән, Муса Җаруллаһ әфәнде гомере буена сәяхәттә яши диярлек. Үзе әйтмешли, бу халәт тумыштан ук аның канына сеңгәндер (Фатих Кәримигә язган хатында: *«Декабрь башларында Ново-Черкасск янында юлда туганмын...»*, – ди). 1934 елда ул янәдән бер кат Финляндиягә барып чыга. Шулчагында биредәге Иран консуллыгына да сугыла, Иран белән Гыйракка сәяхәт кылырга ниятләвен белдерә, виза сорый. Рөхсәт бирелә, әлбәттә. Фарсы телен тирәнтен белгән Муса биредә дә үзен туган илендәге кебек хис итә. Мәктәпләр, мәдрәсәләрдә уку-укыту тәртибе, халык тормышы белән кызыксына, мөгаллимнәр, талип, шәкертләр белән аралаша, бәхәс-әңгәмәләрдә катнаша. Иранда чагында Мусага шигыйләр мөҗәһиде Мөхсин Әмин Хөсәйни әл-Әмили (1867-1952) белән очрашырга туры килә. Форсаттан файдаланып, галим мөҗәһидкә шигыйләр фикхы һәм гакыйдә нигезләренә кагылышлы 20 сорау белән мөрәҗәгать итә. Мәшһәд, Тәбриз, Таһран кебек шәһәрләр белән танышканнан соң, Муса Җаруллаһ Гыйрак башкаласы Багдадка юл тота, биредә Ислам диненең мөһим бер тармагы булган шигыйләр нигезләрен өйрәнүен дәвам иттерә, 26 көн буена шигыйләрнең иң изге урыннарыннан саналган Нәдҗәф шәһәрендә яши (*«Мин яшәгән мәчеттән 5-6 метр чамасы гына арада Имам Әгъзам Әбү-Хәниф хәзрәтләренең кабере күренеп тора иде...»* – дип искә ала Муса соңыннан). Ике атна эчендә галим-сәяхәтче һәрберсе 450шәр биттән торган 15 томлык «Багдад тарихы», фикх нигезләре турындагы «Әл-Мәсбүт», имам Мөхәммәд белән имам Әл-Ширази китапларын укып чыгарга өлгерә. Багдадта ул бер елга якын тора, шигыйләр мөҗәһиденә биргән сорауларын башка галимнәргә, ислам белгечләренә, әңгәмәдәшләренә дә тарата, алардан бик күп җаваплар ала. Мөҗәһид тә Мусаның башта биргән 20 соравына җаваплар язып җибәрә. Габдел-Хөсәен Шәрәфетдин әл-Әмилинең «Әҗвибат Муса Җаруллаһ» («Муса Җаруллаһка җаваплар» дигән исемдәге 150 битле бу хезмәте Нәдҗәфтә 1935 елда басылып та чыга. Ә 1936 һәм 1966 елларда ул китап Ливанның Сәйдә шәһәрендә яңадан бастырыла (тулырак мәгълүматларны Мәхмәт Гүрмәзнең югарыда телгә алынган китабыннан табарга мөмкин).

Муса Җаруллаһ әфәнде 1935 елның ахырларында Каһирәгә кайта һәм үзенең озак вакытка сузылган сәяхәттә алган тәэсирләрен, исламның мөһим мәсьәләләренә багышланган күп кенә фундаменталь хезмәтләрен китап итеп бастырып чыгара.

1937 елда Муса Биги янәдән Һиндстанга бара, элек өйрәнә башлаган Махабхарата, бөек һинд галимнәре, брахманнар һәм пәйгамбәрләрнең бо-

рынгы хезмәтләре, һинд философлары һәм акыл ияләренең фикерләре, язмалары, борынгы китаплар белән таныша. Аннан элеккеге Петербургтагы танышы Габдерәшит Ибраһимов чакыруы буенча Ерак Көнчыгышка – Япония, Кытай илләренә барып чыга, ислам миссионерлары төркеме белән Ява һәм Суматра утрауларында була. 1939 елның көзендә, Икенче Бөтендөнья сугышы башлангач, Япониядән Һиндстанга кайтып китә, аннан инде яраткан Әфганстан җирендә бөтенләйгә төпләнеп калырга уйлый. Ләкин Кабулга кайтканда инглизләр тарафыннан тоткарлана һәм безнең көннәргә кадәр үзенең кыргыйлыгы, рәхимсезлеге белән яманаты бөтен дөньяга таралган Пешавар төрмәсенә ябыла. Искиткеч кыен шартларда ике елга якын гомере узып китә. Бәхеткә, Һиндстанның Бхопал штаты хакиме Мөхәммәд Хәмидулла Муса Җаруллаһны төрмәдән чыгарырга ярдәм итә. Ләкин галим 1945 елга кадәр инглизләр күзәтчелеге астында Пешаварда калдырыла.

Әмма Муса шундый шартларда да үзенең иҗатын, эзләнүләрен туктатмый. Тоткынлыкта чагында гына да ул 8 фәнни трактат яза. Ислам тәгълиматларының яңа тармагын – икътисад юнәлешен тирәнтен өйрәнә. Аның 1916 елда Петербургта «Зәкят» дигән күләмле хезмәте басылып чыгу турында әйткән идек инде. Ә 1944-1946 елларда Һиндстанның Бомбей шәһәрендәге Бхопал штатындагы нәшриятларда гарәп, фарсы телләрендә чыккан «Тәкъмин әл-хәят вә әл-әмлак» (Страхование жизни и имущества), «Сәхифәт әл-фәраид» (Записки о праве наследования), «Әр-риба вә әл-бунук фил ислам» (Ростовщичество и банки в исламе), «Әл-усул әл-җәләлия» (Божественные основы) кебек китаплары, ислам икътисады проблемаларына кагылышлы хезмәтләре бүгенгәчә үз актуальлекләрен югалтмый. Муса Бигинең фикерләре, тәгълиматлары алга киткән мөселман дәүләтләрендә, гомумән, бөтен дөньяда ислам икътисады системасын яңарту, үзгәртеп коруның нигезен тәшкил итәләр, гаять кыйммәтле кулланма булып торалар.

Ләкин ул хезмәтләрнең күбесе әлегәчә кайсы илнең кайсы китапханәсендә, нинди архивында сакланадыр (ә бәлки бөтенләй юкка чыккандыр?) – болар турында бернинди дә хәбәр-мазар юк. Татарстаныбызда инде берничә ел дәвамында ислам банкы, ислам иминият компаниясе оештыру турында сүз бара. Узган елның март ахырларында гына, ниһаять, боз кузгалды: «Хәләл Инвест» дигән иминият тәрәзәсе (гарәпчә – такафул) ачып җибәрергә мөмкинлек туды, быел Ислам банкы үзәге оештыру турында карар кабул ителде. Ә бит татар икътисадчылары бу фикерне инде йөз еллар элек үк күтәреп чыкканнар. Аерым алганда, бөтен мөселман дәүләтләрендә бүген уңышлы гына эшләп килүче финанс-икътисад системасы нәкъ менә Муса Бигиев тәгълиматына нигезләнеп, аның хезмәтләренә таянып аякка баскан. Ә бездә ул хезмәтләрнең хәтта татарчага тәрҗемә ителгәне дә юк.

Бу урында Петербургта яшәгән мөхтәрәм галим-тюрколог, шәрык белгече, Муса Бигиев мирасын өйрәнүгә күп көч куйган Әнәс Бакый улы Халидовның 1990 елда татар зыялылары алдында ясаган чыгышын искә төшереп үтәсе килә. «Гражданнар сугышы, реакция һәм репрессия еллары сөреме бар дөньяны каплап алган елларда Риза Фәхреддин казыйның 400ләп агач тартмаларга тутырылган хезмәтләре, кыйммәтле китаплары, галимнең васыяте буенча, Оренбургтан Петербургтагы Шәрык институты китапханәсенә озатыла. Ләкин бу мирас ерак юлда эзсез югала, – дип ачынып сөйләгән иде ул. – Ә бит Риза казыйның елына 10-11әр хезмәт бастырып чыгаруы мәгълүм». Шуңа күрә Муса Бигиев әсәрләренең дә бөтен дөньяга сибелеп-чәчелеп юкка чыгуы бик ихтимал. ■

Безнең мирас №4 апрель 2017

Әтрәч авылы тарихы

(Әтрәч авылының XIX гасыр-XX йөз башы тарихыннан кайбер сәхифәләр)

Эльмира Сәлахова

ТАШЛАР МОҢЫ

Тәтеш районының Әтрәч авыллары урнашкан җирләрне хәтта XX гасыр башында да «Мең өйле Шонгаты» дип йөрткәннәр. Андагы халык хәзер дә үзенең тарихи җирдә яшәгәнен онытмый. Бу төбәк белән балачактан кызыксынган Гайнетдин Әхмәрев, Тәтештә укытучы булып эшләгән елларында, Тау ягындагы борынгы ядкярләрне тикшерә, укыту эшеннән бушаган арада, авылларның зиратларын өйрәнә, халык белән аралаша, картлар хәтерендә сакланган истәлекләрне барлый. Аның игътибарын Әтрәч авылы янындагы зур зират, андагы кабер ташлары да җәлеп итә. Ул үзенең бер мәкаләсендә: *«Авыл кешеләре генә бу кадәр алты йөз елларга түзәрлек зур вә яхшы ташларны куя алмас иде»*, – дип яза. Тарихка зур ихтирам белән караган Г.Әхмәрев, әбибабайларның сүзен тыңлаганнан соң, монда, һичшиксез, шәһәр булган, дигән нәтиҗәгә килә.

Болгар шәһәре хәрабәләренә зиярәт кылырга йөргән кебек, XX йөз башында Әтрәчкә дә, аның зиратына да дога кылырга ерак-ераклардан килүчеләр була. Бу хакта Гайнетдин Әхмәревкә шул авыл кешесе сөйли. Әлеге факт Әтрәч җирләренең чал тарихлы, борынгы, изге бер урын икәнен раслый.

XX гасыр башында яшәгән кешеләрнең әйтүе буенча, ике Әтрәч авылы (Зур һәм Кече Әтрәч авыллары) халкы Болгар шәһәре Шонгатыдан күчеп утырган. Тарихчы Г.Әхмәрев: *«Бу шәһәрнең халкы болгарлар белән (ягъни пайтәхетләре булган Болгар шәһәренең мөселманнары белән) кыз алышып, кыз бирешеп йөргәннәр. Шунда шәһре Болгарга йөргән тугры юлларын да күрсәтәләр. Зиратлары янында күп болгар нәрсәләре табыла, хосусан «әзгәри» дип атала торган болгар тәңкәләре, элегрәк, Болгар заманында, акча урынына йөртелгән көмеш кисәкләре дә күп табылган»*, – дип яза.

XIII-XIV йөзләргә караган эпиграфик истәлекләрне саклаган Әтрәч зираты XIX гасырда ук галимнәрнең игътибарын җәлеп итә. Шиһабетдин Мәрҗани 1863 елда бу зиратта булып, болгар чорына караган 21 кабер ташын барлый. XIX гасыр башында аларның саны 50ләп була. Әтисе белән бергә килгән кечкенә Шиһаб, 20-30 кабер ташының чиркәү нигезенә түшәр өчен, Җамбакты (Янбухтино) авылына алып китәргә әзерләнгәнен үз күзе белән күрә. Бу авыл зиратына 1905 елда килгән Гайнетдин Әхмәрев 22 кабер ташы саный. 1949 елда тикшерүчеләр шулай ук 22 кабер ташын терки, ә инде мәшһүр эпиграфист галим Һарун Йосыпов өйрәнгәндә анда 16 кабер ташы була. Хәзерге вакытта аларның саны – нибары 7.

Саннарның шулай кимү сәбәбе төрле: беренчедән, Ш.Мәрҗани язганча, кабер ташларын урыс авылларына алып китеп, чиркәү төзелешендә, хуҗалык эшләрендә куллану. Бу хакта Гайнетдин Әхмәрев тә яза. Ул болгар кабер ташларын Җамбакты чиркәве нигезендә, Каратун авылында юлга түшәлгән хәлдә күрә. Икенчедән, җирле халыкның битараф мөнәсәбәте. 1906 елда «Азат» газетасында дөнья күргән «Иске зират-

«Әтисе белән бирегә килгән кечкенә Шиһаб болгар чорына караган 20-30 кабер ташының чиркәү нигезенә түшәр өчен Җамбакты (Янбухтино) авылына алып китәргә әзерләнгәнен үз күзе белән күрә».

лар хакында» дигән мәкаләсендә галим болай дип яза: *«Һәр милләт – нәсараи булсын, яһүд булсын, хәтта мәҗүс таифәләре дә, ата-бабаларының зиратларын мөкаддәс санап, мөмкин кадәр тәрбияле тоталар, мондаен эшләр дине исламда хосусан мактаулы булса да, вилайәтебезнең мөселманнары иске зиратларын бик тәрбиясез, кызганыч хәлдә тоталар»*. Мисал итеп, ул Әтрәч авылы зиратын китерә: *«...шунда алты йөз еллар мөкаддәм куелган (20-25кә кадәр) язулы ташлар да бар. Ихатасы юк, ташларның бәгъзеләре авып ята, бәгъзеләре сыныгалап, берничә еллар мөкаддәм араларын сукалап, иген дә чәчкәннәр иде. Шул сәбәпле, бәгъзе ташларны күрер өчен, бер баруыбызда, иген арасыннан эзләп таптык, икенче мәртәбә баруыбызда такыр басу иде. Шул зират өстендә Әтрәч карьясенең сыер-сарык көтүе йөргәнен күрдек, бәгъзе хайваннар ташлар арасына ятканнар, бәгъзеләре ташка ышкылып торалар. Хайван йөргән сәбәпле, зират өстендә тирес тә күрелде. Шунда бер көтүчедән сорадык: «Ник болай хайван йөртеп, зиратны кадерсез итәсез?» – дип. Йөртәбез шул инде, йөртмә дип әйтүче дә юк», – дип җавап бирде. Бу ташлар элегрәк бик күп булган, имеш, ләкин мөселманнарның илтифатсызлыгыннан, күбесен якындагы урыслар урлап ташыган, диләр»*.

Җамбакты авылындагы Әтрәч ташының һәм дә Әтрәч зиратындагы тагын бер ташның күчермәсен ул үзенең атаклы «Болгар тарихы» дигән хезмәтенә кертә.

КӘСЕП

Әтрәчлеләр, Тау ягы халкының күпчелеге кебек үк, нигездә, җир эшкәртү белән шөгыльләнгән. Кышын, акча эшләп алу максаты белән, Әстерхан якларына барганнар, авыр елларда бөтенләй үк күчеп китүчеләр дә булган. Әстерхан

Әхмәдҗан Минһаҗетдин улы Сәйхунов. 1908 ел.
ТР МА, 2 ф., 2 тасв., 8168 эш

Мөхәммәдһади Мөхәммәдсабир улы. 1911 ел.
ТР МА, 2 ф., 2 тасв., 8838 эш

өлкәсендәге милләттәшләребезнең рухи-мәдәни тормышында Тәтеш ягы татарларының роле гаять зур. Анда хәзер дә бабалары Тәтеш төбәгеннән булган татар авыллары бар.

Әтрәчлеләр, зур сәүдә белән шөгыльләнмәсәләр дә, революциягә кадәр чәй, шикәр, тәмәке һәм көндәлек тормышта кирәк булган башка вак-төяк товар белән сату итә торган лавкалар тотканнар. 1914 елгы чыганакта шушы сәүдәгәрләрнең исеме телгә алына: Закир Әминев (еллык товар әйләнеше 140 сум), Кәмалетдин Хөснетдинов (150 сум), Гыймадетдин Шәмсетдинов (150 сум), Хөсәен Фатхуллин (120 сум), Мөсәлим Фәтхуллин (100 сум), Гыйниятулла Мәрхәбуллин (100 сум).

ИМАН НУРЫ

Халыкны аң-белемле иткән руханиларны искә алмау һич дөрес булмас иде. Әтрәч – зур авыл, аның XX йөз башында ике мәчете була.

Авылда мәхәлләнең кайчан оешуы билгесез. XIX гасыр документларында: «Халык моны хәтерләми», – дип язылa. Авылда мәчет 1873 елда, кайбер документларда, соңгы мәчет 1886 елда салынган, дип күрсәтелә, ләкин мәхәлләнең оешуы, әлбәттә, күпкә элегрәк булган. Бу вакытта мулла – Мөхәммәдсадыйк Биктимер углы, азанчы – Җиһанша Корбангалиев. Мәчет каршында мәдрәсә эшләгән, анда мулла абзый 65 ир балага сабак укыткан.

Соңрак имамлыкны Мөхәммәдсадыйкның углы Мөхәммәтша Садыйков башкара. Ул 1888 елда указ алып, имамхатыйп һәм мөгаллим вазифасын үтәгән. Мөхәммәтша хәзрәт имамлык иткәндә дә авылда мәдрәсә эшчәнлеге дәвам итә. 1905 елгы мәгълүмат буенча, анда 48 ир бала белем ала.

Мөхәммәдсадыйк хәзрәт үзе исән чагында ук, 1861 елның 15 гыйнварында туган Мөхәммәдсабир исемле углын, олы яшьтә булуы һәм муллалык вазифасын үтәү авырлашу сәбәпле, икенче, ягъни ярдәмче мулла итеп ала. Соңрак ул мәчеттә төп мулла эшен башкара. Мөхәммәдсабир хәзрәт 1907 елның 24 октябрендә бакыйлыкка күчә.

Аның вафатыннан соң, бер ел дәвамында авылның үз мулласы булмый, әлеге вазифаны күршедәге Кече Әтрәч мулласы Кәрим Сафиулла углы

МЕТРИЧЕСКАЯ ВЫПИСЬ

о родившихся на тысяча ... годъ (1884 годъ) по деревнѣ ...

№№ по метрической книгѣ	Мѣсяцъ и день рожденія	Имя родившагося	Званіе, имя, отчество и прозваніе (фамилія) отца, а у внѣбрачнаго-матери	Если родившійся умеръ, то годъ, мѣсяцъ и день его кончины
17	... 26 1884 г.	Минкамалетдинъ	...	— „ —

Татарстанның халык артисты Фуад Әбүбәкеровның Зур Әтрәч авылында имамлык иткән бабасы Миннекамалетдин Мөхәммәдҗан углы Мостафинның туу турындагы метрика язмасыннан күчермә. 1884 ел.
ТР МА, 2 ф., 2 тасв., 9633 эш. 9 кгз

башкара. Әлбәттә, бу халык өчен уңайсызлык тудыра. Әтисе вафат булгач та, Мөхәммәдсабир Мөхәммәдсадыйк улы бер ел имамлык итсә дә, ул хокукый яктан әлеге вазифага туры килми, чөнки балигълык яшенә җитмәгән һәм дә солдат хезмәтен үтмәгән була. Шунлыктан халык хәзерге Кама Тамагы районына керә торган Бишалаб (Казыево-Бишалаб) авылында туган Әхмәдҗан Минһаҗетдин углы Сәйхуновны мулла итеп куюны сорый. 1908 елда указ алган хәзрәт бу авылның икенче мәхәллә мәчетенә имам итеп билгеләнгән була, ләкин аның төзелешенә 1907 елда ук рөхсәт алынса да, мәчеткә нигез салынмый. Шунлыктан аны беренче мәчеткә куюны үтенәләр. Икенче мәчет төзелеп беткәч, ул шунда имам булып хезмәт итә.

Икенче мәхәллә мәчетен төзү мәсьәләсендә авыл кешеләре арасында каршылык килеп чыга. Мәчеткә рөхсәт сорап гариза язучылар өстеннән берничә кеше шикаять белдерә. Алар фикеренчә, яңасын төзегәнче, шактый тузган беренче мәхәллә мәчетен рәтләү кирәк. Бу гаризадан соң, староста белән балта осталарыннан торган бер төркем, беренче мәчетне карыйлар һәм аңа капиталь төзекләндерү таләп ителми, бераз рәтләп җибәрү генә сорала, диләр. Шулай итеп, икенче мәхәлләгә мәчет төзергә кирәк, дигән карар кабул ителә. Бу мәчет 1908 елда төзелеп бетә. Бишалаб авылының крестьяны Минһаҗетдин Сәйхунов аны үз акчасына салдыра һәм улы Әхмәдҗан Сәйхунов имам итеп тәгаенләнә.

1884 елның 26 сентябрендә туган Әхмәдҗан Минһаҗетдин углы Сәйхунов Казанның 4 нче мәчете каршындагы мәдрәсәне тәмамлаган. Күркәм холыкфигыле белән аерылып торган әлеге хәзрәтне, староста Сәйфетдин Сәйхунов катнашында, 1908 елны уздырылган авыл җыенында имам итеп сайлыйлар. Җыенда 168 кеше катнаша һәм аны яклап тавыш бирә. Ул имамлык иткәндә дә, Әтрәчтә мәдрәсә эшләп тора, анда 50 ир бала белем алган. Әхмәдҗан хәзрәт, яшь кенә булуына карамастан, авырып китә. 1914 елның 22 ноябрендә ул Казан хастаханәсенә салына, озакламый, 1915

елның 29 гыйнварында дөньядан китә.

1889 елның 25 августында туган, әтисе үлгәндә яшүсмер генә булган Мөхәммәдһади Мөхәммәдсабир углы имамлыкка рәсми рөхсәтне 1909 елда ала. 1911 елда авыл җыенында аны имам итеп сайлыйлар. Мөхәммәдһади Мөхәммәдсабир углы – заманы өчен алдынгы карашлы мулла. Ул Тәтештә атаклы рус-татар мәктәбен тәмамлаган. Муллалыкка куйганда, полиция шундагы укытучылар Исхак Казаков*, Фатих Шәмсетдинов, Солтан һәм Йосыф Саиновлар белән Мөһәммәдһадинең дә ирекхөрлекне данлаган революцион җырлар өйрәнгәнен ачыклый. Шулай да бу аны мулла итеп билгеләргә киртә була алмый.

1915 елда Әхмәдҗан Минһаҗетдин углы Сәйхунов үлгәннән соң, икенче мәчеткә Тәтеш өязе Казыево-Ключище авылында 1884 елның 26 декабрендә туган Миңлекамалетдин Мөхәммәдҗан углы Мостафин билгеләнә. Ул – Казанда 4 нче мәчет каршындагы мәдрәсәдә һәм Иске татар бистәсендәге бер мәдрәсәнең рус классында белем алган хәзрәт.

Тагын бер кызыклы мәгълүмат: архив документы ярдәмендә беренче мәхәллә мәчетенең тасвирламасы белән дә танышырга мөмкин. Аның бинасы, манарасы агачтан эшләнгән, түбәсе түл белән ябылган, керә-чыга торган ике ишеге булган. Мәчетнең озынлыгы 10 сажин, киңлеге 4,5 сажин, биеклеге 11 аршын. Аллаһ йорты ике мич белән җылытылган.

СЫНАУ

Мәгълүм булганча, татар халкы чукындыру сәясәтенең бар авырлыгын татый. Чукындырылып, христиан динен кабул иткәннәр шактый – без аларны керәшеннәр, дибез. Ә кайбер төбәкләрдә чукындыру сәясәте формаль рәвештә генә үтә, ягъни чукындырылган татарларга рус исемнәре бирелә, аларны шулай теркиләр. Рәсми керәшен дип саналсалар да, басым нык булмау сәбәпле, ул кешеләр исламнан ваз кичмиләр, кача-поса булса да, сиздерми генә намаз укыйлар, дини йолаларны үтиләр. Әтрәч һәм тирә-яктагы башка авылларда да нәкъ менә шундый хәл күзәтелә. Анда XIX-XX гасырларда керәшен татарлары авыл халкының якынча 15%ын тәшкил иткән (688 кешенең 97се – керәшен). Чукындырылган дип саналган халык авыл мөселманнарыннан берни белән дә аерылмаган, әмма керәшен булып язылу сәбәпле, аларга мәчеткә барырга рөхсәт ителмәгән.

Бу уңайдан 1876 елда мулла Мөхәммәдсадыйк хәзрәткә гаепләү эше ачыла. Аның белән сүзгә килгән берәү, мулла Корбан бәйрәмендә керәшеннәргә мәчеткә керергә рөхсәт итте, алардан сәдака да алды, дип шикаять яза. Тикшерүләрдән соң мулланың гаепсезлеге таныла, гает намазын укый башлаганчы, хәзрәт старостага керәшеннәрне чыгарырга боерган була. Әлбәттә, керәшен саналган татарлар, борынгы гадәт буенча, Корбан гаетендә катнашалар. Имам аларның мәчет янында намаз кылуларын күрмәмешкә салыша, бернинди каршылык күрсәтми, ләкин әлеге гамәле белән үзен куркыныч астына куя. Керәшеннәр тикшерү эшләре вакытында мулланы сатмый. Сорау алганда алар үзләрен мәчеткә килмәгән итеп, ниндидер эшләр белән гыйбадәтханә яныннан узып баручы буларак кына күрсәтәләр. Берсе: «Мин авыру абыемның хәлен белеп кайтып бара идем», – дип, ә икенчесе: «Мин зиратка бара идем», – дип хәйләли.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин: Әтрәч авылы тарихы турында шактый кызыклы чыганаклар бар. Аларны җыю, өйрәнү, борынгы ядкярләрне саклау – киләчәктә хәл ителергә тиешле актуаль мәсьәлә. ■

* Кара: «Ядкярләргә – бер гасыр», – «Безнең мирас», №3 (279), 2017, 112-113 б.



1906 елның 22 декабрендә куелган «Кызганыч бала» спектакленең (Н.Кәмал) афишасы

XIX гасыр ахырында, шәкертләр, приказчиклар, гимназистлар һәм Татар укытучылар мәктәбе мөгаллимнәре катнашында аулак өйләрдә, мәктәп-мәдрәсәләрдә «театр уйнау» гадәти хәлгә әйләнә. Әйтик, 1887 елда Габдрахман Ильяси тарафыннан «Бичара кыз» исемле беренче пьеса языла һәм ул, чынлап та, әүвәл өй шартларында уйнала. Татар дөньясында рус театры үрнәгендә милли драматургия һәм театр белән чын-чынлап кызыксыну башлана. Шул елларда, ягъни татар милли театрының оешуына кадәр үк, татарлар күпләп яшәгән Уфа, Оренбург, Әстерхан,

«ШИМБӘЧЕЛӘР» ТҮГӘРӘГЕ

Ташкент, Орск, Җаек шәһәрләрендә драма түгәрәкләре бердәм эшли башлый. Шулар арасыннан Казандагы «Шимбәчеләр» түгәрәге халык арасында аеруча танылу ала. Ул вакытта (1903 ел ахыры-1904 ел башлары) урыс мәктәпләрендә укучы татар яшьләре, шимбә көннәрендә зыялы гаиләләрдә җыелып, әдәби-музыкаль кичәләр һәм спектакльләрдән өзекләр әзерли торган була. «Шимбәчеләр» исеме шуннан килә. Бертуган И. һәм Г. Габитовлар тәкъдиме белән оешкан бу түгәрәккә булачак мәшһүрләребез Мулланур Вахитов, Хөсәен Ямашев, Фатих Әмирхан һәм Гафур Коләхмәтов еш килеп йөри.

Мәгълүм ки, 1906 елның 22 декабрь кичендә Казанда, Яңа клубта (Горький урамы, 3 нче йорт), киң катлау тамашачылар өчен, губернатор рөхсәте белән, ярлы студентларга тәгаенләп, беренче тапкыр татарча спектакль (төрек язучысы Н.Кәмал әсәренә нигезләнгән «Кызганыч бала» драмасы) күрсәтелә.

Казанны шаулаткан бу данлыклы вакыйга татар милли театрының туган көне булып тарихка керә.

«Шимбәчеләр» түгәрәгенә йөрүчеләрдән бер төркем. Сулдан уңга: Х.Ямашева, Г.Мостафин, М.Терегулова, Ә.Терегулова, Х.Ямашев, Р.Меликов

«МИНЕМ АВЫЛЫМ»
иҗади һәм фәнни эзләнү-тикшеренү эшләре конкурсының НИГЕЗЛӘМӘСЕ

1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘ

1.1. Бөтендөнья татар конгрессы, Бөтенроссия татар авыллары иҗтимагый оешмасы берлән берлектә, «Минем авылым» иҗади һәм фәнни эзләнү-тикшеренү эшләре конкурсын уздыра.

1.2. Чараның мәгълүмати партнерлары булып «ТАТМЕДИА» АҖ һәм «БЕЗНЕҢ МИРАС» журналы чыгыш ясый.

1.3.Конкурс Татарстан Республикасы, Россия Федерациясенең татар милли-мәдәни оешмалары, якын һәм ерак чит илләрдәге татар милли-мәдәни үзәкләре һәм иҗтимагый оешмалары әгъзалары, укучылар һәм студентлар өчен ачык массакүләм чара булып тора.

2. КОНКУРСНЫҢ МАКСАТЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

2.1. Конкурсны уздыруның төп максатлары:

– туган як тарихын өйрәнүгә кызыксыну уяту;
– киң җәмәгатьчелек игътибарын татар авылларын борчыган проблемаларга юнәлтү;
– татар авылларын берләштергән бердәм мәгълүмат базасын булдыру;
– үсеп килүче буында ватанпәрвәрлек, милли үзаң, кече ватаның белән горурлану кебек хисләр тәрбияләү.

3. КОНКУРСНЫ ОЕШТЫРУ ШАРТЛАРЫ ҺӘМ ТӘРТИБЕ

3.1. Конкурс 2017 елның 20 гыйнварыннан 30 ноябренә кадәр уздырыла.

3.2. Бәйгене оештыру, әзерләү һәм уздыру өчен Оештыру комитеты төзелә. Аның исемлеге оештыручы оешма җитәкчеләре тарафыннан раслана. Оештыру комитеты гаризалар кабул итә, конкурсантлар белән әзерлек эшләре алып бара, жюри исемлеген төзи һәм рәисен раслый.

3.3. Конкурста Россия Федерациясенең төрле төбәкләрендә, якын һәм ерак чит илләрдә яшәүче һәркем катнаша ала. Яшь буенча чикләүләр каралмаган.

3.4. Конкурста катнашучы гариза-анкетаның тутырылган формасын, шулай ук шәхси мәгълүматны эшкәртергә ризалык һәм иҗади эшен 2017 елның 20 гыйнварыннан 30 октябренә кадәр оештыру комитетына җибәрергә тиеш.
3.5. 2017 елның 1-25 ноябрь көннәре аралыгында конкурс эшләрен жюри әгъзалары тикшерә.
3.6. Конкурсның нәтиҗәләре 2017 елның 30 ноябрендә игълан ителәчәк.

4. КОНКУРС ЭШЛӘРЕН ТАПШЫРУ ТӘРТИБЕ

4.1. Конкурска эшләр электрон форматта түбәндәге юнәлешләр буенча кабул ителә:
Туган авылымның тарихы.
Авылым урамнары.
Күренекле якташларым.
Авылым чишмәләре.
Әйт, авылым... (авылны борчыган проблемалар).
Авыл турында җырлар, шигырьләр.
4.2. Конкурска татар яки рус телендә язылган эшләр кабул ителә.
4.3. Эшләргә түбәндәге техник таләпләр куела: Times New Roman шрифты, 14 кегль, юл арасы 1,5 интервал. Эш күләме – 10 биттән артмаска тиеш. Конкурска җибәрелгән эшләр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
4.4. Барлык эшләр дә нигезләмәдә күрсәтелгән электрон адреска җибәрелергә тиеш. Нигезләмә шартларына туры килмәгән һәм башка адресларга җибәрелгән эшләр тикшерелми һәм бәйгедә катнашмый

5. КОНКУРСКА КИЛГӘН МАТЕРИАЛЛАРНЫ БӘЯЛӘҮ КРИТЕРИЙЛАРЫ

5.1. Конкурска килгән эшләр юнәлешләргә һәм 3 төрле яшь категориясенә бүленеп бәяләнәчәк: мәктәп балалары (10-17 яшь), студентлар (18-25 яшь), өлкәннәр.
5.2. Барлык эшләр 0-10 бал югарылыгында бәяләнә.
5.3. Конкурс эшләре түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:
– материалның эчтәлеге сайланылган юнәлешкә туры килүе;
– материалның мәгълүмати яктан эчтәлекле һәм сыйфатлы булуы;
– фәнни эзләнү-тикшеренү ягыннан якын килү, архив материалларыннан файдалану;
– язма материалларның әдәби тел нормаларына һәм куелган техник таләпләргә җавап бирүе;
– автор тарафыннан куелган проблемаларның актуальлеге һәм мөһимлеге.

6. КОНКУРСКА НӘТИҖӘЛӘР ЯСАУ ҺӘМ ҖИҢҮЧЕЛӘРНЕ БҮЛӘКЛӘҮ

6.1. Җиңүчеләрне бүләкләү Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе тарафыннан расланган жюри карары нигезендә башкарыла **(Кушымта 2)**.
6.3. Номинантлар гомуми җыелган баллар күләме буенча, һәр юнәлештә һәм һәр яшь категориясендә билгеләнәчәк.
6.4. Конкурста җиңүчеләргә дипломнар, грамоталар һәм истәлекле бүләкләр тапшырылачак.
6.5. Нәтиҗәләр һәм иң кызыклы эшләр **татар-авылы.рф** һәм **www.tatarcongress.org** сайтларында басылып чыгачак.
6.6. «Безнең мирас» журналына 2017 елның икенче ярты еллыгына язылганлыгы турында квитанцияләре булган иң яхшы эш авторларына һәм аларның фәнни җитәкчеләренә чараның мәгълүмати партнерлары «ТАТМЕДИА» АҖ һәм «БЕЗНЕҢ МИРАС» журналы редакциясеннән аерым дипломнар һәм истәлек бүләкләре биреләчәк. Тарихи яктан әһәмиятле, кызыклы, яңалыгы булган язмалар «Безнең мирас» журналында басылачак, калганнары **beznenmiras.ru** сайтына куелачак.

7. ЭЛЕМТӘ

7.1. Катнашучыларның эшләре һәм үзләре турында мәгълүмат **(Кушымта 1)** электрон вариантта **info@tataravyly.ru** адресына кабул ителә.
7.2. Бәйләнеш өчен телефоннар: 8-927-303-35-49 (Индира Латыйпова);
8-952-036-54-48 (Ленар Гобәйдуллин).

Оештыру комитеты

Финляндиядә татар әсирләре

(Кышкы һәм Дәвам сугышлары[1] вакытында финнәргә тоткынлыкка эләккән татарлар язмышы)

Чыңгыз Сафиулла

ӨЙГӘ КАЙТУ

Вакыт узмый, йөрәк түзми өйгә китәргә, дип көткәч,
Элекке тормышым тарта, бөтенләй бар да, дип беткәч.
Аиләм берлә тормыш күз алдыма килә балкып,
Балаларым, бәгырьләрем, өйгә кайтам, ни зур шатлык!
Күз алдыма килә шунда атам-анам, туганнарым,
Дус-ишләр һәм дә күргәннәр, авылда йөргән юлларым.
Күз алдыма килә шунда күтәргән кул догага, Аллаһым!
Илаһым, ярлыкагыл мине, сәламәт кайтса, ди бәбкәм.
Шәһидләр кайтмыйлар, анлар бу милләткә җанын бирде,
Кайсы дошман туфрагында, кайсы бу җирдә кан түкте.
Әй, Аллаһ, үзең кылгыл шәһидләр урынын җәннәт,
Кыямәт көн афу кылгыл гөнаһларым үзең хәннән.
Дошман аткан ачы тупта ничә егет җанын бирде,
Ничә ана, ничә бала, йәтим калып йәшен түкте.
Бөек Тәңрем, телим синнән элеккечә рәхәт тормыш,
Җиһан дошманлыгын бетереп, әүвәлгечә матур-кадерле.

Татарлар Ярвенпяа тимер юл вокзалы алдында. Уртада, алда – Рәхилә Габделхак кызы Абдуллина үз гаиләсе белән, аның артында – олы туганы Мәликә Габделхак

[1] Фин историографиясендә 1939-1940 еллардагы Совет-фин сугышы – *Кышкы сугыш*, Бөек Ватан сугышының 1941-1944 еллардагы Совет-фин фронты *Дәвам сугышы* («Война-продолжение») дип атала.

Бу шигъри юлларны Габделхак Сафиулла Дәвам сугышы тәмамлангач, өйгә кайтыр алдыннан, 1944 елның 15 октябрендә язган. Сафиулла – 1942 елның май аенда Миккели концлагерендагы татар сугыш тоткыннарын Ярвенпяага күчергән шәхес. Актүк авылында 1905 елда туып, сәүдә белән гаиләсен тәрбияләгән Габделхак әфәнде Финляндия татарлары арасында сөекле адәм булды. Ул татар әдәбиятын белүче дә, артист та иде. Гомере азагына кадәр Ярвенпяа каласы имамы булып хезмәт итте. 1976 елда, 71 яшендә Хювинкяа шәһәрендә вафат булып, Ислам җәмәгатенең Хельсинки каберстанына җирләнде.

***

Бу тикшеренүдә Дәвам сугышлары вакытында Финляндиянең Миккели коммунасына 1941 елда әсир ителгән, гади, ягъни тоткынлыкка эләккәндә хәрби булмаган татарларның тарихы өйрәнелә. Алар, 1940 елның көзендә Иосиф Сталин әмере буенча, Карелиягә сөрелгән, 1945 елда, солых шартлары буенча, Совет иленә кире кайтарылган.

2013 елның май аенда Хельсинки университетында Финляндия татарлары турында семинар оештырылу әсирләр мәсьәләсен мәйданга чыгаруга сәбәп булды. Татарстаннан чакырылган галимнәр Марат Гыйбатдинов һәм Илдус Заһидуллин белән сөйләшкәннән соң, алар миннән татар әсирләренең 1939-1945 елларда Финляндиядә булган вакытлары турында бер мәкалә язуымны үтенде. Мине бу эшкә этәргән өчен аларга олуг рәхмәтемне укыйм.

Тикшерүемне башкарып чыгарга Финляндия Милли архивының кыйммәтле мәгълүматлары белән танышу һәм андагы материалларны куллану ярдәм итте. Балачагында әсирләр лагеренда булган һәм күп вакыйгаларны үз күзе белән күргән Рәхилә ханым Абдуллинага да телефон аша биргән әңгәмәсе өчен зур рәхмәтемне белдерәм.

САННАР НИ СӨЙЛИ?

Татарлар һәм башка төрки халыклар Финляндия сугышында катнашып, Кызыл Армиядә хезмәт иткән. Тарихтан шул да мәгълүм: бер милләттән булган халык, хәтта бер-берсенә кардәш булган кешеләр фронтның ике ягында да сугышкан. Аларны дошман илләр арасындагы чикләр аша уртак тел, мәдәният һәм дин берләштергән.

Фәнни тикшерү барышында, беренче чиратта, 1940-1945 елларда Миккели каласында булган 90 татарның лагерьдагы һәм аннан читтәге тормышы ачыкланды, фин хәрби көчләре тарафыннан бирелгән төрле күрсәтмә-документлар өйрәнелде.

Кышкы һәм Дәвам сугышларында урыс армиясендә тоткын булып калган финнәрнең саны 2950 кеше тәшкил итте. Совет иленнән Кышкы сугыштан соң – 847, Дәвам сугышыннан соң 1931 солдат Финляндиягә кире кайтарылды. Фин солдатларының 404е Русия концлагерьларында вафат булды.

Кышкы сугыш вакытында Финляндиядә тотык булган Совет иле гаскәриләренең якынча саны – 5500, ә Дәвам сугышы вакытында – 64 188 кеше. Болардан һәр өченчесе, якынча 18700 кеше, төрле сәбәп аркасында һәлак булган. Тоткынлыктагы татар хәрбиләренең саны – 12. Сугыштан соң, Совет иленә 42412 сугыш тоткыны кире кайтарыла. Лагерьлардан качкан һәм табылмаган тоткыннар саны 721 кеше тәшкил иткән. 12 татар хәрбие исә Германиягә озатылган.

Финляндия Эчке гаскәр идарәсе мәгълүматларына караганда, илдә барлыгы 60 лагерь булып, 1942 елның 31 декабрендә теркәлгән документтан төрки халыклардан булган тоткыннарның санын күрергә мөмкин. Барлыгы – 752 татар, 83 башкорт, 60 кыргыз, 20 алтайлы, 19 калмык, 10 кумык, 220 казакъ, 196 чуаш, 12 төрек, 4 төрекмән, 91 үзбәк әсир ителгән. Шул ук документта монгол, ойрот, тунгус, таҗиклардан да берничә кеше, яһүдләрдән – 258, кавказлылардан 500ләп әсир булуы язылган.

Татар сугыш тоткыннарына Фин-

ляндия мөселман мәхәлләсе һәм биредә яшәүче татарлар, үз теләкләре белән, мөмкин булганча, туганнарча ярдәм итте. Финляндия хәрби җитәкчелеге дә бу мәсьәләгә уңай карады. Ни сәбәпледер, әллә татарлык хисе көчле булдымы, ике ил арасындагы мөнәсәбәтләр начарланып, хөкүмәтләр сугыш вазгыятенә кергәч тә, гражданлык вә илләр арасындагы чикләр онытылып, уртак милли хисләр алга куелды.

Финляндия җәмәгате исламия тарафыннан Миккелидәге татарларны Ярвенпяага күчерү эше 1942 елның 4-5 май көннәрендә башлана. Шулай итеп, мәхәллә милләттәш туганнарның тормышын яхшыртуны үз бурычы итеп алды. Татар әсирләренең гомерен саклап калу белән бергә, милләттәшләргә уку һәм эшкә урнашу мөмкинлекләре дә тәкъдим ителгән.

Татар халкының эшчән, булдыклы икәнлеге туган җирләрендә генә түгел, чит җирләрдә дә мәшһүр. Финляндиягә XIX гасыр ахыры һәм XX йөз башында сәүдә эшләре белән күчеп калган татарлар әсирләргә үрнәк булган. Бу татарларның күбесе вак мал сатып яки үз кибетләрен тотып көн күргән.

ФИНЛЯНДИЯ КЫШКЫ ҺӘМ ДӘВАМ СУГЫШЛАРЫНА НИЧЕК ЭЛӘКТЕ?

Финляндия һәм Совет иле арасында һөҗүм итмәү турындагы килешү 1932 елның 21 гыйнварында Финляндия Тышкы эшләр министры Аарно Юрьё-Коскинен һәм Совет иленең Хельсинкидагы илчесе Иван Майски тарафыннан имзаланган. Моңардан башка, 1934 елда Хельсинкида өстәмә килешүгә дә кул куела, аның мөддәте 1945 ел азагына кадәр озайтыла. Тарих күрсәткәнчә, әлеге килешү бәясе кулланылган кәгазь бәясенә дә тормады.

Совет иле Кышкы сугышны, алдан белгертмичә һөҗүм итеп, 1939 елның 30 ноябрендә башлады. Сугыш 105 көннән соң, Мәскәүдәге солых килешүе белән 1940 елның 12 мартында тәмамланды. Милләтләр берләшмәсе бу һөҗүм итүгә карата мәхкәмә карарын чыгарды: Совет илен 1941 елның 14 декабрендә әгъзалыгыннан аерды.

Ике куәтле көч – Совет иле һәм Германия 1939 елда үзара һөҗүм итешмәү турында Молотов-Риббентроп килешүен имзалый, аның яшерен беркетмәсендә Финляндия Совет мәнфәгатенә кертелгән була.

Ничек кенә фаҗигале-кәмит тоелса да, бу һөҗүм итмәү турында имзаланган килешү, Германиянең һөҗүменнән соң, Совет иленә Финляндиягә каршы дошманлыкны янә башларга ачык вәкаләтнамә бирде: 1941 елның 25 июнендә Дәвам сугышы башланды. Сугыш тәмамлану турында вакытлы солых килешүе әүвәл 1944 елның 19 сентябрендә Мәскәүдә, соңыннан 1947 елның 10 февралендә Парижда имзаланды.

Урыс хөкүмәтенең беренче һөҗүме белән башланып киткән әлеге сугышларда ике тарафтан да, Финляндия һәм Совет иле армиясендә дә татар ир-атлары сугышты.

ТАТАР ТОТКЫННАРЫ ФИНЛЯНДИЯДӘ НИЧЕК УРНАШТЫ?

Кышкы сугыштан соң, вакытлы солых төзелгәч, Иосиф Сталин Совет иленнән Ладогага һәм Карелиягә гади халыкны, авыл-авыл гаиләләрне, татарларны, шул исәптән Татарстанның Җамбакты авылындагы 19 гаиләне дә сөрде. Бу очракта аның нияте ниндидер золым кылу яки җәзалау гына түгел, ә төбәкләргә булдыклы эшчеләр дә табу иде. Совет кешеләре финнәрдән төзек хәлдә калган буш авылларга һәм йортларга урнаштырылды. Кайберләре исә дәүләтнең яңа чигенә якын ук эләкте. Яңа килүчеләр анда авыл хуҗалыгы һәм терлекчелек белән шөгыльләнде, Совет гадәте буенча күмәк хуҗалык, ягъни колхозлар корды.

Дәвам сугышында кулга алынган колхозчыларны, гаскәри булмаган тоткыннарны фин гаскәре карамагында булган лагерьларга җыйдылар. Җамбакты авылы татарларын исә Карелиядә урнашкан


Sv. leiri N:o 1. 28.XI 42.
Sv. järj. leiri N:o Päivämäärä
Vangin N:o / B-323.

SOTAVANKIKORTTI.

1. Suku- ja etunimi Bigejev Ahmed Musovitsh
2. Syntymäaika ja -paikka 29.12.12. Pietarissa
3. Vanhempien nimet, äidin tyttönimi isä: Musa äiti: Rojma os. Komalova
4. Kenelle ja mihin ilmoitettava tapaturmasta t. m. s. äidille: Rojma Zakirovna Bigejeva Jaroslavsk. obl. Krasnoje na Volge Solodovennyi Zavod
5. Siviiliammatti Dosentti metallurgisti 6. Kansallisuus Tataari
7. Tuntolevyn N:o 8. Sotilasarvo Kapteeni
9. Joukko-osasto (div. rykm. kompp.) 61 lento prikaadi
10. Vangitsemisaika ja -paikka 15.6.42 Mustajoki – Merituli
11. Vankilaantuloaika 21 XI 42 Sv. leiri 1:elle.
12. Vanki lähetetty edelleen (milloin ja minne)

Luovutettu Saksalaisille Hangossa 19.9.43. (S.13.900).
19.9.43

Adolf Koskinen Korpraali.
Kuulustelija (nimi ja arvo)

Әхмәт Бигиевнең (Муса Бигиев улы) Финляндиядә үз кулы белән тутырган хәрби тоткынлык картасы. 1943 ел, 19 сентябрь

Куркижоки авылындагы колхозларда тоткарлыйлар. Мондый лагерьлар барлыгы алтау булып, андагы тоткыннар 1941 елның 15 июлендә Миккели каласына күчерелгән. Анда колхозчыларга хезмәт концлагере оештырыла. Алда әйткәнемчә, аларның зур төркеме Миккелидагы эш лагереннан Ярвенпяага һәм Ярвенпяа аша Финляндиянең башка шәһәрләренә күчерелә.

Бу эштә җирле татарлар да катнашкан. Шулай итеп, Финляндиядә торучы татарлар лагерьларда яшәүче милләттәшләренә әйбәтрәк яшәү шартлары тәкъдим итәргә телиләр. Финляндиядә татар әсирләренә карата яхшы мөгамәлә кылу, хәтта сугыш вакытында да дошмани дәүләтнең халкына, аның әсирләренә уңай, игелекле мөнәсәбәт күрсәтү этник бәйләнешләрнең, милли бердәмлекнең нинди олуг көч икәнлеген раслый.

ФИНЛЯНДИЯ ҖӘМӘГАТЕ ИСЛАМИЯНЕҢ ТАТАР ӘСИРЛӘРЕ МӘСЬӘЛӘСЕНДӘГЕ РОЛЕ

Финляндия татарлары Кышкы һәм Дәвам сугышлары вакытында бернинди каршылыкка карамый, тоткын милләттәшләренә, хәтта, мөмкинлек булганда, фронтның икенче ягында сугышкан дин кардәшләренә дә ярдәм итте.

Кышкы сугыштан соң, Финляндия җәмәгате исламиянең 1940 елның 12 ноябрендә Тышкы эшләр министрлыгына юллаган гаризасында дүрт татар әсирен азат итү турында сорала. Шул ук вакытта, ике фирма, тире кибете хуҗасы Муса Җәмалетдин һәм тире кибете хуҗасы Орава Ой, икесе дә әлеге әсирләрне эшкә алырга әзерлекләрен белгерткән. Алар – Зәкәрия Абдулла, 1919 елның 7 гыйнварында Җабалак авылында туган; Ибраһим Рахман, 1918 елның 20 апрелендә Сәмәркандның Түнәк авылында туган; Хәлиулла Утарбаи, 1917 елның 10 мартында Гурьевкада туган; Салих Заһидулла, 1916 елның 13 сентябрендә Башкортстанда туган. Җәмгыять боларны ышанычлы кешеләр дип әйтә. Милләте буенча төрки, диннәре ислам булганы өчен аларны азат итүне сорый.

Җәмәгате исламия вәкилләре, Дәвам сугышында 1941 елны татар әсирләренең кулга алынуы турындагы хәбәрне алгач та, Эчке гаскәр идарәсе белән Миккелидән әсирләрне гадәти халык арасына күчерү турында киңәшә башлый. Моның өчен әсирләрне конц-

лагерьдан чыгарырга рөхсәт гаризалары әзерләргә кирәк була. Бу эштә җәмгыять рәисе Зухур Таһир һәм урынбасары, кятип Ибраһим Арифулла зур активлык күрсәтә. Финляндия җәмәгате исламия, вакытны сузмыйча, татарларга 1942 елның 4-5 май көннәрендә Миккелидән Ярвенпяага зиярәт итәргә мөмкинлек булдыра. Бу көнне Эчке гаскәр идарәсе капитаннары Элжас Эркко һәм Ааpне Хонка рәсми документны имзалый. Шулай итеп, гаризалары булган әсирләргә генә күчү рөхсәт ителә. Эчке гаскәр идарәсенең вәкаләтнамәсе буенча, Габделхак Сафиулла һәм Гани Хәсән, Миккели концлагерена барып, татар әсирләрен сәфәргә әзерләп, әүвәл Тааветти, аннан поезд белән Хельсинки аша Ярвенпяага күчерде.

Карелиядә кулга алынган 1400 әсир заманында туган төбәкләреннән мәҗбүри күчерелгән гади халык булып, алар сугышта катнашмаган. Дөрес, элек Кызыл Армия сафында хезмәт итсәләр дә, әсирлеккә эләккән вакытта араларында гаскәргә лаеклы ирләр бөтенләй булмаган, дип тә әйтергә мөмкин. Шуның өчен, сугыш барышында кулга алынган гаскәриләрне үз төбәкләреннән күчерелгән гади халыктан аеру ихтыяҗы туа.

МАННЕРГЕЙМ БОЕРЫГЫ

Бөек башлык, Финляндиянең маршалы, булачак Президент Карл Густав Эмиль Маннергеймның әсирләргә яхшы мөнәсәбәт күрсәтелергә тиешлеге турындагы 1943 елгы 2 сентябрь боерыгының өченче маддәсе болай яңгырый: *«Әсирләр командирының максаты – кешелек сыйфатларын күздә тотып, әсирләрнең тормыш шартларын яхшырту һәм кирәк күрелгәндә аларның көчләрен эштә куллану»*.

Гаскәрнең бөек башлыгы Маннергейм лагерьларны зиярәт итә, әсирләрнең тормышы белән таныша, өстәвенә, алар белән үз телләрендә кешечә сөйләшә. Дошманның мондый гадәттән тыш мөнәсәбәте әсирләрдә дә уңай караш тудыра.

Бу зиярәтләрдән сакланган ике истәлек тә бар: Маннергейм музеенда, Хельсинкида совет әсирләре тарафыннан куелган ике рәхмәт тактасы.

КАРДӘШЛӘР

Финляндия Милли архивында кайбер татар әсирләренең язмалары, алар турында документлар саклана. Чыганаклардан күренгәнчә, лагерьдан чыгу теләген алар үзләре яки кардәшләре белдергән, күп очракта Финляндия җәмәгате исламия гариза язып, рөхсәт алырга ярдәм иткән.

Рәфгать Азимов – гаскәри тоткын, сержант. Гаскәри булганлыктан, аңа башкача карыйлар. Тампере шәһәрендә торучы кардәше, Русиядән Финляндиягә инкыйлабка кадәр качкан сәүдәгәр Хөсәен Сөләйманга (1904-1966) Рәфгатьнең әсирлеккә эләгүе турында белгертелә[2]. Башта Азимов Утти төбәгендәге 63 нче хәрби әсирләр хастаханәсенә урнаштырыла. Тампередагы кардәше аны үз янына күчерергә тырыша.

Эчке гаскәр идарәсе архивыннан Хельсинкида (7.10.1941) һәм икенчесе Тампереда (16.10.1941) язылган Азимовка мөнәсәбәтле ике документ табылды. Хельсинкидан юлланылган язуны Финляндия җәмәгате исламиянең рәисе Зухур Таһир, урынбасары, сәркатип Ибраһим Арифулла имзалаган. Язуда Рәфгать Азимовның Тампередагы сәүдәгәр Хөсәен Сөләйманның якын кардәше булганлыгы күрсәтелгән. Икенче язу беренчесеннән 10 көн соңрак Тампередан юлланган. Аны Тампере мәхәллә әгъзалары имзалаган. Берсе –алда әйтелгән Хөсәен Сөләйман, калганнары – Нәүмән Насыйбуллин (1890-1966), Гомәр Насыйбуллин (1895-1964), Гомәр Сали (1876-1951). Гаризага «Суожелускунтаин (Саклау органнарының) штабында, 17.10.1941 тарихында кабул ителгән», дип, мөһер сугылган. Анда

[2] Алар Түбән Новгород өлкәсе Сергач районы Суыксу авылыннан, әниләре бертуган була.

болай дип язылган: *«Якын туганыбыз, Рәфгать Азимов, яраланып, хәрби хастаханәдә яткан һәм Нарижярви тукталышы якынындагы әсирләр лагерена эләккән, дип хәбәр алдык. Ул, белгәнебезчә, мәҗбүри хәлдә калып, әле бара торган сугышта катнашкан. Ул гәрчә Русиядәге әлеге дәүләт системасын хуплаучылардан түгел. Әтисе торган җиренең мулласы булганга, ул да дини катлам кешесе. Рәфгать Азимовны әсирләр лагереннан азат итеп, аңа Тампере шәһәрендә торырга хокук бирүне ихтирам белән үтенәбез. Без, бу гаризаны имзалаган якын туганнары, аны канат астына алабыз һәм эш урыны белән тәэмин итәбез, дип сүз бирәбез. Тампере, 16 октябрь, 1941»*.

«21.10.1941 тарихында» Эчке гаскәр идарә штабы азат итү турындагы гаризаны кабул итми һәм бу мәгълүматны сәүдәгәр Н.Насыйбуллинга, Тамперега җиткерә. Ни өчен инкяр ителгәнлегенең сәбәбе күрсәтелми. Бу, мөгаен, Азимовның гаскәри әсир булуы белән аңлатыладыр. Ул Миккелидәге башка татар әсирләре кебек гадәти халыктан булмый.

Рәфгать Азимов 1941 елның 4 октябрендә Уттидагы хәрби хастаханәдән Наараярви лагерена күчерелә. Анда Хөсәен Сөләйман белән күрешү бәхетенә ирешә. Тампередагы кардәше янына, азатлыкка чыгарылмаса да, Совет иленең азчылык халык вәкиле булганына күрә, аңа ышаныч күрсәтелә. Хәтта Азимовка «Paraisten Kalkkivuori Osakeyhtiö» исемле фирма белән хезмәттәшлек итәргә дә рөхсәт бирелә. 1943-1944 елларда Азимов аның Лоуколампидагы фабрикасында механик булып эшли.

Соңрак, Азимов, үзе рөхсәт алып, бу лагерьдан Котка шәһәренә күчә һәм анда бер татар кызы белән никахлаша. Шуннан соң бу пар Раума шәһәре аркылы Швециягә киткән, аннан Америкага күченгән. Берничә елдан алар Финляндиягә кунак буларак кайталар. Хатыны Нәфисә ханым, иренең вафатыннан соң, Финляндиягә кире күченә, Котка шәһәрендә яшәп, 2006 елда вафат була.

Әхмәт Бигиев – татар әсирләре арасыннан иң дәрәҗәле тоткын. Аның әтисе – танылган галим, татар милләтчесе Муса Ярулла улы Биги (1875-1949).

Әхмәт Бигиев тә Совет гаскәрендә сугышкан һәм Ак атауның Кара елгасы буенда 1942 елның 15 июнендә әсирлеккә төшкән. Бигиевтән башта ук шпион дип шикләнгәннәр. Хәтта фин гаскәре кулына үз ихтыяры белән бирелгәнен белгерткән булса да, аннан шик-шөбһә китмәгән: берничә ай буе Миккелидә сорау алганнар. Соңрак Бигиевне офицерлар өчен билгеләнгән әсирләр лагерена күчерәләр. Үз кулы белән тутырылган документта ул Кызыл Армиянең 61 нче авиация бригадасындагы 30 яшьлек капитан яки мөхәндис майор буларак теркәлгән.

Әхмәт Бигиев тә Финляндия хөкүмәтенә азат итүне сорап гариза юллый. Үзенең башта патша, аннары большевиклар басып алган татар халкының бер кешесе булганын бәян кыла. Документтан күренгәнчә, Әхмәт Бигиев үзен мөселман халыкларының милли уянуына, үзаңнары куәтләнүгә багышлаган. Шул сәбәпле, 30 яшенә кадәр гомеренең алты елын зинданда үткәргән. Гаризада әтисе Муса Ярулла улының галим кеше, Фәннәр Академиясенең профессоры, исламчылык хәрәкәтенең иң танылган лидеры булуын белгерткән. Әтисе 1930 елда Совет иленнән Германиягә һиҗрәт кылырга мәҗбүр булган. Шул сәбәпле, Әхмәт Бигиев тә үзен Германиягә җибәрүләрен сораган. Соңыннан, әтисен эзләп табу өмете илә, 1943 елның 19 сентябрендә Ханко шәһәреннән көймә белән Германиягә китә. Шуннан соң Әхмәт Бигиев үз иленә кире әйләнеп кайтмый.

Ахыры бар ■

Данлыклы Чапаев дивизиясе сугышчылары. 1918 ел

ЗАМАН ГЕРОЙЛАРЫ

Хәнәфи Насыйров

(Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районы халкы – Гражданнар сугышында[1])

Гражданнар сугышының йөзьеллыгы якынлашып килә. Иске Кулаткы төбәген өйрәнүче белгеч буларак, әлеге сугышта катнашкан үз районым кешеләре турында да язасым, журнал укучыларына белгертәсем килә.

Хәзерге Иске Кулаткы җирләре 1918 елда Саратов губернасының Хвалын өязе Иске Атлаш, Шаһ, Урта Терешкә, Иске Лебежай, Яңа Зимничә, Дворян-Терешан волостьларына кергән. Бу волостьларда барлыгы 28 авыл булып, 55,8 мең кеше яшәгән, шуларның 97,6%ын татарлар тәшкил иткән. Болар барысы да заманында Темников, Сембер, Касыйм, Казан, Оренбург төбәкләреннән килгән «йомышлы кешеләр» булып, соңрак аларны дәүләт крестьяннары хисабына кертәләр[2].

Бөек Октябрь социалистик революциясе вакытында 28 авылда 72 мәчет эшләгән. Татар ир-атларында ватанпәрвәрлек хисе көчле булып, алар патша армиясендә тугры һәм намуслы хезмәт иткән. 1917 елның декабрендә

[1] Гомерен партиягә багышлаган ветеран укытучы, төбәкне өйрәнүче Хәнәфи Насыйровның бу мәкаләсе, күптән түгел генә язылса да, совет идеологиясе карашларыннан арынмаган иде. Шуңа күрә мәкаләне берникадәр үзгәртергә, аңа астөшермә рәвешендә өстәмәләр кертергә туры килде.
[2] Иске Кулаткы районы җирләренә халыкның кайдан күченүе турында авторның «Кулаткы морзалары» исемле мәкаләсеннән укып белергә мөмкин: «Безнең мирас». – 2016, май; http://beznenmiras.ru/kulatky-morzalary/

хәзерге Иске Кулаткы районының Яңа Кулаткы авылында, 1918 елның гыйнвар-февраль айларында башка авылларында Совет хакимияте тыныч, кан коюларсыз гына урнаша, крестьяннар яңа хакимиятне шатланып каршы ала һәм тулысынча большевеклар тарафына күчә.

Моңа Беренче Бөтендөнья сугышыннан туган җирләренә кайткан татар солдатларының алдынгы революцион карашлары һәм, шулай ук, Бакы, Саратов, Казан, Сызрань шәһәрләренә сезонлы эшкә, Донбасс шахталарына киткән ир-атларның коммунистик рух белән әйләнеп кайтуы зур этәргеч биргән. Хвалын өязеннән читкә китеп хезмәт куючылар гаять күп булган. Алар, авылга кайту белән, яңа үзгәрешләрне тиз тоеп алып, Совет хакимиятен урнаштыруда җирле түрәләргә ярдәм итәргә керешкән. Өяз хакимияте, волость башкарма комитеты 1918 елгы язгы чәчү вакытында крестьяннарга булышырга тырышкан, хәерчеләргә орлык, ат һәм башка кирәкяраклар биргән. Әмма тыныч тормыш озак бармый.

Мәгълүм ки, 1914-1918 еллардагы Беренче Бөтендөнья сугышы илнең икътисади тормышына зур зыян сала: завод-фабрикалар эшчәнлеге чимал, ягулык җитмәү сәбәпле туктап кала, икмәк, азык-төлеккә кытлык, авыл һәм калаларда яшәүче халык хәерчелек, ачлыкның чигенә килеп җитә. Икмәк алпавыт һәм бай крестьяннар кулында гына була. Илдә хәрби коммунизм сәясәте үткәрелә башлый: алдынгы эшче һәм кызылгвардиячеләрдән торган продотрядлар оеша. Аларның максаты – кулаклардан, бай игенчеләрдән икмәкне тартып алу.

Илдә сыйнфый көрәш кискенләшә, ачлык, төрле авырулар көчәя. Ил «кызыллар» һәм «аклар»га бүленә. Безнең төбәк ир-атлары Сембер, Саратов һәм Идел буеның башка губерналарындагы Гражданнар сугышында актив катнаша. 1918 елда Иске Кулаткыдан ерак түгел генә урнашкан Сызрань, Кузнецк шәһәрләре һәм башка авыллар ак чех-

Сәйфулла Ильяс улы Хуҗәхмәтов – шул заман геройларыннан берсе

лар тарафыннан камап алына. Фетнәне бастырыр өчен, Иске Кулаткы, Шаһ волостьларыннан кызылгвардиячеләр җибәрелә. Ак чехлар тар-мар ителә, бәрелешләр вакытында Иске Кулаткыдан 30 кеше һәлак була. Кулаткылылар Хвалын шәһәрендә патша армиясенең штабс-капитаны Попов җитәкләгән төркемне дә тар-мар итүдә катнаша. Биредә Иске Кулаткы, Урта Терешкә, Яңа Кулаткы авылларыннан элеккеге фронтовик егетләр актив сугыша.

Авыл халкы, җирле совет һәм ярлылар комитеты көче белән, фронтовикларның гаиләләренә һәм Кызыл Армиягә матди ярдәм күрсәтә. Гражданнар сугышы чорында Иске Кулаткы, Бахтеевка, Чуаш Кулаткысы, Яңа Зимничә авылларыннан Кызыл Армиягә 150 ат, йөзләгән кием-салым һәм аяк киеме озатыла. Туган якны өйрәнү музеенда Яңа Кулаткы, Иске Яндовка, Иске Кулаткы авыллары халкының фронтка 72 пар киез итек, 110 пар чабата, 17 тун, 112 пар йон оек җибәрүләре турында документ бар.

Гомумән алганда, Иске Кулаткы районы авылларыннан 3600 кеше Гражданнар сугышында кан коя. Алар

данлыклы Чапаев дивизиясендә, татар һәм интернациональ полкларында, бригадаларда көрәшә, бер меңгә якыны һәлак була, күбесе туган төбәгенә яралып, зәгыйфьләнеп кайта. Кызылармиячеләрдән Исхак Богданов, Галиҗан Монасыйпов, Исмәгыйль Гафуров, Андрей Хуҗәхмәтов, взвод командирларыннан Сабир Рафиков, Шиһап Хәбибуллин, Нурали Сабитов, Каюм Шабакаев, Исмәгыйль Шабакаев, Габдрахман Якупов кебекләр, зур батырлык һәм каһарманлык күрсәткәннәре өчен, орден-медальләр, исемле кораллар белән бүләкләнә.

Сәйфулла Ильяс улы Хуҗәхмәтов – шул заманның геройларыннан берсе. Ул 1875 елда Яңа Зимничә авылындагы ярлы крестьян гаиләсендә туган. Унбер яшьлек малай, ачлык һәм хәерчелектән качып, Идел буена кәсеп эзләп чыгып китә. Әстерхан шәһәрендәге бер пристаньда үзенә эш таба: пароходлардан байларның һәм сәүдәгәрләрнең йөген ташый. 15 яшеннән Хәзәр диңгезе утрауларының берсендә урнашкан балыкчылык хуҗалыгында кара эшче булып хезмәт итә. Патша армиясендә Кавказ ягында хезмәттә була. 1901 елда Бакы нефть промыселенә урнаша. 1904 елда большевиклар сафына баса. Бакы шәһәрендә патша хакимиятенә каршы яшерен эшләрдә, 1905 елда Бакы шәһәрендә булган кораллы восстаниедә катнаша.

Патша хакимиятенең эзәрлекләвеннән качып, С.Хуҗәхмәтов Красноводск (хәзерге Төрекмәнбашы), Кызыл Арват (хәзерге Сердар) шәһәрләренә китә, анда да ул большевиклар белән мөнәсәбәтне өзми, Урта Азиядә прокламацияләр тарату белән шөгыльләнә. 1906 елда Әндиҗан станциясендәге яшерен оешма әгъзалары белән таныша, тимер юл транспортында большевистик әдәбиятны тарату белән актив шөгыльләнә. 1907 елда С.Хуҗәхмәтов, Әндиҗан шәһәренә күченеп, «Беш-Бош» заводына эшкә урнаша, яңадан революцион эшчәнлеген башлап җибәрә. 1917 елның 4 июлендә ул заводта көчле забастовка оештыра.

Июль вакыйгалары Совет хакимиятенең Әндиҗан шәһәрен яулап ала башлау датасы булып тора. Декабрь аенда шәһәр тулысынча большевиклар кулына күчә.

«Беш-Бош» заводында коммунистлар партиясе җитәкчелегендә эшчеләр тарафыннан оешкан Кызыл гвардия отряды Сәйфулла Хуҗәхмәтов командалыгында Фирганә үзәнлегендә революциянең җиңеп чыгуына, кыргыз илендәге Ош, Җәлал-Абад һәм башка шәһәрләрдә басмачыларның[3] советларга каршы көрәшен бастыруда зур көч куя. Үзбәкстанның Бекабад, Тишек-Таш, Хаккул-Абад шәһәрләре һәм башка җирләрдә басмачыларның хәрәкәтен туктата. Коканд Советына иң авыр вакытларда ярдәмгә килгән Сәйфулла Хуҗәхмәтов командасы, башка хәрби берләшмәләр белән бергә хәрәкәт итеп, Ташкент шәһәрендә басмачыларның «Төркестан мөхтәрияте»н (яки «Коканд автономиясе»н) төбе-тамыры белән юк итүдә катнаша, Совет хакимиятенең тулысы белән җиңүенә ирешә[4].

1919 елның сентябрендә Әндиҗан шәһәре генерал Монастровның 20 меңлек армиясе һәм басмачылар белән камап алына. 23 көн дәвамында барган сугышларда Сәйфулла Хуҗәхмәтов

[3] Басмачылар хәрәкәте хәзерге тарих фәнендә Урта Азиядәге төрки халыкларның Россия колониясенә каршы милли-азатлык хәрәкәте буларак бәяләнә.

[4] «Төркестан мөхтәрияте» (яки «Коканд автономиясе») – төрки-мөселман халыкларының хәзерге Үзбәкстан, Казакъстан, Кыргызстан җирләрендә 1917 елның 27 ноябреннән – 1918 елның 22 февраленә кадәр оешкан дәүләти берләшмәсе. Шунысын искәртик, әлеге бәйсез дәүләтнең Вакытлы хакимияте составында, казакълар һәм үзбәкләр белән бергә, татар егетләре – рәиснең урынбасары Ислам Шаһиәхмәтов, Хәрби шура рәисе Мәһди Чанышевлар да була. Басмачыларга һәм әлеге милли җөмһүриятькә каршы көрәшкә совет хакимияте җирле халыкның телен, гореф-гадәтләрен яхшы белгән Идел буе татарларын күпләп махсус озата.

җитәкчелегендәге отряд, иң авыр һәм җаваплы бәрелешләрдә катнашып, каршы якка зур зыян китерә.

Шул ук елда Әндиҗан шәһәренә Төркестан фронты командующие Михаил Фрунзе килгәннән соң, аның җитәклегендәге Хуҗәхмәтов отряды, Кызыл Армия гаскәре белән, корбашы (ягъни кырык башы) Ахунҗанның гаскәрен туздыра, шулай ук баш командирның фәрманына буйсынып, Фирганә фронтында да басмачылык хәрәкәтен бастырырга керешә.

С.Хуҗәхмәтов җитәкчелегендә басмачыларга каршы көрәш вакытында җирле халыклардан торган аерым отрядлар да оеша. Әндиҗанда эшче, кызылгвардиячеләр һәм партия дружинасы әгъзалары әзерләнә. Большевиклар партиясенең карары нигезендә, С.Хуҗәхмәтов гадәттән тыш хәлләр отрядының партия дружинасы командиры итеп тәгаенләнә.

1922 елның февралендәге 253 нче аттестациядә С.И.Хуҗәтмәтов турында болай языла: *«Коканд продбатальонының 2 нче Әндиҗан ротасы командиры иптәш Хуҗәхмәтов, батальонда булган вакытта законга каршы бернинди хилаф гамәл кылмады, хәрби хакимият тарафыннан бирелгән барлык фәрман һәм күрсәтмәләрне карусыз үтәде. Өязләрдәге эш вакытында продармиячеләр белән җитәкчелек итә алды. Алар, сугышчан яктан начар әзерлекле булсалар да, һәрвакыт алгы сафта көрәштеләр. Фирганәдә басмачылык көчле булуга карамастан, продбатальонда үлүчеләр һәм яраланучылар саны башка отрядлар белән чагыштырганда азрак иде. Басмачылар белән көрәш туктатылганнан соң, иптәш Хуҗәхмәтов Үзбәкстанда Совет хакимиятен ныгыту юнәлешендә төрле вазифаларда эшләвен дәвам итте»*.

1929 елда Сәйфулла Хуҗәхмәтов, Үзбәкстанның Нәмәнган өлкәсендә барлыкка килгән басмачыларга каршы көрәшер өчен, партия тарафыннан яңадан мобилизацияләнә һәм, отряд командиры буларак, сугышка җибәрелә. Хәрби бурычны уңышлы үтәп, Нәмәнган өлкәсендә басмачыларны төбе-тамыры белән кырып аткач, ул Әндиҗанга әйләнеп кайта һәм көчле авыру нәтиҗәсендә аяктан егыла.

Үзбәкстан Совет хакимияте үзенә тугры һәм намуслы хезмәт иткән татар егетен онытмый. Шул чордагы документларга күз салсак, 1935 елда Октябрьнең 18 еллыгы уңаеннан, аңа Мактау грамотасы, бер мең сум акча бирелә. 1936 елда көрәшче «Кызыл Байрак» ордены белән бүләкләнә. 1918-1922 елларда басмачыларга каршы көрәшен, 1905 елда Бакы шәһәрендә яшерен рәвештә большевиклар белән хезмәттәшлек итүен истә тотып, 1939 елда Әндиҗан шәһәр советы аңа 500 сум күләмендә пенсия билгели. Шул ук елда Хуҗәхмәтовның сәламәтлеге тагын да начарлана. Моны истә тотып, Үзбәкстан ССР ҮБК рәисе Юлдаш Ахунбабаев республиканың халык сәламәтлеге комиссарына көрәшчене дәвалауны үз контролендә тотарга куша. 1939 елның 3 нче июнендә Әндиҗан шәһәренең сәламәтлек саклау бүлегенә телеграмма килеп төшә. Анда: *«Персональ пенсионер, элекке командир Хуҗәхмәтовның сәламәтлеген тикшерегез, дәвалау чараларын күрегез, нәтиҗәне Наркомздравка – Абдуллаевка хәбәр итегез»*, – дип язылган була.

Сәйфулла Хуҗәхмәтов 1940 елның 27 нче февралендә, озак авырудан соң, бакый дөньяга күчә, шәһәрнең Пушкин исемендәге үзәк паркында, туганнар каберлегенә җирләнә.

***

Дөрес, хәзерге вакытта Гражданнар сугыш геройларына – ярлы, хәерче, батрак һәм эшче арасыннан үсеп чыккан каһарманнарга, революционерларга карата мөнәсәбәт төрле, күбесенчә тискәре һәм алар әкеренләп тарих хәтереннән җуела бара. Әмма бу шәхесләр без яшәгән илнең – Советлар Союзының геройлары булды, меңләгән совет укучысы алар үрнәгендә һәм рухында тәрбияләнеп, бүген дә илебезгә намуслы хезмәт итә. ■

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

СӘМӘРКАНТ

1908 елның февраль башында Бохарадан киттем. Кәрминә-Кәтәкурган юлы белән Сәмәркантка килдем.

Урта Азиянең үзәге һәм, халкының үз сүзләре белән әйтсәк, җир өстенең каймагы булган бу борынгы мөбарәк шәһәр кайчандыр Азия каһарманнарының пайтәхете – баш каласы булган, бүген исә аның турында борынгы Ислам әсәрләренең хәрабәсе, дип әйтергә мөмкин. Сәмәркантта яшәүче халык саны 70000 тирәсе дип санала. Бөтенесе дә үзбәк. Бу төбәк кайчандыр Бохара ханнарының җәй үткәрү урыны, ә берара бөтен Иран халкы өчен күчеп утыру җире булган, шул сәбәпле бөтен Сәмәркант халкы фарсыча да, төркичә дә белә. Хәтта укый-яза белми торган гади халык та ике телдә дә сөйләшә ала, чөнки Сәмәркант халкы иранлылар белән үзбәкләрнең катнашмасыннан гыйбарәт.

Сәмәркант бервакытлар гыйлем иле булган, зур дарелфөнүн-университетлар, зур расадханә-обсерваторияләр бу шәһәргә нур чәчеп, дәрәҗә биреп торган. Ул сокландыргыч төзеклекнең калдыклары – Дилләкяр һәм Ширдар мәдрәсәләре, Хаҗи әш-Шәйх Гобәйдулла әл-Ахрарның кабере бүген безгә шуны дәлилли: Сәмәркант чынлап та кайчандыр гыйлем чәчәк аткан төбәк булган. Инде җимерелеп барган ул биек мәдрәсәләрнең, зур мәчетләрнең эчләре һәм тышлары нәфис мозаика сәнгате белән бизәлгән, күренешләре әле дә гаҗәпкә калдырырлык дәрәҗәдә матур. Дилләкяр мәдрәсәсе янында искиткеч зур һәм биек ике манара бар: әгәр бүген мондый манара төзергә уйласалар, бу эш бик зур фидакарьлек таләп итәр иде. Ләкин шул ук вакытта, фән һәм архитектура ягыннан шаккатырырлык ул сәнгать әсәрләрен, ул гүзәллекне бүгенге көндә барлыкка китереп булыр кебек күренми.

Бик кызганыч ки, шушы XX гасыр мәдәнияты аркасында бу борынгы әсәрләрнең үрнәкләре инде ахыргача җимерелә бара һәм әледән-әле сәяхәткә килүче европалылар тарафыннан ул сәнгать шаһәсәре ташлар берәм-берәм чит илләргә алып кителә. Тагын шунысы гаҗәпкә калдыра: боларны вәхши мөселманнар барлыкка китергән, ә менә мәдәни аврупалылар җимергәннәр һәм җимерәләр. Бүгенге көнгә кадәр, боларны – борынгы сәнгать әсәрләре буларак – саклап калу өчен бераз гына да кайгыртучанлык күрсәтелмәгән һәм әле дә күрсәтелми. Бигрәк тә, кан коючы, мәдәният дошманы һәм тагын әллә ниләр дип ярлыклар тагылган Тимерланның (Аксак Тимернең) төрбәсен һәм китапханәсен күрсәгез, канлы яшь кояр идегез.

Тимерлан (рәхиме Аллаһ) төрбәсе турында мәшһүр рус әдибе Чукмалдин[1] болай ди: *«Тимерланның төрбәсендәге архитектура технологиясе бүгенге көндәге фәнни үлчәмнәрдән күпкә өстенрәк. Чарасызлык шунда ки, боларның һич бере дикъкать һәм гаделлек белән карап тикшерелми, мәрхүмнең яманлыклары гына искә алына»*.

Сәмәркант мөселманнары арасында бу нәфис сәнгатькә хезмәт итүчеләр әле

Дәвамы. Башы журналның 1 нче, 2 нче (2017) саннарында.

Текстта авторның тел-стиль үзенчәлекләре тулысы белән саклана.

[1] Николай Мартемьянович Чукмалдин (1836-1901) Төмәннең Кулаково авылында руслашкан татар гаиләсендә туган. Танылган сәүдәгәр, меценат, җәмәгать эшлеклесе, язучы. (тәрҗ. иск.)

Сәмәрканд. Җәмигъ мәчете «Биби ханым»

Сәмәрканд. «Биби ханым» мәчете ишегалдындагы Корьән аскуймасы

һаман да очрый. Руслар күрсәткән золым һәм гаделсезлекләргә дә карамыйча, Әминҗан исемле бер олы зат, мозаика ысулы белән яңа, әмма бераз кечерәк, 20 бүлмәдән гыйбарәт бер мәдрәсә төзеткән. Бинаның эчке эшләрен тәмамларга торалар. Тышкы яктан күренеше бик ямьле, бик нәфис. Мәдрәсәне салдыручы Әминҗан үзе дә, улы да эшчеләр арасында иде. Әминҗан әфәнде ябык кына гәүдәле, аксак ир заты, бай түгел, ләкин бик игелекле кеше. Ата-бабадан мирас булып калган әлеге сәнгать төренең бер үрнәген үз исемен мәңгеләштерәчәк ядкяр итеп калдырыр өчен зур тырышлык куя.

Сәмәркантта исемнәре мактау такталарына алтын белән язылырга лаеклы бөек һәм изге затлар бүген дә бар, тиранлык яшене сукмасын өчен исемнәрен атамыйм, әмма Ислам тарихы, әлбәттә, бу кешеләрнең исемнәрен саклаячак һәм яшәтәчәк. Сәмәркантта бүгенге көндә изге затлар тарафыннан ачылган башлангыч һәм рүшдия (урта) мәктәпләре бар, болар бөтен Төркистан өчен үрнәк булып торалар. Мәктәпләрнең оештыручысы Габделкадыйр әфәндене һәм аның химаячесе мөфти Мәхмүд Хуҗа җәнапларын үзбәк халкының каһарманнары дип атау дөрес булыр.

Сәмәркантта төрле төрбәләр, зиратлар һәммәсе борынгы Ислам әсәрләре һәм архитектура үрнәкләре булып торалар. Шул дәрәҗәдә ки, гасырыбызның архитекторларын, төзүчеләрен таңга калдырырлык. Бүгенге көндә Петербургта салына башлаган мәчет тә төзелеш планы буенча бу үрнәкләргә якын бу-

Безнең мирас №4 апрель 2017

лачак. Инженерлар арасында ярышма һәм иң яхшы план өчен 10000 сум акча биреләчәге игълан ителгәннән соң, сынаучы вәкаләтле төркем, авруропалы архитектор һәм инженерлар хәзерләгән планнар арасыннан Сәмәркант архитектура ысулы белән әзерләнгән бер планны сайлап алган һәм кабул иткән.

Петербург мәчете Сәмәркандтагы Тимерлан төрбәсенә охшатып салыначак, бары тик бер аермасы бар: төрбә бер генә манаралы була, ә Петербург мәчете, мәчет булганга күрә, ике манаралы булачак. Төрбәнең эче һәм тышы, гадәттә, мозаика ысулы белән бизәлә, Петербург мәчетенең исә тышы акшар белән агартылачак, эче буяу белән буялачак. Бина әлегә төзелеп бетмәгән.

Хәзерге вакытта Сәмәркантта шул борынгы биналардан башка күзгә ташланырлык башка берни дә юк. Борынгыдан калган никадәр тарихи әсәр булган булса, руслар басып алганнан соң алар барысы да Петербургка алып кителгән. Бүген Петербург императорлык китапханәсендә сакланган борынгы ислам әсәрләре, китаплары һәм алдынгылыкның күрсәткече булган нәфис әсәрләрнең һәммәсе бирегә Ислам өлкәләреннән китерелгән. Шул исәптән, Петербург китапханәсендәге Хәзрәт-е Госманныкы дип фараз кылынган Мусхаф-ы Госмани (Хәзрәт-е Госманның Коръән-е Кәриме) дә Сәмәрканттан китерелгән. Бу Мусхафтан башка да Петербург китапханәсендә никадәр нәфис китап булса, һәммәсе дә Сәмәркант малы.

МУСХАФ-Ы ГОСМАНИ

Бүген Петербургта императорлык китапханәсендә бик борынгы Мусхаф (Коръән) саклана. Аны күрергә дип чит илләрдән бик күп кеше килә. Мусхаф-ы шәриф, Хәзрәт-е Госманныкы булганга, мәшһүрлек казанган.

Бу Мусхаф-ы шәриф, руслар басып алганга кадәр, Сәмәркантта Хаҗи



٢٦ عالم اسلام

روسيه‌ده ـ اوفا ، قزان ، نيژنی وسائرولايتلرك كافه‌سنده ـ تاتارلر عصرلرجه روسلر ايله مختلط . اكثر ولايتلرده روسلرده چوق اولمغله برابر ، روسلشمق شويله دورسون ، كيتدكجه تاتارلرك مليت وتعصبی قابارمش وقابارمقده‌در . حتی بر آرالق روسلر تاتار كلمه‌سنی غايت چركين تعبيرلر ايله حقارت معناسنده استعمال ايتمشلر . بر آرالق تاتار جهلاسی بيننده تاتار كلمه‌سنی مجوسی معناسنده استعمال ايتديرمشلر . حتی بيچاره تاتارلر بو التباسی دفع ايچون مجوسيلك خاطره گلمك ايچون ، تاتار ديناله‌جك يرده مسلمان ديرلرمش ، الی يومنا هذا تاتارلر ، تاتار لسانی ديه‌جكلری يرده ، مسلمان ديلی ديرلر . مع مافيه روسلشمق (آسيميلاسيون) اثری بو كونه قدر يوقدر ديه بيلورز . شو حالده تركستانده دخی اسيميلاسيون اولمق احتمالی بعيددر . زيرا خرستيانلق اسيميلاسيونه مانعدر . بونی تاريخه واقف اولانلر انكار ايده‌مزلر . روسيه‌ده دكل تاتارلر وبخاريلر ، حتی روسلر ايله جنسلری بر ، دينلری بر ، لسانلری بر ، نسل ونسبلری بر اولان مالا روس ، بيلا روس ، ايستلر بيله روسلاشمامشلر وروسلاشميه‌جقدرلر . عربستانده يهوديلرك ، سوريه‌ده درزيلر واسرائيليلرك ، مصرده قبطيلرك ، آفريقاده حبش وبربريلرك عربلشمه‌سينه ديانت اسلاميه بيوك خدمت ايتمشدر . اوقدركه بونلر كندی لسانلرينی اونوتدقلری كبی قوميتلرينی دخی اونوتمشلردر . بوكون اكثری عربلق دعواسنده بولنورلر . ايشته ظلم واستيلا فكرينه مستند اولميان عادلانه معامله‌لر بويله كوزل نتيجه‌لر ويرر .

يدی صو ولايتی

يدی صو ولايتی اكثر اهاليسی كوچبه قازاقدر . جزئی بر مقدارده قيرغيزدر . ديكرلرينه‌ده « صارت » يعنی شهر خلقی تعبير اولنور . بخاری وتركستانليلر ، بر قسمی ده روسيه‌دن كلمش ، نوغای تعبير اولنور تاتارلردر .

اسكی‌دن اورالرده روسلردن كيمسه بولنمزمش ، اوكنيش مملكتك بر طرفنه قيشلاو (قيشلق) ديكر طرفنه‌ده يازلاو (يازلق) تعبير اولنور ، هر كس كندی بيلديكی كبی كوچر قونارمش . قازاق ، قيرغيز بونلرك بوتون معيشتلری حيوانات بسلمه‌مكدر . اك فقير بر آدمده لااقل اون بش ، يكرمی آت ، قصراق ، قرق ، اللی قيون بولنورمش . اغنياده ايسه بيك ، ايكی بيك ، حتی بش بيكه قدر (يلقی) قصراق بولنديغی كبی اون بيك ، يكرمی بيك قدرده قيون بولنورمش ، ايكی ، اوچ يوز قصراغی اولانلرده بر درجه وقت وحالی كوزل ديرلرمش .

«Ислам дөньясы» китабының бер бите

Гобәйдулла әл-Ахрар мәчетендә сакланган. Анда бу Коръән-е Кәримне куяр өчен мәрмәрдән ясалган рахлә (аслык) әле дә булса урынында тора. Тик Коръән үзе генә юк, Петербургта. Руслар Сәмәркантны басып алганда, 1869 елның 24 сентябрендә, атаклы генерал Кауфман тарафыннан ул Петербург китапханәсенә җибәрелә. Генерал-майор Абрамов бу Мусхаф-ы шәрифне, Ахрар мәчете голәмәсе Габделҗәлил һәм Мулла Могыйнь исемле ике кешенең фәтвасы белән һәм 100 сум бүләккә каршы бүләк рәвешендә алып, Кауфман җәнапларына тәкъдим итә. Шул ук мөфти Мулла Могыйнь белән Мулла Гбделҗәлил әйткәнчә, Мусхаф-ы шәриф Сәмәркантка Истанбулдан Хаҗи Ахрарның тырышлыгы белән, моннан 400 еллап элек китертелгән булган. Мусхафның өстендә әлегә кадәр Хәзрәт-е Госманның (рәхиме Аллаһ) кан эзе сакланган. Риваятькә күрә, бу Мусхаф хәзрәт-е Госманның шаһадәте (дин өчен сугышта шәһит киткән) вакытында укыган Коръән-е Кәриме икән, үтерелгәндә каны китап өстенә тамган. Шул кан эзе бүгенге көнгә кадәр сакланган, дип санала.

Сәмәрканд кызлары. 1900 ел

Рус язучысы мәшһүр Шебунин бу Мусхаф турында махсус хезмәт язган, аңа «Куфический Коран» дигән исем биргән[2]. Әлеге хезмәтендә Шебунин бу Мусхафның ул кадәр үк борынгы булу ихтималын кире кага.

Моннан тыш, мәгълүм булганча, Хәзрәт-е Госман (рәхиме Аллаһ) мөселманнарның анасы Хәзрәт-е Хафсаның кулындагы Мусхаф-ы шәрифтән күчермә ясарга әмер иткәндә: «Кәгазьнең киңлеге ике кул яссуы кадәр булсын!» – дигән. Петербургтагы Мусхаф-ы шәрифнең кәгазе исә 4 кул яссуы кадәр булыр. Чынлап та өстендә кан эзе кебек бер эз бар, ләкин кан булу ихтималы катгый түгел. Кыскасы, «бу Коръән, Мусхаф-ы Госмани, ягъни Хәзрәт-е Госманныкы түгел», дисәк, дөреслеккә якынрак килгән булырбыз.

Бу Коръән бүгенге көнгә кадәр императорлык китапханәсендә саклана, кайбер битләре юк[3]. Бервакыт Сибряков (Сибиряков?)[4] исемле бер кеше бу Коръәнне ташбасма ысулы белән 200 нөсхә итеп бастырды, бер нөсхәсенең бәясе сатуда 200 сумга кадәр җиткән иде.

ФИРГАНӘ ӨЛКӘСЕ

Мин Сәмәрканттан Фирганә өлкәсенә таба юл тоттым: Хокант, Наманган, Маргилан, Әндиҗаннарны үттем.

[2] Гарәп белгече А.Ф.Шебунин (1867-1937) һәм аның Мусхаф-ы Госмани турындагы мәкаләсе турында сүз бара. Шебунин А.Куфический Коран. – СПб. Публичной библиотеки. — Записки Восточного отделения имп. Русского археолог. общества. Вып. 1-4. СПб., 1892, т.VI, с.76-77. (Тәрҗ. иск.)

[3] Революциядән соң, РСФСР Халык комиссарлары советы карары белән, Коръән башта Петроград Мөселман съездына, 1918 елның башында Бөтенроссия мөселманнар советына тапшырыла һәм Уфага китерелә. 1923 елда, Төркестан голәмәләренең соравы буенча, Ташкентка китереп тапшырыла. Аннан Коръәнне Сәмәркантка китереп Хаҗи Ахрар мәчетенә куялар. 1941 елдан соң аның саклану урыны Ташкенттагы Үзбәкстан халыклары тарихы музее була. 1989 елда музейдан алынып мөселманнарга, 1990 елның башында Үзбәкстан мөселманнары идарәсенә тапшырыла. Бүгенге көндә ул Идарәнең Барак-Хан мәдрәсәсендә урнашкан китапханәсендә саклана. 1997 елда Коръән-е Госмани ЮНЕСКО тарафыннан «Дөнья хәтере» реестрына кертелде. (Тәрҗ. иск.)

[4] Белгечләр тарафыннан язылган хезмәтләрдә бары тик Писарев дигән кеше тарафыннан чыгарылган 1905 елгы факсимиль басма турында гына мәгълүмат бар. Ул 50 нөсхә басылган булса да, 25е генә сатуга чыккан, 500 сумнан сатылган. (Тәрҗ. иск.)

Боларның һәммәсе, алдарак та әйтеп үткәнемчә, ике шәһәр яки мәхәлләдән гыйбарәт: рус һәм мөселман мәхәлләләре. Хокантта яшәүче халык саны 95000. Боларның бары тик 3000е генә рус, шулай булуга да карамастан, рус мәхәлләсе бик төзек, тәртипле, ә мөселман мәхәлләсе исә үтеп чыгарлык түгел. Бөтен Төркистанда Хокант гыйлем ягыннан икенче урында тора. Беренче – Бохара, икенче – Хокант. Биредә ханнар заманыннан калган бик зур мәдрәсәләр бар. Болардан тыш, нәфис Ислам сәнгате үрнәге булып торган «Ходайяр хан сарае» дип йөртелә торган бик биек сарай бар. Бүгенге көндә ул гаскәр кышлагы – казармасы итеп кулланыла. Бу сарай моннан 35 ел элек бер Ислам падишаһының солтанат сарае булган, ләкин бүген рус гаскәре казармасына әйләнгән.

Моннан 40-50 ел элек хөрмәтләп, олылап, кадерләп карап тотылган, эчен һәм тышын аятьләр бизәгән бу Ислам сарае, бүген бөтен хәл-торышы белән: «Кимлеккә, хурлыкка калдым, гөнаһ һәм түбәнлек җире булдым. Моннан 40 еллап элек минем эчемдә зикер әйтелә, тәсбих тартыла һәм Коръән укыла иде, бүген исә төрле-төрле ямьсезлекләр эшләнә, начар сүзләр сөйләнә. Сүгенүче, ата-анага карата көфер сүзләр әйтүче сәрхүшләргә, әдәпсезләргә яшәү урыны булдым...» – дип, ачыргаланып кычкыра кебек.

Бу хурлыклар Хокант халкының күз алдында эшләнә. Моны күреп торган халык бүген канлы яшь түксә дә аз булыр иде. Ләкин адәм баласы әсирлеккә тиз ияләнә икән шул.

Хокантта гыйлем иясе һәм фазыйләтле кешеләр юк түгел, бар. Шагыйрьләр бар. Фәкать милләтпәрвәрлек юк, гайрәт юк, затлылык юк, милли холык, миллият юк. Менә шуңа күрә мөселман падишһының сарае рус гаскәренә кышлак булган да инде.

Маргилан, Нәмәнган, Ош, Чош һәм башка бөтен Фирганә шәһәрләренең халкы – үзбәк. Гаҗәеп саф һәм сәләтле

Фирганә. Борынгы зиратка керү капкасы

милләт булса да, җаһиллеге сәбәпле, әсирлеккә хөкем ителгән.

Мин Фирганәдән кабат Сырдарья өлкәсенә, Ташкентка кайттым. Биредә бер 15 көн калганнан соң, Чимкент, Әүлия Ата, Пәшпак, Тукмак юлыннан, кайда атка, кайда ишәккә утырып, мең километр ара үтеп, Җидесу өлкәсенә, Алм-Ата шәһәренә килеп җиттем. Төп ватаным булган Тара шәһәреннән алып бирегә кадәр үткән юлым 5900 километрга якын булган. Моның 1300 километры гына ат, йә ишәк белән, калганы гел тимер юл буйлап үтелгән. Бу җирләрдә яшәүче халыкның зур күпчелеге – мөселман. Аеруча, «Сырдарья, Фирганә, Сәмәркант өлкәләрендә яшәүче халык бөтенләе белән мөселман», дисәк тә, дөрес булыр. Тик соңгы елларда гына бу җирләргә русларны китереп урнаштыра башлаганнар. Төркистанга Русиянең эчке районнарыннан күчеп килүчеләрнең саны аеруча күп.

Русиянең гомер-гомергә тоткан юлы шул: бер өлкәне үзенеке итәм, дисә, бар нәрсәдән дә элек, ул җирләрне үз кавеме белән ассимиляцияләргә тырыша.

Шулай итеп, русларны Төркистан

Фирганә базары

Җидесу өлкәләренә урнаштыру өчен, хөкүмәт миллионнар туздыра. Фәкать ассимиляция тормышка ашачакмы, юкмы – анысы авыр мәсьәлә. Русиянең эчке районнарында, Уфа, Казан, Нижний [Новгород] һәм башка өлкәләрнең барысында да татарлар гасырлар буе руслар белән янәшә, катнашып яшиләр. Бу өлкәләрдә, русларның саны күп булуга да карамастан, руслашу турында сүз булуы да мөмкин түгел, тора-бара, киресенчә, татарларның миллият хисе һәм милләткә бирелгәнлеге көчәя башлый һәм хәзерге вакытта да арта гына бара. Бервакыт руслар «татар» исемен ямьсез гыйбарәләр белән сүгү, хурлау сүзе итеп куллана һәм татар җаһилләре арасында «мәҗүси» мәгънәсендә кулландыра башлаганнар. Бичара татарлар, бу буталчыклыктан котылыр өчен һәм мәҗүсилекне хәтерләтеп тормасын, дип, «татар» урынына «мөселман» дия башлаганнар. Әле бүгенге көндә дә «татар теле», диясе урында, «мөселман теле», диләр. Шул ук вакытта, «ассимиляция бүгенге көнгә кадәр тормышка ашмады», дияргә мөмкин. Шулай булгач, Төркистанда да ассимиляциянең тормышка ашу ихтималы якында йөри, дип әйтергә урын юк, чөнки ассимиляциягә христианлык киртә булып тора. Моны тарихны яхшы белүче берәү дә инкарь итә алмас. Русиядә, татарлар яки Бохара халкы түгел, руслар белән үзләре, диннәре, телләре, тамырлары бер булган малорус, белорус, истләр[6] дә хәтта руслашмаганнар һәм руслашмаячаклар. Ә менә Гарәбстанда яһүдиләрнең, Сириядә дүрзиләрнең һәм чыгышлары белән Израильдән булган халыкның, Мысырда кыбтиләрнең, Африкада хабәш һәм бәрбәриләрнең гарәпләшүенә ислам дине зур өлеш керткән. Шул кадәр ки, болар үз телләрен онытып кына калмаганнар, миллиятләрен дә онытканнар. Бүген аларның күпчелеге үзләренең гарәп булулары фикерендә нык торалар. Менә шулай: золым-явызлык һәм басып алу фикеренә таянмаган гадел мөгамәләләр шундый уңай нәтиҗәләр бирә.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе.* ■

[6] Текстта бу кавемнең исеме истләр рәвешендә язылган. Г.Ибраһимов биредә, чынбарлыкта угро-фин халкы булган иштәк яки остякларны күз алдында тоткан булуы мөмкин. (тәрҗ. иск.)

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК
(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

ИЛБИКНЕҢ ҖАВАБЫ

Җавап бирде илбик: — И, егет кеше,
Үтәлер хаҗәтең — теләгең тошы.

Сиңа Тәңре бүләк иткән юньлелек,
Исемеңә тәңгәл[1] кылыгың, телең.

Булмас синдә һич тә ярамас юрык,
Ана сөте белән кергән саф холык.

Синең хакта әләк сөйләүче куштан
Сиңа дошман булса, миңа да дошман.

Мин тыңлыйммы инде аларның сүзен?
Кирәк күбен, кирәк кыска һәм әзен.

Ничек атар идек илнең башчысын,
Аермаса кемнең начар-яхшысын.

Халыкка хөкемче илбиккә ни сан,
Турыны кәкредән аермас булса?

Ничек ашар ашын көнне төн дисә —
Сыналган кулдашын хаин дип әйтсә?

Нәрсәгә ирешер түрә — канунчы,
Аермаса сүзнең ялганын-чынын?

Ходайдан миңа бер бүләк син бүген:
Ниһаять, чишелде ничәмә төен.

Лаеклы үтәдең үз хезмәтеңне,
Тулаем акладың тоз-икмәгеңне.

Кайтарырга кирәк сиңа әҗерне,
Җитеш-киң яшәргә инде әзер бул.

Ишет, изге кеше әнә ни дигән
(Аның тугры даны илгә җәелгән):

Синең хакта әләк сөйләүче куштан
Сиңа дошман булса, миңа да дошман.

---

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынннан басылып килә.

[1] Бу аңлашу-сөйләшүләр, күрәсең, шуннан килеп чыккан: Үгделмеш өстеннән кемдер илбиккә әләкләгән, илбик ышана төшкән, Үгделмешкә кырын караган, шуннан инде Үгделмеш тә үпкәләп, кардәше Уйгырмыш янына тауларга качмакчы булган.

«Кешеләрдән иң-иң изге шул була,
Кем кешегә һәрчак игелек кыла.

Үзара игелек кылган өчен дә
Кеше дигән исем калган кешегә».

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ СҮЗЕ

Җавап бирде, әйтте Үгделмеш: — Илбик,
Ләззәтләнсен, илгә ашатсын җилек[2].

Илаһ бирде ике дөнья нигъмәтен,
Теләгәне килсен, киңчә үтәлсен.

Уңайга әйләнсен сина киң фәләк
Һәм үтәлә торсын синең һәр теләк.

И, күңле киң, бөтен, кылыгы алчак,
Котлы булсын көнең, исән бул һәрчак!

Синнән миңа тиде һәртөрле хөрмәт:
Җиемлек-киемлек, дәрәҗә, мөлкәт.

Менә, хезмәтеңә баглыйм билемне,
Ходай тәүфыйк бирсен, и, киң белемле!

Һәм әйтте Үгделмеш: — И, илбик, котлы
Ходай үзе бирә изге холыкны.

Теләсәң изге ат, Алла бирер кот,
Бәхетле хәлеңдә күңлең изге тот.

Һәрвакыт бай булыйм, дисәң, билгеле,
Булсын дүрт шәй һәм син алырсың өлеш.

Бере — телең дөрес, сүзең рас булсын,
Икенче – илгә тәртип хас булсын.

Өченче — киң куллы, юмарт булалсаң —
Илдә икътисадны җайга куялсаң.

Дүртенчесе — батыр алпарлык кирәк,
Дошман муенын бөгеп кайтырлык гайрәт.

Бу дүрт шартның әгәр берсе генә дә
Булмаса, илеңә төшә күләгә.

**Халыкка хөкемче илбиккә ни сан,
Турыны кәкредән аермас булса?**

Шулар ич билекнең[3] тамыр нигезе
Һәм шулар бийлекнең[4] төп юлы — эзе.

Яхшы юл-юрыкны бозмый боралсаң,
Элекке бийләрдән үрнәк алалсаң.

Каю бий бу юлдан китсә борылып,
Төзәлмәслек булып эше бозылыр.

Кадерлә өч төрле кешене илбик,
Мин әйтим, син тыңла, бу сиңа — белек.

Бере — алпар, корыч йөрәкле батыр —
Кылыч илә илгә хезмәт күрсәтер.

Икенчесе — белкә, оештыручы,
Үз эшен бик белгән киңәш бирүче.

Өченчесе — юньчел бетекче була[5],
Эшен шәп башкарса, хәзинә тула.

Шундыйларны менә ала бел сайлап,
Хезмәтенә күрә бүләклә, сыйла.

Шуннан эшең инде җайланыр синең,
Киңәер җирең һәм көчәер илең.

Дан алган булырсың, исемең — изге,
Галәм халкы күрмәк булыр йөзеңне.

Акыллылар дөрес әйткәннәр аны:
Изге кеше үлсә дә үлмәс даны.

Ни һәйбәт, кара син, изгедән булып,
Яхшы атың калса, тик үзең үлеп.

Әгәр изге булсаң тереклегеңдә,
Рухың тере кала, тик тән — гүрендә...

Озын гомер түгел, изге ат телә.
Син һәрчак тересең изге ат белән.

---

[2] Җилек ашату — күрәсең, борыңгы фразеологизм, «сыйлау, җиңеллек китерү» дигән сүз.
[3] Билек — башында бий торган географик өлкә.
[4] Бийлек — «бий вазифасы».
[5] Моннан аңлашылганча, бетекче язучы гына түгел, «дәүләт секретаре» булган.

**Нәрсәгә ирешер түрә — канунчы,
Аермаса сүзнең ялганын-чынын?**

Озын гомерме, йә изге атмы
Хәерлерәк, батыр, син миңа әйтче?!

Терелекнең чыны изге гомерләр.
Һәрвакыт тереләр — алар изгеләр.

Кылыгы-кылмышы изге зат — тере,
Яман-юньсез терек килеш тә үле...

Кичәр дөнья, кичмәс изге кылмышың,
Шуның белән үрнәк булып калырсың.

Вафасыз дөнья йөз чөерсә, кыен,
Шунда изге атың-терәк, кузыем.

Бу дөньяң белән бик мавыкма, илбик,
Алда барсын фани мал түгел, белек!

Бер уен кебек ул — бу дөнья эше,
Нә аягы юньле, нә аның башы.

Кермә бу уенга, үскерем, саклан,
Элмәк ул муенга, анда катнашсаң.

Укы — шәп язылган мәгълүм китапта
(Онытма, булдыклым, һич тә бу хакта):

«Бу дөнья эше, күр, комар ул, комар,
Комарлы уенда кем генә уңар?!

Ходай әмрен үтә, аңар бәндә бул,
Югыйсә элмәккә әзер хәлдә бул»

Менә, илбик, әйттем бар белмешемне,
Бер дә яшермичә эчем-тышымны.

Сүзеңне тотсаң тот, тотмасаң инде
Бел, ләкин, тотмасаң, отмассың, димен.

ИЛБИКНЕҢ ҖАВАБЫ

Илбик әйтте торып: —Тәүфыйк телимен,
Ходайдан сорыймын күңел төзлеген.

Ходай теләсә һәм бирсә ярдәмен,
Мин белмәгәндә син ачыкла, яме.

Тырыш, тыштан-эчтән барча эшкә бак,
Уяу, җете күз бул, колак тот — бул сак.

Көч җитсә, эшли тор, каран миңа
Вакыт калса, ярдәм кылырмын сиңа.

Сүзен кисте илбик, ял бирде телгә,
Һәм Үгделмеш чыгып китте сем генә.

Атын менде, янә килде өенә,
Керде дә арынды тышкы киемнән.

Төн уздырды, иртән янә атланып
Сәрайга килде һәм эшен башлады.

Шуннан соң Үгделмеш бик тә тырышты,
Аягүрә кылды бар кирәк эшне.

Халык та кинәнде, дөнья саф булды,
Илбик тә сөенде һәм гел шат булды.

Аңар изге дога илә ил тулды,
Аты калды — мәңге онтылмас булды.

Ни шәптер ки илгә изге заң булса,
Илбик шуның илә эш иткән булса.

Менә шундый булса би — ил башчысы,
Көләч-шат булачак халык барчасы.

Халык күндәм булса, ачык күңелле,
Яхшы була шуннан илләрнең көне.

Бийләрне, асылда, Тәңре күндерә,
Алар иге булса, халык көн күрә.

Халык исәр булса, бийләр дә исәр,
Исәргә исәрме — бер-берен кисәр.

Халык юрыгында — биләрдә кылык,
Бийләр юрыгыннан торадыр юрык.

Шулай итеп, кичте ничә көн һәм ай,
Дөньялар ямьләнде, халык булды бай.

**Акыллылар дөрес әйткәннәр аны:
Изге кеше үлсә дә үлмәс даны.**

Томан-тузан китте, көн булды ачык,
Сафланды, сөзелде барча болганчык.

Шөкер кылды илбик, күп шөкер кылды,
Ходайга туктаусыз мактау укыды.

УЙГЫРМЫШНЫҢ ХАСТАЛАНЫП ҮГДЕЛМЕШНЕ ЧАКЫРУЫ

Шулай, төннәрдән бер төнен Үгделмеш
Ятмак булган иде ястанган килеш,

Дөбердәде капка, каты өн килде.
Бәк кеше җибәрде — «багып күр», диде.

Йомышчы тиз кайтты: — Бер ир торадыр,
«Сүз бар», ди, керергә рөхсәт сорады.

Тик Үгделмеш әйтте: — Сөйләсен сүзен,
Нишләп йөри икән, кем икән үзе.

Янә чыкты углан, әйттерде сүзен,
Каян килмешен һәм теләген, үзен.

— Уйгырмыш, — диде ир, — җибәрде мине,
«Кардәшемә сүзем бар иде», — диде.

Керттеләр юлчыны, ул хәбәрләде
Уйгырмышның сүзен һәм хәл-әхвәлен.

Үгделмеш тә торды, ишеккә килде,
Ул ир эчкә керде һәм «Сәлам!» диде.

—Каян киләсең син,— диде Үгделмеш, —
Теләгең ни егет, сөйлә, нинди эш?

Бу әйтте: — Уйгырмыш мине көндерде,
Сиңа ул «тиз генә бер килсен», диде.

Авыр хәлдә күңле, ята интегеп,
«Бер генә сәгатькә килсенче», — диеп.

Җавапта Үгделмеш әйтте көлебрәк:
—Дөрес әйткән булсаң, китәрбез бергә.

**Әгәр изге булсаң тереклегеңдә,
Рухың тере кала, тик тән — гүрендә...**

**Бу дөньяң белән бик мавыкма, илбик,
Алда барсын фани мал түгел, белек!**

Ошатмады теге: — Кардәшең хәле
Авыррак, турая кебек ич юлы[6].

Синнән элгәрерәк мин бара торыйм,
Син инде әзерлән, и, холкы тугры.

Капкага юнәлде тиз генә юлчы,
Үгделмеш, аптырап, кулларын уды.

Бүлмәсенә керде, кинәт кайгылы,
Сөенече китте, сагышы олы.

Ятырга угалады — йокы килмәде,
Төне елдай, тынып-ятып булмады.

Күзен уалады куеп йодрыгын.
Йокы очып китте күзеннән чыгып.

Шуннан соң торды һәм бераз утырды,
Сары таң атты һәм шәфәкъ яктырды.

Чәчәклектә былбыл сайрап җибәрде,
Күңелне кузгатты — давыл кубарды.

Ат менеп кардәшен күрергә чапты.
Барып кулын, битен үбеп уятты.

Ә кардәше исә сузылып яткан,
Аста чикмән, өскә җиңнәрен япкан.

Сорады Үгделмеш: — Кардәш, ни булды?
Сине күрдем исә күңелем тулды.

УЙГЫРМЫШНЫҢ СҮЗЕ

Әйтте: — И, кардәшем, юлым туп-туры,
Үлем арттан куа. Барасы булыр.

Тагын бер күрим, дип, нурлы йөзеңне,
Китәрем алдыннан борчыдым сине.

Дәвамы бар ■

[6] Юлы тураю, күрәсең, борыңгы фразеологизм, «үлү хәлендә», «үлемгә йөз тоткан» мәгънәсендәрәк.

Безнең мирас №4 апрель 2017

ЧЫҢГЫЗХАННЫҢ АК БОЛЫТЫ

Романга бәян

Чыңгыз Айтматов
(1928-2008)

Кайчандыр кемгә булса да гаепләү итеп ябыштырылган «халык дошманы» мөһере, әсир аркасына уелган йолдыз кебек, куптарып ала торган түгел. Аңардан бары тик теге яки бу төрле җәзаны алып – атып үтерелү, егерме биш, унбиш яисә ун елга иректән мәхрүм ителү белән генә котылып булачак. Мондый очраклардан башкача чыгуны күтәргә мөмкин түгел. Җәза бирүче генә түгел, халык та «дошман» дип ябыштырыла торган бу мөһерне бертөсле укый: әлеге тылсымлы төшенчә, ничектер этәрелеп, көч алып китсә, дошманнарны «ахыргача фаш итү» өчен җәлладның кулына теләсә нинди корал биреп, даими рәвештә аны җинаятькә этәрәчәк, ә канлы иблиснең корбаннары һәм аңа кул чабучы гавам илнең бу фаҗигасен изге максатка туры килүче ихтыяҗ дип кабул итәргә тиеш була. Чынлап та шулай түгелмени! Зиндан стенасына, сугыштагы кебек, «Сталин өчен!» дип каннары белән язып китүчеләр кайсы окоптан чыгып, нинди пулемет авызына капланалар?

Поезд тәгәрмәчләре Сарүзәк далалары буйлап алга тәгәрәде. Тансыкбаев белән аның тоткыны бер вагонда баралар иде. Майор фикеренчә, аларның һәркайсы, үзенчә булса да, хезмәт ияләренең бәхете хакына әлегәчә посып яткан идеологик дошманнарны фаш итү турында кайгырта, чөнки социализм моннан башка асыл мәгънәсен югалтыр, үзеннән-үзе таркалып-таралып төшәр, кояш астындагы күлдәвек кебек кибеп парга әйләнергә мөмкин иде. Шуңа күрә һәрдаим кем беләндер көрәшү, кемнедер фаш итү, нәрсәнеңдер тамырын корыту таләп ителә. Моның өчен бер яктагыларны – вакытыннан алда яңа дәрәҗә, икенче яктагыларны, бераз көттеребрәк булса да, үзләре «сигнал» җибәреп фаш иткән танышларыннан бушагач, рәшәткәле тәрәзә күтә...

Ә поезд тәгәри. Әбүталип, поездны туктатудан гаҗиз булган кебек, берничек тә ачы язмышын үзгәртә алмый, котылгысыз золым белән килешергә мәҗбүр иде. Хәзер ул боларның барысына да шулхәтле буйсынып һәм өметен өзеп карый, баштагы авырту тойгысы тупасланган һәм тәвәккәл каршы килү дәрте, булмаган да кебек, сүнгән. Инде, яңадан дөньяга туарга туры килсә дә, Тансыкбаев артында торган төссез, кешелексез көчкә буйсынудан котылып булмасын аңлый ул. Бу көч сугышта һәлак ителүдән куркынычрак һәм әсирлектә түбәнсетелүдән мыскыллырак, чөнки аның ахыры-азагы күренми, ул дөнья яратылганнан бирле килә иде, ахрысы. Ихтимал, Әбүталип Куттыбаев, тыйнак кына мәктәп мөгаллиме, кешеләр арасында, дәҗҗал белән йөзгә-йөз килеп, аның Галәм киңлекләрендә шактый озак эшсезлектән интегүе өчен җавап тотучы затларның берседер. Әйе, бары тик адәмнән азган ерткыч кына гасырлардан гасырларга үз ишләренең тамырын корытып баручы золым иясе була ала... Икенче яктан караганда, Әбүталип, «Сарүзәктә җәзалап үтерү» риваятен искә төшереп, Тансыкбаевны дөя аркасындагы дар агачының икенче башына «тигезләү» өчен асылган ком капчыгы итеп күз алдына китерә. Ул да, мескен, үзләре корган үрмәкүч тозагының корбаны түгелме икән? Иртәгә бүләк алып, берсекөнгә адәм рисвае булып йөрер көннәре килер бит әле аның да, дип, вакыт-вакыт, рәхимсез җәлладын

Башы журналның 2016 елдагы 8 нче санында. Тәрҗемәче – **Мөдәррис Вәлиев**.

чын күңелдән кызгана иде Әбүталип. Бер поездда, бер махсус вагонда, гадәттән тыш мөһим бер эш буенча бергә барулары да аны шундый уйларга этәрә иде.

Тансыкбаевны төрле станцияләрдә җирле дәрәҗәдәге хезмәттәшләре каршылап, мөһим эшеннән бүлеп тордылар, кем – дуслык хакына, кем ялагайланып кына аңа төрле юл ризыклары һәм затлы эчемлек китергәндә, Әбүталипны бу хәтта шатландырды, – тегенең сорау алу белән интектерергә вакыты азрак кала иде. Юл рәхәтен күреп барсын, әйдә. Кызыл Урда вокзалында бигрәк тә җылы очрашу булды, – дуслары Тансыкбаев вагонына ак сөлге белән капланган, буы күтәрелеп торган табак күтәреп килгәннәр. Ишек төбендә сый-хөрмәтне кабул итүче сакчыларның берсе: «Казы, кабырга! – дип ярымпышылдап, авыз суларын көчкә йотып куйды. – Исе генә дә ни тора! Шәһәрдә мондыйны таба алмыйсың. Дала ите шул!»

Тансыкбаевның, шинелен җилкәсенә генә салып, перронга рәхмәт әйтергә, саубуллашырга чыкканын күрде рәшәткәле тәрәзә читеннән Әбүталип. Түгәрәкләнеп басканнар, минсиңайтим, барысы да сайлап алган кебек нык, таза гәүдәлеләр, бүрткән кызыл яңаклы йөзлеләр, елмаюлы тук чырайлылар, бик дәртләнеп кулларын болгыйлар, дәррәү көлеп җибәрәләр, – күрәсең, яңа анекдоттандыр, – салкын һавада авызларыннан кайнар пар бөркелә, башларында каракүл бүрек, юка гына кар өстендә, мөгаен, үкчәләре шыгырдыйдыр. Ә һәрвакыт уяу милиция бу тирәгә берәүне дә якын җибәрми, – махсус вагон янында майорны саклаучылар баскан, үз-үзләренә ышанган, бәхетле халык, мәхбүсләр купесында алар богаулап керткән – карак түгел, кемнедер көчләгән яки үтергән кеше түгел, ә, киресенчә, намуслы, әдәпле, сугыш һәм әсирлек газапларын кичергән, балаларына һәм хатынына мәхәббәттән кала бүтән табынуы булмаган, шул мәхәббәттә тормышының төп мәгънәсен күргән зат интегеп утыруында берсенең дә эше юк. Нәкъ менә шундый, дөньядагы бер фиркадә дә тормаган һәм шуңа күрә кайсыдыр почмакка башын орып ант та эчмәгән, тәүбә дә итмәгән кеше аларга, хезмәт халкы бәхетле яшәсен өчен, төрмә сәкесендә ятарга кирәк булып чыкты...

Кызыл Урдадан соң таныш, күңелгә якын җирләр башланды. Кич җитеп килә иде. Кар баскан түбәнлекләрдә, бөгелеп-сырылып, Сырдәрья ялтырап китте, һәм, инде кояш чыгып барганда, дала уртасында Арал диңгезе күренде. Баштарак әле камышлы текә борылмасы ачылды, аннары, ерактагырак чиста суы йә утраучыгы белән, диңгез үзенең барлыгын сиздерергә тотынды, ә тиздән Әбүталип тимер юлның янында ук диярлек юеш комда диңгез ярына бәрүче дулкыннарны күрде. Боларның һәммәсен: карын, комын да, яр буендагы ташларны да, җил иркендәге диңгезне һәм ташлы ярымутраудагы коба дөя көтүен дә – әле бит боларның барысы да анда-санда таралган болытларның ак таплары белән чуарланган биек күк астында, – аларны берьюлы бер мизгел эчендә күздән кичерү гаҗәп иде.

Әбүталипның исенә төште: Буранлы Идегәй – Арал диңгезе тумасы, ә Казангап таныш балыкчыларыннан товар поездын озатып йөрүчеләр аша үзе яраткан киптерелгән арал балыгын әрҗәләп ала иде, һәм йөрәге кабат борчылып кысылды – Буранлы станциясенә инде ерак та калмады – төн кичәсе генә, ә иртән, сәгать уннарда яки чак кына соңрак, махсус вагон таккан пассажир поезды гүләп килеп чыгар да, Буранлының җилләрдә таушалган кечкенә йортлары, чәнечкеле кибәннәре, киртәләнгән кура һәм дөя каралтылары яныннан ыжгырып үтәр, бер-берсенә ялганып күзне камаштыра торган тимер юлларны артта калдырып, шунда ук, булмаган да кебек, күздән югалыр. Кояш чыгышыннан кояш батышына һәм кояш батышыннан кояш чыгышына таба үткән хисапсыз поездларны кем санаган, әмма Зарипага, ул таңда, кояш батышына таба махсус вагонның мәхбүсләр купесында Әбүталип узып китәчәген йөрәге әйтерме, ә бәлки, нәкъ шул сәгатьтә улларының күңеле нindидер аңлатып булмый торган киеренке бер тойгы кичерер дә, алар поезд каршыларга

йөгереп чыгарлар? Йа Раббым, кешеләргә шулкадәр авыр һәм ачы язмышны ник бирдең икән?

Февраль кояшы инде офык артына тәгәри, еракта, җир белән күк арасындагы, салкын булса да, мич авызыннан чыккан кебек алсу балкышка уралып сүнеп килә, озак та үтми, дала киңлегенә кышкы төн пәрдәсе төшәр. Эңгер-меңгер эченә әле генә күзгә чалыныр-чалынмас торган күренешләр кереп югала, станция утлары кабына. Ә поезд, суга баручы кыз кебек борыла-сырыла, дала төненә сукмак сала...

Йокы алмый интектерде Әбүталипны. Калай белән тышланган купе-камерада бикле килеш, ул үзенә урын таба алмый, почмактан почмакка бәргәләнә, уфыра, әледән-әле, назирның ачуын китереп, бер йомышсыз әбрәкәйгә чыгарга сорый. Тегесе инде, купе ишеген бераз ачып, берничә тапкыр кисәтү дә ясап алды:

– Тоткын, син нәрсә һаман кыжмырдыйсың? Болай ярамый! Тыныч кына утыруыңны бел!

Әмма Әбүталип үз-үзен тынычландыра алмый иде, шуңа күрә, кизү торучыга ялынмый булдыра алмады:

– Тыңла әле, ялварып сорыйм, туган, йоклап китәргә ни дә булса бирче, югыйсә үләм бит. Ипидер әгәр! Ә мин үле килеш сезгә кирәкме? Башлыгыңа әйт, – үлсәм, минем белән нишлисез? Чынлап әйтәм, бер тамчы йокы алмый!

Ничек кенә сәер булмасын (бу кадәр тиз хәленә керүнең сәбәбен Әбүталип икенче көнне иртән аңлады), назир Тансыкбаев купесыннан ике төймә йокы даруы алып килде, һәм шуннан соң гына, дару эчкәч, инде төн уртасында Әбүталип йокымсырап китте, әмма барыбер чынлап торып йоклый алмады. Йокымсыраган хәлдә, тәгәрмәчләр тукылдавы һәм тыштагы җил улавына колак салып, төшләнеп ятты: имеш, ул, тәгәрмәч астына эләгүдән куркып, тыны кабып, хырылдап, паровоз алдыннан йөгерә, ә поезд аның артыннан бөтен көченә чаба икән. Паровоз алдыннан шпаллар буйлап ул җенле төндә йөгерде дә йөгерде, бу бастырылу, чынлап та өндә булган кебек, шулхәтле ачык һәм куркыныч иде. Тамагы кипте, сусады. Ә паровоз аның артыннан, ут бөркүче фаралары белән өтеп, һаман куа килде. Ул, буран уйнаган юл читенә карый-карый, рельслар арасыннан җан-фәрманга йөгерде, гаҗизләнеп ярдәмгә чакырды: «Зарипа, Даул, Эрмек, кайда сез? Минем янга йөгерегез! Бу мин, сезнең атагыз! Кайда соң сез? Аваз бирегез!» Беркем дә дәшми, алда кара бушлык, ә артта – менә таптыйм, менә изәм, дип, дөбердәп килүче паровоз. Бу өскә баса-баса куган албастыдан качарлык хәл калмады... Шунлыктан тагын да авыррак була барды – курку, өметсезлек аякларны богаулый, гәүдә тыңламый, сулыш өзелә иде...

Иртә таңнан, җилкәсенә сырмасын салып, агарынган, битләре җилсенгән Әбүталип инде рәшәткәле тәрәзә буенда утыра һәм далага карап бара иде. Тышта әле караңгы, салкын да булырга тиеш, әмма, таң атуын белгертеп, әкренләп көн ачыла барды. Һава болытлы, күктә аяз уйдыклар күренсә дә, кар явуы бик ихтимал...

Әйе, инде Сарүзәкнең төп җирләре башланды, аларны кыш дәвамында кар баскан, кайбер төшләренә көрт өелгән, шулай да, игътибар беләнрәк карасаң, кашлык урыннарны, чокыр-чакырларны чалымлап була, ара-тирә тораклар кала, аларның морҗаларыннан иртәнге мич-учак төтеннәре күтәрелә. Бу чит-ят түбәләр дә өсләрендә эңгер булып тирбәлгән кышкы төтеннәре белән күңелгә якын иде. Тиздән Кумбель станциясе, ә аннан, өч сәгать тирәсе баргач, – Буранлы. Күршедә генә дип әйтергә була, – монда Идегәй белән Казангап йомыш төшкәндә дөяләрдә дә килгәлиләр иде, – мәет ашларына, туйларга... Менә әле дә, бу иртәнге сәгатьләрдә, башына төлке тиресеннән тегелгән зур колакчын бүрек кигән кемдер, коба дөягә атланып, дала буйлап бара. Әбүталип рәшәткәгә үк сыланды – ә, бәлки, безнекеләрдән берәрсе булып куяр... Әйтик, Идегәй, үзенең Каранарын иярләп, нинидидер эш белән бу якларга

килеп чыкмас, дип, кем әйтә ала? Куәтле ата дөясендә эһ дигәнче йөз чакрымны узу аңа ни тора? Чапса, кайдадыр Африкадагы жирафтан кимен куймый иде бит Каранар.

Һәм, ничектер, үзе дә аңышмастан, Әбүталип поездан төшәргә тиешле кеше кебек җыена башлады. Ике мәртәбә аягына киеп салды, чолгауларын яңадан әйбәтләп урады. Юл капчыгын тотырды. Һәм көтә башлады. Шулай да утырып тора алмады, сакчылардан иртәрәк юынырга рөхсәт сорады, тик купега әйләнеп кайткач, тагын үзенә шөгыль таба алмый кыбырсыды.

Ә поезд Сарүзәк далаларыннан бара иде... Үзенең чын хәленнән аерылмас өчен, Әбүталип кушырылган кулларын ике тезе арасына кыстырып утырды, инде тәрәзәгә дә сирәк кенә күз сала башлады.

Кумбель станциясендә поезд берничә минут торды. Монда инде барысы да үз иде. Хәтта каршыга очраган поездлар да, – товарныкы яки пассажир ташучылар булсын, – Әбүталипка якын һәм таныш булып тоелды, чөнки алар күптән түгел генә Буранлы аша үткәннәр, ә анда аны балалары һәм хатыны көтә. Бу инде җансыз җисемнәрне дә яратырга җитә иде.

Менә поезд яңадан юлга кузгалды, әле ул перрон буйлап барган арада, станциядән чыгып җиткәнче, Әбүталип аңа таныш булып тоелган йөзләрне күздән кичереп өлгерде. Әйе, әйе, һичшиксез, ул аларны, үзе күргәләгән Кумбельныкыларны, белә иде, алар да, мөгаен, Буранлыда элек-электән яшәгән Казангап, Идегәй, аларның гаилә кешеләре белән аралашканнардыр, – Казангапның улы Сабитжан мондагы мәктәпне тәмамлады, шуннан институтка укырга китте...

Станция юлларын артта калдырып, поезд тизлек җыйды, торган саен кызурак бара башлады. Кумбельга балалар белән карбыз алырга, аннары үзе генә яңа ел чыршысы артыннан, башка йомышлар белән килгәне исенә төште Әбүталипның...

Иртән бирелгән ризыкка Әбүталип хәтта кагылмады да. Буранлы станциясенә бик аз ара – ике сәгать ярымлык юл калган иде, шул турыда уйлап, инде хәзер ул, кар ява күрмәсен дә буран чыкмасын, дип курыкты, – ул чакта Зарипа белән балалар өйдә утырачаклар, һәм ул аларны еractан да күрмәячәк...

«Йа Хода, – дип эченнән ялварды Әбүталип, – бу юлы гына карыңны туктатып торсана. Бераз түз инде, аннары туйганчы яудырырсың. Язга кадәр вакыт күп бит әле. Ишетәсеңме? Бик үтенеп сорыйм!» Үзалдына йомылып, кушырган кулларын янә тезләре арасына кыстырып, Әбүталип фикерләрен бер төенгә җыярга, сабырлыгын тупларга тырышты, – аның сораганын Күкләр ишетсен, вагон тәрәзәсе аша гына булса да хатынымны һәм балаларымны күрергә язсын иде, дип ихластан тели, шул мизгелне түземлек белән көтәргә разый иде ул. Ә менә алар да аны күрсәләр... Иртән, ишек артында кизү торган назир күзәтчелегендә битен-кулын юганда, ул күгәргән юынгыч өстендәге яшел төс иңгән иске көзгегә күз салды һәм үзен танымады: күзләрендәге очкын сүнгән, чәчләре чаларган, чырае идән астында үргән бәрәңге сабагы кебек аксыл, үлекнеке шикелле сары, маңгаендагы, йөзендәге җыерчык буразналары шулкадәр тирән уелып кергән, – хәтта немец әсирлегендә дә мондый бетәшкән түгел иде ул... Ә бит картлык турында уйларга әле иртәрәк... Уллары Даул белән Эрмек, хатыны Зарипа күрсәләр, мөгаен, танымаслар, – куркып калырлар. Шулай да өенә әйләнеп кайта алса, шатланырлар иде, ул үзе дә, балалары һәм хатыны янында тынычлык табып, яңадан элеккеге хәлен торгыза алыр иде кебек...

Шулар хакында уйланып, Әбүталип тәрәзәгә күз салгалап барды. Менә яңадан таныш ике кашлык, арасында дөя өркәчедәй батынкы урын бар. Буранлы бала-чагасы белән шунда барырга, алар, дулкыннан дулкынга сикергән кебек, чыр-чу килеп, сөенә-сөенә, кашлыктан кашлыкка йөгереп уйнасыннар, дип хыялланган чаклары искә төште.

Шулвакыт тоткын купесындагы ишек йозагына кискен генә шылтыратып ачкыч тыктылар, бусагада ике назир пәйда булды.

– Сорау алуга чык! – диде аларның берсе, өлкәнрәк дәрәҗәдәгесе булса кирәк.

– Нинди сорау алу? Ничек? Нишләп?

Әбүталипның мондый кыланышын болар көтмәгән иде, әлбәттә.

Өлкән назир хәтта аңа якынрак килде, күзләрен акайтып, беренче күргәндәге кебек текәлеп карады, ычкынмаганмы бу, янәсе:

– «Нишләп» – нәрсә дигән сүз? Аңламыйсыңмы әллә, сорау алырга дәшәләр сине!

Әбүталип, өметсезләнеп, башын түбән иде. Бер булмагач, булмый икән. Тәрәзәгә сыланып, шулхәтле көткәнне күрермен дип өметләнде бит. Инде, һични уйлап тормыйча, тәрәзәгә ташланыр иде, әмма анда – тимер рәшәткә... Буйсынмый чара юк. Әбүталип, җилкәсенә авыр йөк салган кешедәй, әкрен генә урыныннан кузгалды һәм, назирлар озатуында, дар агачына барган кебек, Тансыкбаев купесына китте. Шулай да соңгы өмет чаткысы сүнмәгән иде – алда әле сәгать ярымлык чамасы юл бар, бәлки, аңа хәтле сорау алу да төгәлләнер. Бөтен ышаныч шунда гына... Тансыкбаев купесына кадәр нибары дүрт адым. Шул дүрт адымны Әбүталип бик озак барды. Ә тегесе аны көтеп тора иде.

– Кер, Куттыбаев, гәпләшеп, эшләп алыйк әле, – йөзе һәм тавышы кырку булып күренсә дә, яңа гына кырынып, әче исле хушбуйга манчыган яңагын канәгать төстә сыйпаштыргалап, үткер күзләре белән Әбүталипны чишендергән төсле, сөйләнеп каршылады Тансыкбаев. – Утыр. Утырырга рөхсәт итәм. Сиңа да, миңа да шулай уңайрак булыр.

Сакчылар, бер сүз дәшү белән керергә әзер булып, ишекнең теге ягында калды. Ә лачын күзлене барыбер болай гына үтерергә мөмкин түгел. Кул астында берни дә юк. Ни шешә, ни стакан күренми, гәрчә, җае чыкканда, майор, ялгызы гына булса да, кәгеп алырга ярата. Купедагы аракы һәм кабымлык исе шул турыда сөйли иде.

Поезд, элеккечә үк, Сарүзәк даласын ярып, алга баруын белде, Буранлы станциясенә кадәр юл-ара кыскарганнан-кыскара. Тансыкбаев исә ашыкмый, ниндидер язуларын укый, кәгазь арасында казына. Әбүталип, түземсезләнеп, урындыгында борсаланды, бу тынлык берничә минут эчендә дә аны җәфалап, зарыктырып өлгерде. Әлеге «эшләп алырга» чакыру шулкадәр авыр иде аңа, шуңа, сабырсызланып, Тансыкбаевка сүз катмый булдыра алмады:

– Мин көтәм, гражданин начальник.

Тансыкбаев, гаҗәпсенеп, күзләрен күтәрде:

– Көтәсең? – дип, аптырап, Әбүталипны тагын бер кат күздән кичерде. – Нәрсә көтәсең?

– Сорау алганны. Җавап тотарга...

– Ах вон оно что! – дип русчалап сузып куйды Тансыкбаев, бу минутта тоткыннан өстенлеген тою рәхәте кичерә һәм ачыктан-ачык тантана итә иде ул. – Что ж, бу начар түгел, Куттыбаев, әйтер идем, гаепләнүче, кылган гамәлләренә үкенеп, үз ихтыяры белән сорау алганны көтсә һәм, билгеле, тиешле җавабын тотса, бу – бер дә начар түгел... Димәк, аның әйтер сүзе бар, тикшерү органнарына ачар сере бар. Без икебез дә бер фикердә бит? – Тансыкбаев сорау алуны бүген нәкъ шулайрак, янаудан, сүгенүдән тыелып, баллы-майлы тел белән, янәсе, дустанә алып бару кулай булыр, дип уйлады.

– Димәк, син гаебең нәрсәдә икәнен аңлагансың, – дип дәвам итте ул, – һәм, хәтта үзең дошман булсаң да, тикшерү органнарына ярдәм итәсең килә, Совет властеның дошманнары белән көрәшкә үз өлешеңне кертергә ашкынасың, шуның белән кырыс җәзаны йомшартырга телисең. Синең белән миңа Совет властеның әти-әнидән дә кадерлерәк булуын аңлау кирәк. – Органнарда армый-талмый хезмәт итүче Тансык-

баев, үз-үзенә сокланыпмы, әллә, бик акыллы сүзләр сөйлим бит, дипме, канәгать бер төстә тынып торды һәм аннары өстәп әйтте: – Мин һәрвакыт сине төпле кеше дип уйладым, Куттыбаев, һәм синең белән уртак тел табасыбызга һәрвакыт өметләндем. Ник дәшмисең?

– Белмим, – дип икеле-микеле җавап бирде Әбүталип, – аңламыйм, минем гаебем нәрсәдә, – дигән булды, үзе яшертен генә вагон тәрәзәсенең тышына карап алды. Поезд күктән җиргә кадәр салынган авыр болытлар юрганы астында бик көчәнеп бара, шулай да Сарүзәк даласы, баш әйләндергеч тизлек белән, тавышсыз кинодагы кебек, артка йөгерә иде.

– Минем менә нәрсә әйтәсем килә, Куттыбаев. Ачыктан-ачык сөйләшик әле, – дип дәвам итте майор. – Сине бит, король шикелле, махсус вагонда болай гына алып бармыйлар инде. Аерым купеда теләсә кемне бушка йөртмәгәнне дә беләсең. Димәк ки, син – тикшерү эшендә бик кәттә шаһит. Синнән күп нәрсә тора. Һәм сиңа аерым таләп куела. Уйла. Ныклап уйла. Ә хәзер мин әйткәннәрне тыңла. Бүген кич, соң гына без Ырынбурга, ягъни мәсәлән, Чкаловка барып төшәбез. Анда безне көтеп торалар. Бу – безнең беренче тукталыш. Беләсең, анда ике братаның яши. Попов Александр Иванович һәм татар Сәйфуллин Хәмит. Икесе дә инде ышанычлы сак астында. Сүз уңаенда исеңә төшерим, алар синең күрсәтүең буенча утыралар. Икесе дә синең белән Бавариядә әсирлектә булуларын таный. Аннары бергәләп качкансыз, – бик сәер шартларда, – чөнки таш чыгара торган җирдән, ни өчендер, сезнең бригада гына кача алган, бусын әле без ачыкларбыз. Аннары Югославиядә сыену урыны тапкансыз. Аларның икесе дә шунда Англия миссиясе белән очрашуда булганнарын күрсәтә. Ни-нәрсә турында сүз барганын син яхшы беләсең. Болар хакында истәлекләреңдә үк тәфсилләп теркәгән идең. Кызыклы гына язмалар, минсиңайтим. Безгә Попов – резидент, ә Сәйфуллин – аның уң кулы һәм, кирәк була калса, аны алыштырырга әзер торучы кеше икәнлеге мәгълүм. Син, Куттыбаев, билгеле, агентурада йомышчы малай гына, шуңа күрә, тикшерү эшендә ярдәм күрсәтсәң, шактый җиңел котыла алырсың, дип уйлыйм.

– Ниткән агентура? Әйттем бит инде, минем кырык бишенче елдан, сугыш беткәннән бирле аларны күргәнем юк, – дип бүлдерде Әбүталип.

– Анысы әһәмиятсез нәрсәкәй. Бөтенләй мөһим түгел. Шәхси очрашу, икәүдән икәү калып сөйләшү турында сүз бармый. Арада кемдер элемтәче булган. Әйтик, шул ук гаделлек яратучы Идегәй Җангилдин, ди. Ул Ырынбурга яки башка җиргә бармадымы? Сезнең кем ашадыр элемтә тоткан булуыгыз да бар бит. Син башта уйлап бетер.

– Әгәр Идегәй Ырынбурга үзенең дөясе Каранар белән барды, дисәм, шул җитәме? – Әбүталипның түземлеге төкәнгән иде.

– Син һаман үз кирең... ябышасың, Куттыбаев. Юкка гына. Мин бит яхшылык белән сөйләшмәкче булам, тик син артың белән борыласың. Каршы торуың сиңа зыянга гына. Ә Идегәй мәсьәләсендә борчылма, бездә урын җитәрлек, кирәк булса, аны да алырбыз, хәтта дөясе белән дә сыяр. Аңа тимәсеннәр, дисәң, күзгә-күз очрашу вакытында җүләр сатма.

Дәвамы бар ■

Безнең мирас №4 апрель 2017

КАБЕРДӘН ТАВЫШЛАР

Халит Зыя Ушаклыгөл

Госманлы әдәбиятының Яңарыш чоры вәкиле Халит Зыя Ушаклыгөл (1867-1945) әсәрләре XX йөз башы татар әдипләре тарафыннан яратып укыла һәм тәрҗемә ителә. Иҗаты Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан, Ш.Камал, Н.Гасрый һ.б. каләменә уңдырышлы тәэсир итә. Кешелек дөньясы, яшәү һәм үлем, фани һәм бакый дөнья, барлык һәм юклык, яшәү мәгънәсе кебек мәңгелек темалар Х.Зыя иҗатында төп сюжет сызыгы булып бара. Галимҗан Ибраһимов «Изелгән, йөрәге хәлсезләнгән төрек эченнән ничек шулкадәр дәрәҗәдә гарешкә, тәңренең үз хозурына оча алырлык рух, бер йөрәк, бер куәт чыга алган – хакыйкатән, шашылачак хәл», – дип яза. Төрек әдибенең зур югалту кичергәч – әнисе үлеменнән соң иҗат ителгән «Мәзардан сесләр» нәсере татар әдәбияты дөньясында аеруча киң таралган. Габдрахман Сәгъди 1910 елда – Истанбулда яшәгән вакытында – әлеге әсәрне татарчалаштырып: «Мәзардан сесләр» шулкадәр мәзияти хавидер ки[1]: һәм тәсаувыф, һәм әхлак, һәм фәлсәфә, һәм әдәбият, һәм фән китабыдыр, дисәм, мөбаләга булмаз[2]... Имди, шундый газиз бер әсәрдән, үзем файдаланган шикелле, үземдән башка минем кеби гаҗиз бер адәмдән истифадәгә[3] мохтаҗ улган, ягъни төрекчә белмәгән мөхтәрәм милләтдәшләремне дә файдаландыруны үземә бөек вә лязем бер вазифа буларак, тәрҗемәсене мөнасиб[4] күрдем», – дип искәртә.

Әсәр «Шура» журналының 1910 елгы 7 нче санында «Кабердән тавышлар» исеме белән басылып чыга. 1912 елда нәсер 37 битлек китап булып дөнья күрә. Г.Сәгъди «Символизм турында» дигән китабында нәсерне француз декадентлыгы тәэсире астындагы госманлы символизмы үрнәге буларак бәяли. Әсәр экзистенциализм фәлсәфәсенә – яшәүнең мәгънәсен ачарга омтылуга, яшәешнең ялгыш кануннарга корылуы өчен кайгыручы, куркучы, чарасызлык баскычына атлаучы лирик «мин»нең рухи дөньясын ачуга корылган. Төп эчтәлек кабердән килгән тавыш – монолог аркылы лирик «мин»нең хис-кичереше, дөньяга мөнәсәбәте, күзаллавы үзгәрүе кебек тәкъдим ителә. Лирик герой хакыйкать буларак аңлашылган каберлектән ишетелгән тавыш аркылы тормышның ялгыш һәм ялган булуын аңлый, яшәү мәгънәсе хакында уйлану баскычына аяк баса. Әсәрдә әт-тәүхид фәлсәфәсе алгы сызыкка чыга: кабердән килгән сүзләр изге Коръән китабының серләрен ачуга хезмәт итә, хакыйкатьне чагылдырырга омтыла.

Алия Мөбарәкшина

Яз көне иде. Күбдән бирле яңгыр ява иде. Һәм дә күк йөзене тәмам кара болыт каблаган, яңгыр да һич өзлексез һәмишә[5] ява иде. Яңа гына яшәрергә башлаган үләнләр дә, яңгырдан башларыны иеб, йиргә ятканлар иде. Әлхасыйль[6], бөтен дөньяны тәмам күңел караткыч бер караңгылык каблаган иде. [...] Бераз соңра шундый бер сәгать килде ки: тәрәзәләремне моңлы тавыш белән бәребләреб яуган яңгыр тәмам тынды. Һәр тараф тирән бер секундка талды. Күк йөзене каблаган калын кара пәрдәләр дә бер читдән ертылырга башлаб, кояшдан нурлар сачелергә, бер-бере илән уйнашырга, куышырга тотындылар! Менә шул вакыт мин дә тышка чыгыб йөрергә тели башладым. Чөнки күбдән бирле, һичбер йиргә дә чыкмыйча, бер өйдә бикләнеб яту мине бик ялыкдырган; күңелемне бик яман бер караңгылык баскан иде. Бинаән галәйһи[7] бераздан соңра сахрада булындым. Мин һаман китә идем. Фикерем бер йирне билгеләгән иде. Һаман шул йиргә таба китә идем. Ул йир каберлек иде. Белмим нигә, каберлекгә баруны тели идем.

[1] Мәзияти хавидер ки – яхшы сыйфатларны эченә алган.

[2] Мөбаләга булмаз – арттыру.

[3] Истифадәгә – файдалану, куллануга.

[4] Мөнасиб – яраклы.

[5] Һәмишә – һаман.

[6] Әлхасыйль – җыеп әйткәндә.



Мәшһүр төрек язучысы
Халит Зыя Ушаклыгөл
(1867-1945)



Халид Зыя. Кабердән тавышлар.– Уфа: «Шәрык» матбагасы, «Каримовъ, Хусаиновъ» электротипографиясе , 1912. Мөтәрҗиме: Габдрахман Сәгъди

Каберлекгә йитдем. Капкасы төбендә туктаб, бераз вакыт тик кенә торыб, үлекләрнең бу дөньясыны сәйр[8] вә тамаша итдем. Бу йирне, ягъни үлекләрнең бу икамәтгяһләрене[9], бу йортларны шулкадәр моңлы, шулкадәр куркыныч бер рәвешдә күрдем ки, эченә тиз генә кереб китәргә батырчылык итә алмадым. Бер кәфен кисәгенә төрелеб дә, караңгы тирән бер упкынга ташланган бу үлекләр өстендә җанымны гиздереб йөрүдән өркә башладым. Шулай булса да, өркү, бу курку минем өчен шул кадәр татлы, шул кадәр җазибәле иде[10] ки, түзә алмадым, ирекле-ирексез, тетри-тетри булса да капканы ачдым. Бу көнгә хәдле, бер кабат улсын, ачылыб кермәгән бу зур вә иске капка тик авырсыныб кына, шыгырдый-шыгырдый ачылыб, миңа юл бирде – каберлекнең эченә кердем. Кереб, бер-ике адым атлар-атламаз каты бер тавыш ишетдем. Әйләнеб карасам – каберлек капкасы ябылган имеш! Ләкин бу тавыш мине бер адәм гомеренең соң сәгате сукган шикелле бик куркытды. Гаять мөтәэссир улдым[11]. Чөнки бу йир – киң бер каберстан! Тирән бер секунд! Дөньяга килүемезнең куркыныч, өмидсез табышы иде! Каберләр арасындан бер күләгә кебек үтеб-үтеб китә башладым. Аякларым да үлекләрнең бу моңларны, бу тирән секундларны һич бозасы килмәгән шикелле, бик сакланыб кына басыб, мине һаман алга таба илтәләр иде. Ләкин ошбу вакыт хәят галәмендән шул хәдле ераклашкан идем ки, хәтта үземнең терек улыб-улмавымдан да шөбһәләнергә башлаган идем. [...]

Һушым киткән кебек, куркуымдан югалыб, бер кабер өстенә барыб төшдем. Шул вакыт бер кабер ташына күзем төшде, шул язуны укыдым: «Зияратчы! Син һичсең!..»

Бу ни дигән сүз иде? Һәм дә ни димәк була иде? Бу юкса, бер үлекнең бер тере адәм йөзенә орган бөек бер хәкарәте[12], бөек бер истиһзасымы[13] иде?

[7] Бинаән галәйһи – шуңа күрә.

[8] Сәйр итдем – күзәттем.

[9] Икамәтгяһләрене – тора торган урыннарны.

[10] Җазибәле иде ки – үзенә тартып тора иде ки.

[11] Мөтәэссир улдым – кайгыхәсрәткә төштем.

[12] Хәкарәте – хурлау, кимсетүе.

[13] Истиһзасымы – мыскыл итүе, көлүеме.

«Син һичсең!..» Башка бер йирдә, башка бер вакытда булса, бу сүз миңа ул кадәр каты да тимәс иде. Ләкин бу йирдә, бу вакытда бу ачы сүз бөтен йилекләремә үтде... Үземне гүя итләре чергән, тамырлары өзелеб беткән, коры сөяк җыентыкдан гына гыйбарәт бер хәлдә күрдем. Һәм дә ачы ямьсез бер көлеш илән елмаеб көлдем дә ачуымдан, ниһаять, иренемне тешләргә мәҗбүр улдым. Бар көчемне сарыф итеб, кулларым илән кабергә таяныб, көчкә генә торыб килә идем, тагын истиһза итеб көлгән бер тавыш ишетдем. Башым әйләнде. Бөтен әгъзаларым тетри башлады. Күз алдымда торган агачлар, кабер ташлары да «зыр, зырр...» әйләнгән шикелле була башладылар. Ниһаять, тәмам хәлдән языб, югалыб, яңадан кабер өстенә барыб төшдем. Шул заман кабер астындан гаять куркыныч, гаять ят бер тавыш ишетелергә башлады. Шул сүзләрне сөйли иде: «Бик дөрест! Син һичсең! Ләкин бу сүз сиңа ачы, бик агыр тисә кирәк, зарар юк – тисен! Чөнки хакыйкать дигән нәрсә даимән шулай каты тиячәк, даимән сине чүкечләб вә башканы изеб торачак! Һәм дә шундый бер хакыйкатькә һәр заман колакларыңа шул сүзләрне тукыб торачак. Һич... һич!... [...] Һәр тарафыңны тикшереб кара! Һәммә ягыңдан чолгаб алган шул газамәт[14] хилкать[15], шул чиксез кяинат[16], шул хәдсез-хисабсыз дөньялар эчендә син нисең?!. Син үзеңне бер япрак эчендән тамган тамчы, чык суындагы мәхлуклардан бөек, алардан артыкмы хисаб итәсең?.. Син үзеңне бу көн җан илән тулы сөякләрдән, итләрдән гыйбарәт күрәсең. Ләкин белмисең, бичара, алданасың! Чөнки башка шундый бер көн киләчәк ки: итләреңне йөкләб йөргән шул сөякләрең; тамырларыңны тутырыб, бөтен тәнеңне сугарыб, сине яшәтеб торган шул каннарың сиңа болай һәрвакытда да хезмәт итеб торудан ялыкырлар; әкрен-әкрен череб юк улырлар. Вә шундук, шундый бер сәгать килер ки, хәзерендә шул күкрәгең астында типелдәп тибеб торган йөрәгең ул бер сәгатьдә тәмам тиберсенүендән туктар, сөкүт итәр[17]! Менә шул заманларда син ни улачаксың, беләсеңме? Череб, тузыб беткән бер калеб!.. [...]

И зәваллы! Башыңа шундый бер көн киләчәк ки, ошбу көндә шул сурәтең белән тәҗәссем итеб[18], күренеб йөргән рух ул бер көндә сине ташлаб китәчәк. Син дә чиркин бер сурәт, ямьсез бер гәүдәдән генә гыйбарәт улыб калачаксың! Ул кибкән иренләрең, эчкә баткан нурсыз, сөйкемсез күзләрең, ул ямьсез коточкыч йөзләрең алданыб йөргән хәятеңнең һәм ачы һәм күлүнч бер нәтиҗәсе улачак! Мондан соңра сине янә йиргә табшырачаклар: өстендә яшәмәк сәляхиятендән[19] айрылдыгың шул йирнең астына чукыб күмәчәкләр. Бу исә гаять тирән, гаять караңгы, гаять куркыныч бер кабердер. Тереклегеңдәге котыңны ала торган ул куркыныч кортларның, ул йирәнгеч, чиркин хәшәрәтләрнең оясы мондадыр. Имди мондагы кимерүче тупраклар, мондагы елан, чаянларның ул инсафсыз тешләре сине нинди бер хәлгә китерәчәкләр – беләсеңме?.. Сөякләре ватылган, кимекләре каралган, итләре череб, сөякләре, кимекләре белән катышыб буталыб беткән чиркин бер хәлгә!

Тупрак сине болай гына да калдырмаячак. Изәргә башлаган тәнеңне изә-изә шул хәлгә китерәчәк ки, ниһаять, андан ялгыз бераз сөяк кисәкләре генә калачак. Бара-бара ул сөяк кисәкләрен дә юк итәчәк, менә шул вакыт син нә улачаксың – хәбәрең бармы? Бер уч тупрак!..

Юк, син бер уч тупрак кына да улыб калмаячаксың. Сөйгәнеңне кысыб-кысыб үбәргә хәзер генә торган шул иренләрең, бөтен

[14] Газамәт – бөек.

[15] Хилкать – яратылыш.

[16] Кяинат – галәм.

[17] Сөкүт итәр – аерылып төшәр.

[18] Тәҗәссем итеб – гәүдәләнеп.

[19] Сәляхиятендән – сәләтеннән.

өмидләреңне тотмак өчен, алга таба узанган шул канәгатьсез кулларың, юк-бар әмәлләр илән тиберсенеб торган шул йөрәгең, әлхасыйль, бөтен вөҗүдең йир астында изелә-изелә, ялгыз бер уч тупрак улыб кына эш бетмиячәк. Бәлки җәнабе Аллаһ сине истәгәненчә[20] идарә итәчәк. Синдән нәбатларга[21], хайванларга, һаваларга, суларга өлеш чыгарачак. Зәррәләргә[22] таратачак. [...] Йирдә синдән һичбер әсәр калмаячак. Йир өчен син, йир йөзенә һичбер килмәгән кебек, бөтенләй белемсез калачаксың!..

И мескен! Барлыгың илән алданасың. Синең барлыгың ялгыз бер көзгегә төшергән нәрсә, бер нурдыр. [...]

***

Ләкин син үлүең илән бәрабәр янә бер шәйсең. Ягъни һәм һичсең, һәм дә бер нәрсәсең!.. Синдә бер фәгалиять[23] хәятийә бар. Сине даимән бер кувәи мөтәфәккир[24] гакыл, рух идарә итә. Вөҗүдеңнең һәрбер йирендә бер зәкявәт[25], бер җан әсәре бар. Ишетәсең, күрәсең, сизәсең. Синдә бер нәрсә бар ки, тугърысы син үзең бер нәрсәсең ки: төшенәсең, сизәсең, ләззәтләнәсең, шадланасың, кайгырасың; әлхасыйль, һәр заман һәр төрле тәэсират эчендә бүленәсең.

***

«Һәйһат! Зәваллы инсанлар! Йирнең хәтта бер секунд кадәр генә гомерене дә ишгаль итә алмаган[26] шул аз гына гомерләрне дә нинди юк-бар нәрсәләргә әрәм итәләр. Аны үзләрендәге табигый улган, яратылышларындагы биеклекләрендән ни хәдле ким, ни кадәр чиркин[27] бер нәрсәләр өчен тәләф итәләр[28]. Шул кадәр гасырлар эчендә бар белгән, бар эшләгән бер нәрсәләре булса – ул да сугыш!..

Әй, кан эчүче мәхлук! Җинаятеңне, залимеңне иң элек хайваннардан башладың: итләрне ашамак, тиреләрне суеб алмак, алар илән файдаланмак өчен ул гөнаһсыз хайваннарны тотыб үтерергә тотындың. Ләкин үз җенесеңдән һәм дә үзең шикелле башка инсанлардан ни өмид итә идең?!. Тугърысы син, үз балаларын үзе үтереб ашый торган ерткыч хайваннар кебек вәхши бер мәхлуксең!

Кан!.. Кан!.. Менә синең бөтен тәрҗемәи хәлең!.. Яратылышыңдан ике йөз гасыр кичдеке хәлдә һаман шул чиркин хәлеңдән кортыла алмыйсың. Һаман кан эчәсең!..

Мәдәният!.. Тәрәккый!.. Болар сине яратылышыңдагы вәхшилекдән асла кортара алмадылар. Бәлки, билгакес[29], вәхшилек вә җинаятьләреңне йиңеллек илән мәйданга китерергә көчле бер сәбәб кенә улдылар... Син, табигатнең хәзинәләренә нихәдле төшенсәң, ул кадәр дә коралга әһәмият бирдең. Бар фикереңне, бар һәвәсеңне шуңа сарыф итдең. Иң әүвәл корал ясадың. Тимер кәшеф итеб чыгардың, аны да кан түгү өчен истигъмаль итдең[30]. Хәтта ошбу көндә вәхшилекең аның илән генә дә канәгать итмәде, утлар пошкыра башлады!.. [...] Мылтыклар иҗад ителде. Туплар ясалды. Хәлбуки боларның өлгесе бер минутда йөзләрчә инсаннарны тәләф иткәне кебек, икенчесе дә күз ачыб йомганчы белмим нихәдле адәмләрнең башына йитә. Үтереб, сибереб йир астына тутыра!.. Шушы киң мәйданлыкда дүрт-биш сәгать кенә ул меңләрчә адәмләр тезелешеб, һич сәбәбе булынмаган бер нәрсәне (сугышны!) көтеб торалар иде. Бераз соңра шул нәрсә мәйданга килде, бичара меңләрчә инсаннарның башына йитде...

[20] Истәгәненчә – теләгәненчә.

[21] Нәбатларга – үсемлекләргә.

[22] Зәррәләргә – кисәкләргә.

[23] Фәгалиять – эшчәнлек.

[24] Мөтәфәккир – уйчан.

[25] Зәкявәт – зирәклек.

[26] Ишгаль итә алмаган – били алмаган.

[27] Чиркин – шыксыз.

[28] Тәләф итәләр – әрәм итәләр.

[29] Билгакес – киресенчә.

[30] Истигъмаль итдең – кулландың.

Менә бу хатын ибдәшләре арасында иң бәхетле бер хатын иде. Әмма хозур да исә, зәваллы, углыннан аерылыб, аның өчен йөрәге яныб, еглаб, көеб-көеб утыра. Чөнки ялгыз калган, карар кешесе юк...

Әнә шул тау башындагы яшь кыз да, күрешеб калмак өчен, сөйгәнене көтеб тора. Чөнки сөйгәне иртәгә, өстенә кораллар тагыб, сугышка китәчәк. Ничөн? Кан!.. Чөнки болар инсан, боларга кан лязем!..

Аллаһ Тәгалә инсанларны йир йөзенә сөрдекдән соңра, шул зәгыйфь мәхлук, үзене издермәү өчен бөтен табигатькә каршы торырга башлады. Табигатьне йиңмәк өчен һәртөрле чараларга тукынды. Хаҗәтләрне үтәтмәк, йомышларны күрмәк, авыр-авыр эшләрне эшләтдермәк өчен бөтен хайванларны, хәтта бөтен йир йөзене үзенә әсир итмәк улды. Тау-ташларны актарды. Йир астына төшде, бутанды, чукынды, актарынды да, ниһаять, андан да бер чук нәрсә табыб чыгарыб, алар илән үзенә корал хәзерләде, көчене арттырды!

Дөрест! Яратылышдагы канунга ияреб һәм мәгънә, һәм дә матдә һаман бер ноктага тугры тәрәккый итеб утырасың. Һәрбер дөрдә башка бер тәрәккый, башка бер халәт күрсәтәсең. Ләкин һәйһат! Нихәтле тәрәккый итсәң дә, нихәдле юкарыга үрмәләб утырсаң да, фазыйләт[31] вә кәмаләтдән[32] шул кадәр ераксың... Яратылуыңа екерме мең кадәр бер заман кичдеке хәлдә, бармак араларыңдан әле кан түгеләә!.. Сәфаләт! Җинаять!

Менә, инсанларны даимән зәһәрләб торган шул ике куркыныч авырудан һич бер кортыла алмадың. Боларга бер дару табыб да, шул инсанларны куркыныч фәлякәтдән[33] хәляс итүн[34] белмәдең. Әлхасыйль, гакыл вә фикереӊ никадәр тәрәккый итсә дә, вә ни хәдле юкарыга чыгарга тырышса да, һаман бик сәфил[35], бик явыз, бик чиркин бер хәлдәсең! Күз алдында шундый куркыныч рәсемләр, ләүхәләр[36] (ятимләргә, мәгъсумләргә[37], фәкыйрьләргә золым итү, фәхеш вә сәфаһә[38] уенлары уйнау!..) тора ки, болар шулай инсанларның хәят сәхифәләрендән һичбер вакытда да чыгарылмаячакмы? Җәмгыяте бәшәрия мәңге шулай чиркинлек, пычраклык эчендәме калачак?!. [...]

***

Әнә шунда бер иске череб, йимерелеб беткән кучүк кенә бер өй бар. Эчендә бер гаилә көн кичерә. Гаилә башлыгы да көнлекләб эшләүче бер эшче. Гаиләсене маңлай тирләре илән туйдыра... Гаиләсе авыру бер хатын илән сикез яшендә бер баладан гыйбарәт. Менә шул эшче бераз көн әүвәл эш эзләб чыгыб киткән иде. Ләкин, бичара, эшләргә эш табалмыйча мәхрүм булыб, кабат кайтды. Һәм дә ачыгыб, арыб кайткан. Ач!.. Гаиләсе белән кучүк кенә бер ашъяулык җәеб ашарга утырганлар. Ашарларына да бер генә кисәк икмәкләре бар. Зәваллы ата, нишләгәнен дә белмичә, ашъяулыкның бер башында күзләрендән яшьләр агызыб, шул бер кисәк икмәкләрне тураклаб, өләшеб маташа. Ашъяулыкның икенче башында да хатыны көчкә генә стенага сөялеб утырган. Еглаб утыра. Еглый-еглый күзләре шешенеб беткән. Күзләрендән дәрьялар ага!.. Баласы да ашарга сораб еглый. Шуны кызгана. Шул газиз баласы өчен йөрәге өзелә. Ашарга юк!

***

Ятим, мәгъсум, матур бер кыз:

– Әфәндем!

[31] Фазыйләт – яхшы холык.

[32] Кәмаләтдән – камиллектән.

[33] Фәлякәтдән – кайгыдан.

[34] Хәляс итүне – котылуны.

[35] Сәфил – түбән.

[36] Ләүхәләр – картиналар.

[37] Мәгъсумләргә – гөнаһсызларга.

[38] Сәфаһәт – сарыф.

– Ни бар?
– Бераз туктамассызмы?
– Ни кирәк?
–(Моңлы, кайгыви хәзин[39] бер тәбәссем[40])
– Кая, күзләрең бакыйм, матурсыңмы?
– (Күңелсез, хәсрәтле бер караш)

Зәваллы кыз нишләсен, ахырысы шул адәмнең артындан ияреб китә. Башына зур бер фәлякәт ала (гыйффәтендән, кыйммәтендән, гыйзззәтендән аерыла...) Чөнки ашарга юк, икмәк кирәк... Юкса, ачка үләчәк! [...]

Менә, ошбу рәвешдә җәмгыяте бәшәриянең һәр әгъзасында бер яра: һәр җөзьәсендә бер авыру, бер җәрәхәт бар. Мәдәният боларны тәдави итәргә[41] тиеш түгелме иде?! Хәлбуки мәдәният, җинаятьче вә сәфаһәтчеләрнең[42], рәзил[43] вә сәфилләрнең мөбтәля улган[44] шул куркыныч авыруларындан һич берни кортара алмады. Бәгъзе бер лисандан алыб ташлый торган сүзләр бар ки: һич улмазса, мәдәният шуларны да чыгарыб ата алмый! [...]

Мәдәният, инсанларны мәхкәмәләрдән, зинданлардан, гаскәрләрдән, кораллардан, бигрәк дә акча бәласендән кортарырга тиеш түгелме иде? Җәмгыять бәшәриянең зур бер ярасы, зур бер фәлякәте исә – акчадыр. Хәтта бу көндән-көн күченү артдырмакда, көндән-көн хәдсез-хисабсыз инсанларны истибдад (деспотизм) астында измәкдә, иңрәтмәкдәдер! Инсанларның һәммәсе дә ялгыз бер нәрсә өчен генә хәсрәт чикәләр: акча!.. Бөтен фәлякәт, бөтен сәгадәт ялгыз шуның илә генә хасыйль була. Бөтен дөнья ялгыз шуның күчәрендә әйләнә. Бөтен җәмгыять ялгыз шуның өчен яши. Бөтен тереклек фәкать аның белән генә каим[45] ! [...]

Бу галәмдә һәрбер нәрсә алышыну эчендә. Һәрбернәрсә бер инкыйлаб тулкынлары арасында йөзә. Бу өзлексез алышынулар, бу өзлексез үзгәрешләр эчендә ялгыз бер нәрсә бакый. Ялгыз бер шәй генә хакыйкый барлык илән бар ки, җәнабе Тәгалә хәзрәтләредер. Шундый бер шәй ки, бөтен галәмләр ялгыз аның сәясендә һәм дә аның кушуы, аның теләве, аның коты илән генә дәвам итәләр. Һәммә нәрсә дә анчак аның тәкъдире илән генә яратыла. Аның казасы, аның хөкеме, аның әмере белән генә юк ула, бетә, үлә. Ялгыз ул бар. Ялгыз ул бакый! [...]

Фәкать дөньяларның бу хараблыгы, галәмләрнең бу кырылышы җиһанларның бу бетеше эчендә ялгыз бер шәй бөеклегенә, ялгыз бер шәй югары аша. Ялгыз бер шәй генә үзгәрми иде. Бөтен хәят илә мәмат[46], барлык илән юклыкның һич өзексез, бере артындан икенчесе нәүбәтләшеб[47], килеб-китеб торган бер заманда һәм дә мондый дәһшәтле бер инкыйлаб эчендә ялгыз бер Аллаһның барлыгы бар; ялгыз Ул гына алышынмый, ялгыз Ул гына бер барлык илә Бар иде. [...]

Ошбу вакыт миндә курку тәмам киткән иде. Бу куркыныч манзараларны батырчылык илән сәйрәтә идем[48]. Хәтта ошбу вакыт, минемчә, бер кабернең бер бишекдән һичбер фәрекъ[49] калмаган иде. Барлык эчендә юклык, юклык эчендә дә барлык күрә идем. Һәм дә ирекле-ирексездән кычкырыб, үз-үземә: «Хәят илән мәмат, барлык илән юклык – болар һәр икесе дә бердер. Ялгыз бер барлык, бер бәка эчендә фанилекгә мәхкүм улганларның[50] бер алышынуы, бер үзгәреше бар, башка һич!.. дидем.

Текстны басмага ***Алия Мөбарәкшина*** *әзерләде.* ■

[39] Хәзин – кайгылы.

[40] Тәбәссем – елмаю.

[41] Тәдави итәргә – дәваларга.

[42] Сәфаһәтчеләрнең – сарыф итүчеләрнең.

[43] Рәзил – начар.

[44] Сәфилләрнең мөбтәля улган – түбәннәрнең дучар булган.

[45] Каим – бар булып тора.

[46] Мәмат – үлем.

[47] Нәүбәтләшеп – чиратлашып.

[48] Сәйрәтә идем – күзәтә идем.

[49] Фәрекъ – аерма.

[50] Мәхкүм улганларның – хөкем ителгәннәрнең.

ТУКАЙ ФӘНЕ ҮСӘЧӘККӘ ӨМЕТ ЗУР

Рифә Рахман

Апрель аен, шигърият бәйрәмен әллә нинди эчке сөенеч белән каршылыйм, чөнки бу елда мәдәни-фәнни җәмәгатьчелек Тукай алдында зур бурычын үтәде – җиденче гыйнварда Татарстан Фәннәр академиясендә озак көттергән Тукай энциклопедиясен тәкъдим итү кичәсе узды. Әлеге чарада бер төркем галимнәрнең, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институтының дистә елларга сузылган белешмәлек төзү тарихына нокта куелды, әмма ул Тукай фәненең үсешенә яңа этәргеч кенә булды.

Сөенмәслек тә түгел: Бөек Шагыйрьгә мөнәсәбәттә, хезмәттә халкыбызның гасырларга сузылган сәнгать-әдәбият тарихы чагылыш тапты; моннан тыш, ул озак еллар бөртекләп җыелган һәм вакытлы матбугатта, китапларда апробацияләнгән мәгълүмати-фәнни материалны бер бураннага салды; алга таба да яшәргә хокукы расланган академик гыйльмиятне заман карашлары белән кушу һәм тулы бер иҗатка карата куллану шартларын тудырды; әдәби бәйләнешләребезне ныгытты; институтның энциклопедияләр төзү мөмкинлекләрен ачты һәм алга таба анда энциклопедик юнәлеш мөһим юнәлешләрдән була алганны раслады.

Академик басма Тукай тирәлегенә караган шәхесләр хакында да белешмәлекләр төзү эшенә юл ачты. Тукайны алга таба өйрәнү перспективаларын билгеләүгә, Тукай фәнендәге бушлыкларны ачыклауга җай туды. Укытучылар, студентлар, мәктәп балалары персоналийдагы җыйнак чыккан мәкаләләрне мөстәкыйль рәвештә киңәйтә, теге яки бу фәнни эзләнүләренең тема-проблемасы итә алачак. Әйтик, без алга таба Тукай тормышының төрле чорларын тәфсиллерәк яктыртырбыз, бер тупланган мәгълүматка таянып, Тукайга кагылышлы барлык фәнни-әдәби материалны чагылдырган икенче белешмәлек тә төзергә мөмкин.

Энциклопедияне язу киң билгеле хезмәтләрне туплап-җыйнакландырып, алар хакындагы фикерләрне бәяләү, гомумиләштерү кысаларыннан бик нык читкә чыкты, еш кына өр-яңа фәнни эзләнүләр төсмерен дә алды. Кызганыч, шушы эш барышында туплаган, язган мәкаләләребез, күләмгә бәйле рәвештә, тулы чагылыш таба алмады. Шунысы нык сөендерә: хәтта энциклопедия язылып бетеп килгәндә дә, галимнәр Тукай белән бәйләнешләре булган каләм ияләрен ачыклауны, исемнәрен сүзлеккә өстәүне, ә ялгыш килеп кергәннәрне төшереп калдыруны туктатмады. Бик күп язучыларның

әсәрләре Тукай фәнендәге әйләнешкә тәүге тапкыр кертелде, белешмәлектә әле аның исемнәр сүзлеге төзелгәндә бөтенләй билгеле булмаган шәхесләр иҗаты да шактый киң чагылыш тапты. Энциклопедия озак еллар язылу сәбәпле, анда бик күп материалларны яңартырга туры килде, ә бит шушы хезмәт белән генә шөгыльләнүчеләр саны, күләмле академик басмалар төзү белән шөгыльләнүче төрле оешмалар белән чагыштырганда, әйтеп бетергесезлек аз һәм әлеге хезмәткәрләрнең фәнни эзләнүләр алып барган башка өлкәләре дә бар.

Тукай энциклопедиясен язу бүгенге Рәсәй, шул исәптән татар, хәтта дөнья гуманитар фәннәре алдында торган проблемаларны да шәрәләндерде, дип уйлыйм. Кайберләренә генә тукталып узыйм. Шуларның берсе – безнең генә түгел, дөнья әдәбият гыйлеменең дә кадрларга, бигрәк тә тирән белемгә ия, башка өлкәләрдән дә мәгълүматлы һәм каләм шомалыгына да ия галимнәргә мохтаҗлыгыдыр. Моннан тыш, киләчәккә алган зур планнарны – һәр хезмәткәргә төшкән биниһая зур йөкләмәләрне истә тотканда, институтыбызда эшләүчеләрнең саны булган ихтыяҗны канәгатьләндерерлек түгел. Никадәр диссертацияләр яклана да, күпләргә якын кебек Тукай темасын ачканда да, тиз арада моңа кадәр калып килгән мәкаләләрне әзерләрлек компетентлы белгечләрне читтән табу бик кыен. Бүгенге фәндә теге яки бу мәсьәләгә бәйле карашлар төрлелеге, галимнәребезнең аерым бер терминнарны һәм темаларны ачканда уртак фикергә килә алмавы да үз кыенлыкларын китереп чыгара, чөнки энциклопедиядә Тукай иҗатын төрле теоретик яссылыкларда анализлау да алга куелган иде.

Теләсә кайсы белешмәлеккә сүзлек төзегәндә, фән бер баскычта була, ә чыкканда – икенче, кулланучы әлеге аерманы сизәргә тиеш түгел. Авторлар алмашыну шартларында бу өстәмә кыенлыклар тудыра. Энциклопедиянең киң катлау халыкка адресланганын да онытмаска кирәк. Ул мәкаләләрдәге мәгълүматны киңәйтә, анализлый алган, инде үз белгәннәренә таянып, киләчәктә төзәтеп укыячак заманча карашлы, белемле укымышлыларны да, элегрәк чорда белем туплаган, фәнни яктан инерт зыялыларны да, аны кирәк чакта күз төшерергә дип сатып алган гади кешене дә күздә тотып язылган. Алтын урталыкны табу һәм белешмәлек принципларын да саклап язу җиңел эш түгел.

Тукай – күпмилләтле төрки дөнья баласы. Аның хакында материалларның, авторы чынбарлыкны тулы һәм төгәл чагылдырырга омтылса да, милләтара мөнәсәбәтләрнең начарлануына китерергә тиеш түгеллеген беләсең. Шул ук вакытта үз милләтеңнән чыккан күп кенә каләм ияләренең башкаларныкына әверелүенә, кайчак хәтта тугандаш халыклар фәнендә генә түгел, алар тырышлыгы белән, дөнья историографиясендә дә татарныкы булып кермәвенә борчыласың һәм берни эшли дә алмыйсың.

XX гасыр башының торган саен бездән ераклашуы, чит халыкларның татар әдәбияты, тарихы белән элекке дәрәҗәдә таныш булмавы яисә инде үз әдәбиятларының хәзерге мөстәкыйльлеге зурлык һәм башка сәбәпләр белән дә аңлатыла торгандыр. Бу уңайдан, алга таба без нишли алабыз, дигән сорау туа. Минемчә, кытайлар кебек, әлегәчә читләргә тапшырылып киленгән аерым проблемаларны үзебез өйрәнеп, әдәбиятыбызны тәрҗемә итеп, әдәбият белемебезне дә, әдәбиятыбызны, шул исәптән каләм ияләребезне дә үзебез пропагандаларга, чит гуманитар фәннәрдәге объективлыкка, тулылыкка да юллар салышырга тиешбез.

Тукай энциклопедиясе татар халкына гына түгел, башка милләтләргә дә Тукай шәхесенең, талантының төрки әдәбиятлар барышына гаять зур тәэсире, милли-иҗтимагый-сәяси хәятыбыздагы әле без бүген дә бәяләп бетерә алмаган йогынтысы турында сөйли. Ул безгә Тукайны өйрәнүне үз тирәлегебез, XX гасыр башы чиге белән генә тарайтмаска кирәклекне, аның бәйләнешләре алдагы гасырларгача сузылачагын аңлатты. Димәк, Тукай фәне бервакытта да үсештән туктамаячак! ■

АТАЧАК ТАҢНАРГА БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

Флера Сәйфуллина,
филология фәннәре докторы, профессор.

Татар әдәбияты тарихында Якуб Зәнкиев заманның хәлиткеч мәсьәләләренә кагылган 400гә якын публицистик мәкалә, дистәдән артык кечкенә хикәяләр, ике роман – «Иртеш таңнары» дилогиясе һәм «Ялкында өтелгән мәхәббәт» авторы буларак билгеле.

Әлегә кадәр себер татарлары дигән халыкның барлыгын да уйлап карамаган, кичә генә вуз бетереп, кайдадыр, югарыда язылган фалга буйсынып, Себер якларына ана телендә белем бирергә чыгып киткән кыз бала өчен ышанычлы, кыен вакытларда терәк булырлык, туган җирдән читтә күңел тулганда сыеныр, шатлыкларны бүлешер, җаныңны, күңел халәтеңне аңларлык кешеләргә мотаҗлык булуы, әлбәттә, гайре табигый хәл түгел. Киң күңелле кешеләре, кырыс табигате белән танылган Себер яклары истәлеге буларак, күңелемдә мәңге онытылмаслык тирән хатирәләр калдырган очрашуларның берсе – бу якларда яши башлаганнан икенче кышымда танышкан Якуб Зәнкиев белән бәйле. Якуб абый һәм аның җәмәгате Рәшидә апаның үзләренә бертөрле, ниндидер сирәк очрый торган зыялы мөнәсәбәтләргә нигезләнгән гаиләсе, күп санлы балалары белән танышу, аралашу гүзәл истәлекләр булып, әлегә кадәр күңел түрендә саклана.

Язучының үзе белән беренче кабат танышу, аралашу яңа гына эшли башлаган Тубыл дәүләт педагогика институтының татар студентлары укый торган икенче катындагы бер аудиториясендә булды.

1990 елның декабрь ае... Дәрес бара торган сыйныфка ишек шакып килеп кергән чандыр гәүдәле, өлкән яшьтәге ир-атны студентларым аягүрә басып, олылап каршылады: аларның күбесе керүчене таный икән... «Мин Якуб Зәнкиев абыегыз булам, бәлки минем «Иртеш таңнары»мны укыгансыздыр», – дип башлады ул сүзен. Институтыбызда татар бүлеге ачылуына бик шат булуын, татар студентлары һәм аларның Казаннан килгән мөгаллимәләре белән танышырга махсус керүен әйткәч, бик якын итеп уку шартлары, дәреслекләр, уку китаплары хакында сораштырды. Әлеге танышудан башланган аралашуыбыз Якуб абыйны үзенең туган авылында соңгы юлга озатуга кадәр дәвам итте...

Себер татарларының горурлыгы булып әверелгән «Иртеш таңнары» романын аеруча бер кызыксыну белән, йотлы-

Я.Зәнкиев җәмәгате Рәшидә апа, пединститут галимнәре һәм студентлар белән. 1993 ел

гып, әлегә үзем өчен бик үк аңлашылып бетмәгән себер халкы, аларның яшәеш рәвеше, көнкүреше хакында җаваплар эзләп укуым хәтеремдә. Тиз арада Төмән өлкәсе татар газетасы «Яңарыш» укучылары белән әсәрдән алган тәэсирләрмне бүлешергә ашыкканмын. Бу хакта Якуб аганың эре хәрефләр белән, үзе кебек ипле-җайлы итеп язылган хаты искә төшерә. Кешене шатландырудан бер эчке ләззәт, ямь таба белүче олы җанлы, киң күңелле шәхес иде ул: әле кичә генә Казанга барып, аспирантурага кереп кайткан, үзеннән 2-3 яшькә генә кечерәк булган студентларын татар әдәбиятының бай вә катлаулы тарихы белән таныштыру кебек олы хезмәткә алынган яшь укытучыны канатландырып, өметләндереп хат язган: *«Яңарыш»тагы «Иртеш таңнары турында» дигән рецензияңне зур канәгатьләнү белән укып чыктым. Моңа кадәр шушы роман турында төрле газет-журналларда күп кенә язмалар-рецензияләр булды. Әмма моның кебек җентекләп, әсәрнең эчтәлеген матур итеп ачканнары әле булмаган иде. Сезнең бу рецензиягезне мин бик төпле, объектив һәм иң грамоталы итеп язылганы дип саныйм... Мин сезнең киләчәктә олы галим булуыгызга ихлас күңелдән ышанам... Зур ихтирам белән Якуб Зәнкиев. 17 март, 1994 ел».* «Мәхмүт Хәсәновның «Язгы аҗаган» һәм Якуб Зәнкиевнең «Иртеш таңнары» романнарында себер татарлары чынбарлыгы» дип аталган язма да (аспирантурага керү өчен язылган иде) шул тәэсирдә туган беренче фәнни хезмәтем булды.

Әкренләп әлеге шәхес хакында мәгълуматларым шактый киңәйде.

Якуб Камали улы Зәнкиев 1917 елның 6 апрелендә Өркет (Иркутск) каласында туа. Аның бабасы Зәнки – җирсез сарт (Бохара якларыннан Себергә килгән төрки кавем), фәкыйрьлектән интегеп, туган авылын – хәзерге Төмән өлкәсе Тубыл районы Хуҗайлан авылын ташлап, читкә эш эзләп китә. Егерме биш ел байларда ямщик булып Тубыл, Ом, Өркет калалары арасында йөк ташый. Олаучылар Тубылдан кыйммәтле тире-пушнина, замш бияләйләр алып китеп, Өркеттән кытай чәе, ефәк, мануфактура төяп кайтканнар. Кайчагында юлга бишәр йөз ат чыгып китә торган булган, сәфәр еллар буе дәвам иткән. Бай-

Камалетдин белән Закирәбану. Өркет шәһәре, 1918 ел

кал (Бай күл) күле тирәсендә тимер юл төзелә башлагач, Зәнки абзый шунда биш ел таш каерган. Улы Камалине дә үз янына алдырган һәм аны камыт тегүче итеп эшкә урнаштырган.

Якубның әнисе Закирәбану – Татарстанның Норлат (хәзерге Яшел Үзән) районы Әрә авылыннан Вәлит мәзин кызы. Алар гаиләсе дә Өркет ягына бәхет эзләп килеп чыккан, шунда Камали белән танышып, гаилә корганнар, тиздән аларның беренче балалары – Якуб дөньяга килгән. Улларына бер яшь тулганда яшь гаилә ата-аналарының туган туфрагына күчеп кайта. Булачак язучының балачагы, яшьлек еллары шунда үтә. Якубка бары 8 яшь, ике сеңелесе – Зәйтүнәгә 5 яшь, Заһидәгә бары сигез генә ай гына булганда әниләре вафат була, сабыйлар бабалары Зәнки һәм абзыйлары Сәләхетдин, аның хатыны Зиннәтбану карамагына калалар.

Я.Зәнкиев әтисе, үги әнисе, бертуган сеңлесе һәм балалары белән

Гасыр башындагы давыллы – даулы елларда дөньяга аваз салган Якубка катлаулы тормыш юлы узарга туры килә. Башлангыч белемне ул үз авылында ала, мәктәптә беренче адымнарыннан ук укуга зур омтылыш, белем алуга хирыслык күрсәтә. Әлеге авыр, катлаулы елларда үзен укыткан кешелекле укытучылары – Мөхәммәтулла Урамаев, Зиннур Бекшенев, Хөсәен Ильясов, Ваһап Әхмәтов абыйларны, Фатыйма апа Галиәкбәрованы Якуб ага олыгайган көнендә дә олы хөрмәт һәм рәхмәт белән искә ала иде. Язучының тормышындагы һәм иҗатындагы идеалы – әхлак ягыннан үтә пакь, үзләрен бөтенләе белән яраткан эшләренә – балалар укыту-тәрбияләүгә, халыкка, җәмгыятькә хезмәт итүгә багышлаган кешеләр булуы әлеге укытучылары тәэсирендә формалаша. Тубыл шәһәрендәге җидееллык татар крестьян яшьләре мәктәбендә белем алу бәхете (йөзеллык тарихы булган, хәзерге тәрбия эше татарча алып барыла торган 15 нче мәктәп) аның киләчәген хәл итә: әлеге мәктәпне тәмамлагач, 17 яшьлек егет туган авылында башлангыч сыйныфлар укытучысы итеп билгеләнә. Соңрак Тубылда педагогия техникумында белем ала, Төмән укытучылар институтының физика-математика факультетын тәмамлый.

Икенче Бөтендөнья сугышы булачак язучы язмышында тирән эз калдыра. Ватан өчен изге көрәшкә күтәрелгән кыю кешеләр арасында мөгаллим Якуб Зәнкиев тә була. Сугыш елларында ул Себер бригадасы составында 5800 чакрым юл үтә: Львов, Дрезден, Праганы алуда, Висла, Одер елгаларын кичеп, Германия, Польша, Чехословакия җирләрендә барган канлы сугышларда катнаша. Бригада җиңүне Чехословакия җирендә Прагадан ерак түгел урнашкан Вельтруси шәһәрендә каршылый. Бу шәһәрнең иске мәктәбе урынына яңа мәктәп төзү өчен сугышчыларның акча җыеп калдырулары, шул акчага төзелгән мәктәпкә «Кызыл Армия» исеме бирелүе хакындаЯкуб ага горурланып искә ала иде. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен ул «Кызыл Йолдыз», 1-2 дәрәҗә «Ватан сугышы» орденнары, күп кенә медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан кайткач, Төмән өлкәсенең Ялутор районы Аслана мәктәбендә укыту эшләре мөдире, директор булып эшли. 1950 елда Асланадан туган ягына – Хуҗайлан мәктәбенә директор булып кайта. Тубыл районы мәгариф бүлеге мөдире булып та эшли. 1975 елгача туган мәктәбен җитәкли.

Тарихта булган үзгәрешләргә, тор-

Укытучылар коллективы, 1950 нче еллар

Хатыны Рәшидә апа һәм Аяз Гыйләҗев белән. 1980 нче еллар

мышта туган төрле катлаулы мәсьәләләргә битараф булмавы аны журналист-язучы эшенә алып килә. Якуб абый – заманының катлаулы мәсьәләләренә кагылган 400гә якын публицистик мәкалә авторы. Әдәби иҗат эшенә ул зур тормыш тәҗрибәсе туплап, журналистлык эше аша килә, әдәбиятыбызның олы хәзинәләрен үзенчәлекле образлар, әлегә кадәр күренмәгән Себер киңлекләре сурәте белән баета.

Я.Зәнкиев татар әдәбиятына чын күңелдән мөкиббән киткән җан иде. Татар җанлы кеше өчен әдәбият элек-электән җәмәгатьчелек мөнбәре булып килгән. Әйтергә кирәк, җәмәгате Рәшидә апа – ана теле һәм әдәбияты укытучысы, Якуб абыйның әдәбиятка тартылуында аның тәэсире дә бәяләп бетергесез, таянычы, фикердәше, әсәрләрен укып, беренче бәяне бирүче дә ул. Әдәбият дигән иксез-чиксез бай хәзинәнең бер кисәген тудыруга үзеннән дә өлеш кертү теләге, үз сүзен әйтергә омтылыш аны язучылык эшенә алып килә. Укытучы булып эшләгән елларында ук күңелендә зур күләмле әдәби әсәр язу теләге белән яши. Зур тырышлык, эзләнүләр нәтиҗәсе булып, 1988 елда «Иртеш таңнары» романы дөнья күрә. Күләмле әсәр язуга керешүен автор үзе болай аңлата: «*...Без яшәгән заманда, без гомер үткәргән җирләрдә укытучының роле ифрат зур иде. Шул үзем күргән-белгәннәр күңелемә тынычлык бирми башлаган чорда безнең төбәккә Казаннан бер төркем язучы килеп төште. Ф.Хөсни, Ш.Галиев, А.Гыйләҗевләр белән аралашу минем тормышымны яңартып, үзгәртеп җибәрде. Укытучыларга багышлап, Себер татарларының тормышын, гореф-гадәтләрен, йолаларын сөйләп бирәсем килде. Әлеге фикер кырык ел буена миңа тынгылык бирмәде һәм нәтиҗәдә шушы әсәр туды...*». Роман «Казан утлары»нда басылып чыккач, Гариф Ахунов болай яза: «*Себер ягыннан «Иртеш таңнары» әсәрен язып җибәргән Якуб Зәнкиев күңелдә өмет уята. Роман моңарчы без күрмәгән Себер ягы кешеләренең кызыклы образларына бай булуы белән түгел, үзенә генә хас, кабатланмас тел үзенчәлекләре, себер чишмәләре төсле яңа агынтысы белән дә игътибарга лаек*». Безнеңчә, әлеге бәя әсәрнең асылын, кыйммәтен ачарга ярдәм итә, аның үзенчәлеген төгәл билгели. Я.Зәнкиевнең бу әсәре XX гасырның беренче яртысында илебез тарихында булган, Тубыл-Иртеш буендагы себер татарлары тормышына кагылышлы вакыйгаларга нигезләнә. Җирле халык башыннан кичкән катлаулы хәлләр әсәр

Якуб абый һәм Рәшидә апа белән очрашуым истәлеге. 1998 ел

тукымасында себер табигате, халкының гореф-гадәтләре, әсәрдә урын алган олы язмышлар, катлаулы мөнәсәбәтләр аша сурәтләнә. Әсәр текстка, сюжет канвасына кертеп җибәрелгән фольклор жанрларының байлыгы белән аерылып тора. Дилогиядәге себер татарлары тарихына мөнәсәбәтле легенда-риваятьләр, көндәлек тормышындагы гореф-гадәтләр, бу як халкының үзенчәлекле көнитеш тәҗрибәсен туплаган мәкаль-әйтемнәр – барысы да дөнья сурәте тудыруга, геройларның холык-фигылен ачуга хезмәт итә. «Иртеш таңнары» романында тарихи шәхесләр һәм вакыйгалар белән бәйле легенда һәм риваятьләр укучыда аеруча зур кызыксыну уята. Язучы әлеге романның дөнья күрүендә Аяз Гыйләҗевнең ярдәме зур булуын һәрдаим әйтә килде, аңа чын күңеленнән рәхмәтле булды. Китап дилогия рәвешендә 1994 елда Казанда яңадан басылып чыга, соңрак рус теленә дә тәрҗемә ителеп, укучыларга тәкъдим ителә...

Якуб абый Тубыл шәһәрендәге педагогика институтында яңа гына оешкан милли бүлекнең хәле белән чын күңелдән һәрдаим кызыксынып яшәде. Еш кына студентлар белән очрашуларга керә, татар яшьләре белән аралашудан аерым бер ләззәт таба иде олы-олпат укытучы. Аның белән бергәләп оештырылган китап укучылар конференцияләре, әдәби кичәләр, спектакльләр кую якты истәлек, булып хәтердә калган. Якуб Зәнкиев олы сабырлык һәм изге теләкләр белән, кандидатлык диссертациямне тәмамлаганымны көтте, эш барышы белән чын күңелдән кызыксынып торды, институтыбыз янында гына урнашкан өйләренә хәл белергә кергән саен, иңнәргә канат куеп чыгара белә иде ул!

1998 елның яз башында, диссертация яклауга ике-өч ай кала ул, өенә чакырып, җайлап кына сүз башлады. Тел төбе тиз аңлашылды, озакка сузмыйча гына Якуб абый сүзнең асылын аңлатты: соңгы берничә елда күләмле яңа әсәр язу нияте белән янып яши икән өлкән язучы, инде романының караламасын язып та куйган икән. Әдәби эштә бернинди тәҗрибәсе дә булмаган, әле яңа «өлгереп кенә килә торган галимәгә» олы ышаныч баглаган, күрәсең, әсәренә әдәби эшкәртүче булып алынуымны теләвен әйтеп, гозерен кире какмавымны үтенде. Әлбәттә, бу тәкъдимнән югалып калсам да, олы кешенең сүзен кире кагарга базмадым, хәлдән килгән кадәр ярдәм итәргә сүз бирдем.

Якуб абый эшне кызу тотты: «Егәр булганда эшләп төгәллисе иде, кызым», – дигән сүзләре җаваплылык хисен арттырган, күрәсең, шунда ук эшкә керештек. Тормыштагы һәрбер вакый-

гага игътибарлы, аларны берәмтекләп көндәлекләренә язып баручы кеше буларак (аның күп санлы «амбар кенәгәләре» кадәр дәфтәрләргә язып барган көндәлекләренең саны дистәдән артык иде...), ул бу эшкә дә бик җаваплы килеп, уртак эшебезгә мөнәсәбәтен, үзенең фикерләрен, теләкләрен хатка язып тапшыра торган иде. Беренче хаты әсәрнең экспозиция һәм төенләнеш өлешен эшкәртеп чыкканнан соң язылган. *«Язмамның эшкәртелгән битләрен (кызыксынып китеп, берничә биттә тупланган фикердән этәрелеп, унҗиде бит текст язганым исемдә) бик зур канәгатьлек белән укып чыктым. Болай булгач, эш чыга икән! Әсәр башы әдәби калыпка кергән, дип уйлыйм. Тормыштагыча матур башланган. Әгәр түземлегең җитеп, бөтен әсәрне шулай энә күзеннән үткәрә алсаң, күзгә күренерлек әйбер булачак бу. Гомумән, ничек кенә булмасын, мин синең белән бергә эшләү идеясен дөрес алга сөргәнмен. Кабатлап әйтәм, Алла боерса, бу язмабыз рәтле китап булып чыгачак икән! Зур өмет уятты. Рәхмәт! Инде иң әүвәле алдыгызга куйган диссертация яклавыгыз уңышлы булып чыгуын телим! Амин!»*. Һәр хатының ахырында Я хәрефе өстенә өчле санын куеп, имзасын салган. «Мин бит алган белемем буенча физика-математика укытучысы, шунлыктан, үз исемемне шулай күз алдына китерәм», – дигәне хәтеремдә. «Ялкында өтелгән мәхәббәт» романын камилләштерү шул рәвешле дәвам итте.

Матур җәй айларын Якуб ага җәмәгате Рәшидә апа белән туган авылы Хуҗайланда үткәрә иде. Әллә никадәр очрашып, Иртеш буйлары, Кызлар убысында (Хуҗайлан авылы янындагы калкулык исеме) йөреп, әсәренең вакыйгаларын шул җирләр белән бәйләп сөйләве туачак әсәрнең җирлеген, геройларын күз алдына китеререгә ярдәм итте дип беләм – әсәрне әдәби эшкәртү барышында вакыйгалар һәм геройлар күңелемдә үзенә бер якын чынбарлык булып урын алдылар.

Уртак эшебез 1998 елның соңгы аена


Хөрмәтле Флера!
Шушы китапны – уртак хезмәтебезнең җимешен, кадерләп, мәңгелек истәлек итеп саклассың дигән өметтә калам. Ул, бәлки, синең гыйлем варисым итәргә, эстафетаны сиңа тапшырырга юл ачкандыр. Син талантлы әдәбият белгече, теоретик белемең җитәрлек. Соңлаганчы, әдәби иҗат җиңенә адымнар ясарсың. Мине булышканың өчен зур рәхмәт. Бу китап безнең йортка бәхет, шатлыклар алып керсен. Сәламәт булыгыз.
Изге теләкләр белән
6/XI-99 ел. Якуб Зәкиев

кадәр дәвам итте. Шул вакыт эчендә Якуб агадан дистәләрчә хат килгән. Арада балаларча канатланып, шатланып язганнары да, олыларча киңәш биргәннәре дә бар, китапның укучыны кызыксындырырлык булып чыгуына ышаныч белдереп, бу эштә минем дә өлешем булуына кат-кат басым ясаган. «Беренче фикер алышуыбыз үткәч, гадилек һәм үз кешеләр булып сөйләшер өчен, гади генә «Флера» дип дәшсәм дә, бәлки үпкәләмәссең, дип уйлыйм. Син бит минем җиденче балам Әлфиямнән дә яшьрәксең, – дип дәвам итә хатларның берсе. – Татарстанда талантлы язучылар күп. Безнең отышлы ягыбыз – материалның себер татарлары тормышыннан, бу яклардан булуы белән өстенлек алачакбыз». Өч-дүрт, кайбер очракта биш-алты биттән торган хатларда Якуб ага миңа бик үк таныш булмаган, себер татарларына хас йолабәйрәмнәргә, аерым сүз, гыйбарәләргә тәфсилләп аңлатмалар биргән, үзе әһәмиятле дип уйлаган фикерләрне кызыл кара белән сызып куйган.

Язучының төп максаты – үз халкының табигатькә якын тормыш итү-

Иртеш буе

яшәү рәвешен, башка халыкларга хас булмаган гореф-гадәтләрен, аерым үзенчәлекләрен ил тарихы белән бәйләп, укучыга җиткерү, киләчәк буыннарга тапшыру иде. Шунысы куанычлы: максатына ирешүне үзенең изге бурычы итеп таныган, гомумән һәм эшкә бик җаваплы караган, башлаган эшен ахырына җиткерергә өйрәнгән Якуб абый үзе исән чагында ук бу теләкләренә иреште, эшенең нәтиҗәсен күрә алды.

Роман «Казан утлары» журналында һәм Төмән өлкәсе нәшриятында да басылып, үз укучыларына тагын бер тапкыр гыйбрәтле китап уку ләззәтен тоярга мөмкинлек бирде. Яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләрне чагылдыруны сюжет үзәгенә куйган әлеге роман аерым геройларының гыйбрәтле язмышын илебез тарихындагы зур вакыйгаларга оста итеп бәйләүгә ирешкән. Язучы мәхәббәткә, туган илгә тугрылык дигән олы төшенчәләрне искә төшерә яхшылык һәм явызлык көрәше, мәхәббәт һәм нәфрәт, мәрхәмәтлелек, кешелеклелек кебек мәңгелек темаларны үзенчә яңарта. Әсәр себер татарлары тарихыннан да шактый кызыклы мәгълүмат бирә.

Һәркемнең тормышында, язмышында аерым бер урын тоткан вакыйгалар, шәхесләр була. Гомеремнең Себер


Сәламәт, бәхетле булыгыз! Изге теләкләрегезгә Аллам Сезне ирештерсен.
Хәерле юл, укучылар телә(ге)м Якуб абый Зәнкиев.
9/VI-98 ел.

яклары белән бәйләнгән егерме елында очраган шушы олы җанлы, эчкерсез, кайбер очракларда балаларча самими, беркатлы булган, киң күңелле кеше – Якуб Зәнкиев хакында күңелемдә әнә шундый онтылмаслык хатирәләр, якты истәлекләр саклана. Әдәбиятыбыз тарихында проза һәм публицистика өлкәсендә шактый үзенчәлекле әсәрләр калдырган язучының якты истәлеге алдында баш иеп, исеме милләтебез күңелендә сакланыр, дигән өметтә калам. ■

Безнең мирас №4 апрель 2017

Ачы алма суты – ирендә...

Миләүшә Талипова

Замандашлары аны һәрвакыт елмаеп-балкып торган, җор телле, ачык күңелле кеше иде, дип сурәтли – юктан да кызык таба белгән, юкка да куанган. Куанырлык кызыклар булмаганда үзе уйлап чыгарган...

Әйе, бер карасаң, шаккатырлык ни бар соң? Язмабызның каһарманы Габделхәй Хафиз улы Мөхәммәтшин (сәхнә һәм тарих аны Хәй Мушинский буларак яхшырак хәтерли) – иллюзия остасы, татарлар арасында бу жанрга нигез салучы, беренче татар фокусчысы лабаса, ул шундый, бая сурәтләнгәнчә булырга тиеш тә кебек.

Әлбәттә, әлбәттә...

Хәй – Казан театр техникумы студенты. 1938 ел

Техникумны тәмамлагач. 1939 ел

ЮЛ БАШЫ

Нинди генә сынауларга тарып, утсуларны кичеп тә кече күңелле булып кала белгәннәргә ничек сокланмыйсың? Каян көч алган икән алар? Ничек сынмаганнар, сыгылмаганнар да ничек дөньясына-каһәренә төкереп йә элмәккә (бүген гаять популяр юл), йә җинаятьчелек юлына баш тыкмаганнар?

Бу җәһәттән Хәй Мушинскийның язмышы аерата гыйбрәтле.

1908 елның 27 июнендә хәзерге Башкортстан Республикасы Эстәрлебаш районы Тәтер-Арыслан авылында дөньяга килгән сабый, әти-әнисен таный башлауга ук, тормыш дип аталган алманың ачы тәмен татый башлый. Иң элек зәмһәрир кыш уртасында, авылда янгын чыгып, туган йортлары көл була. Шунда Нәфига апа өч баласын һәм аяксыз килеш урын өстенә калган хәләл җефетен коткара. Авыру ирен район хастаханәсенә илтер өчен мескен хатын бай күршесеннән ат сорый, дилбегәне унбер яшьлек Габделхәйгә тоттырып, икесен ерак юлга озата. Ләкин ачлыктан арыкланган ат район үзәгенә барып җитә алмый, юлда егылып үлә. Бу хәлне белеп алган ат хуҗасы күзе тонган килеш болар янына килеп, авыру карт белән ярымшәрә баланы урман эчендәге карга ташлап калдыра. Хафиз абыйның гозере буенча җәяү ярдәм эзләп киткән малай икенче көнне буш кул белән (ни хикмәт – ярдәм табылмый!) әйләнеп кайтуга әтисенең өшүдән җан биргән гәүдәсен генә таба...

Габделхәй авыл мәктәбен яхшы билгеләргә тәмамлый, Оренбург педагогика институтының физика-математика факультетына укырга керә. Урал тавы итәгендә урнашкан әлеге гүзәл татар каласында үсмер егеткә чын-чынлап театр җене кагыла: ул шәһәрдә күрсәтелгән һәр спектакльгә йөри, үзешчәннәр куйган тамашаларда катнаша. Күңелен ялмаган сәнгатькә тартылу хисен баса алмыйча, 1936 елда Казанга күченеп, биредәге татар театр техникумына укырга керә. Уку йортын тәмамлауга, аны Татар

Х.Мушинский – Камал театры артисты. 1946 ел

дәүләт академия театрына драма артисты сыйфатында эшкә алалар. Габделхәй Мөхәммәтшинның «аурупалаштырылган» Хәй Мушинскийга әвереләүе (Ашказарский, Ильская, Камский, Болгарская һ.б. үрнәгендә) дә шушы чорга карый.

1939 елда Кызыл Армия сафларына чакырылып, аннан... контузия һәм икенче группа инвалидлык алып кайта. Яңадан театрда эшли башлый.

Суфия Ягушевага өйләнеп, Фуат исемле балалары тугач, яшь эти һәм гаилә башлыгы, ниһаять, бәхеткә тиендем, дип тә уйлагандыр әле, бәлки. Әмма тәкъдиренә язылган Кайгы-Хәсрәт җәнапларының бу хакта, ни аяныч, фикере үзгә була шул: озакламый артист сөекле хатынын җир куенына тапшыра. Язмыш һаман Хәйнең ныклыгын сыный. Сыный, әмма сындыра алмый...

ТЫЛСЫМЧЫ

Театрда эшләгән елларында ук Хәй Мушинский иллюзия һәм фокуслар күрсәтү белән мавыга башлый. Бу эштә, могҗиза кылу ук булмаса да, кешенең күңеленә могҗизага (димәк, яхшыга, яктылыкка) ышану салу күрә ул, өлкән яшьтәге тамашачыларның шаккатып тел шартлатуыннан, сабый балаларның ихлас куануыннан искитмәле ләззәт һәм җылылык ала.

Озакламый яңадан гаилә кора. Бу юлы аның күңеле Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры артисткасы Рәбига Исхаковага ята, яшь җырчы кечкенә Фуатка ягымлы әни, Габделхәйнең үзенә сөекле хатын була.

Иллюзионистның «эш кораллары»

Яңа гаиләдә 1951 елда Әхәт (булачак язучы Әхәт Мушинский[1]) дөньяга килә.

Хәй Мушинский 1946 елда Татар дәүләт филармониясенә күчеп, бөтен гомерен, тырышлыгын, сәләтен шушы оешмага һәм анда оригиналь жанрны үстерү хезмәтенә багышлый.

Иллюзияче эше зиһен үткенлеге, математик төгәллек һәм гаҗәеп артистизм сорый: куллар җәт-җәт хәрәкәтләнергә, әсбаплар дөрес урнашырга, нәтиҗәдә, тамашачы «хәйлә»не сизмичә, сәхнәдә күрсәтелгән хәлгә ышанып калырга тиеш. Моның өчен Илаһ Тәгаләдән иңгән сәләт кирәк, билгеле. Өстәвенә, Габделхәй һаман яңалыкка омтыла, өйрәнгәнен шомарта, яхшырта, бертуктаусыз эзләнә, таба, тапканын тормышка ашыра бара. Һәр номерын үзе уйлап чыгара ул. Репетициядән туктамый. Эшчәнлегенең төп кагыйдәләренә гомере буе тугрылык саклый: бер үк номерны бер үк тамашачыга ике тапкыр кабатлап күрсәтмәскә, артык озакка сузмаска һәм, әлбәттә, чыгышны мөмкин кадәр кызыклы, күңелле итеп әзерләргә! Тамашачы өчен син, ни дисәң дә, әкият китабыннан чыккан «тылсымчы» бит, әйдә, асылыңа хыянәт итмә, кешенең өметен өзмә, тылсымыңны тарат!

Кичәге көн белән бүгенгене чагыштыру төптән дөрес түгелдер, мөгаен. Шулай да, артистлар тормышындагы бер күренешкә игътибар итәсе килә: теге чорларда сәхнә халкы Казанда җылынып кына утырмаган: ишеп кар яуса да, чиләкләп яңгыр койса да, чанага яисә тарантаска утырып илкүләм сибелгән халыкка мәдәният илтергә ашыккан алар; хәтта «дөнья читендәге» иң караңгы авылга да сәнгать нуры таратуны үзләренең төп бурычы, миссиясе итеп санаган. Хәй Мушинский да шул рәвешле, Рәшит Ваһапов, Усман Әлмиев, Җәваһирә Сәлахова, Әлфия Авзалова, Флера Сөләйманова кебек сәхнә осталары белән иңгә-иң, татар җиһанын ничәмә-ничә кат айкап чыга.

Татарстанның халык язучысы, җөмһүриятебезнең Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Рабит Батулла Хәй Мушинскийга багышлаган һәм, аз да түгел, күп тә түгел – «Остаз» дип атаган яз-

[1] Аның әтисе турында язылган романы «Һаваларда – ак күгәрчен» дип атала.

Артистлар гастрольгә кузгала. 1950 нче еллар

Сәхнәдә – татарның беренче фокусчысы! 1962 ел

масында, күренекле иллюзия остасының бихисап игелекле сыйфатларын искәртеп, бер уңайдан кызыклы-гыйбрәтле вакыйганы да искә төшереп уза.

Толыпларын, шәлләрен, киез итекләрен әзерләп юлга чыккан могтәбәр артистлардан аермалы буларак, тәҗрибәсез Роберт Батуллин (ул чакта исеме шулай әле) тәүге гастроленә өстенә демисезон пәлтә, аягына ботинка киеп кузгала. Йөри торгач, табигый, кышкы суык җелегенә үтә моның. Хәер, сүзне үзенә тапшырыйк: *«Өч чанада бардык. Артистларга кыш әллә бар, әллә юк – туннарына-шәлләренә төренгәннәр дә, авыз эченнән яраткан җырларын көйләп бара бирәләр. Шулвакыт Хәй абый мине чанадан төртеп төшерде. Аякка басуга, артларыннан чаптым, билгеле. Әмма ни галәмәт: куып кына җитәм – атлар кызулана төшә, яңадан куам – тагын шул ук хәл. Куәтем төкәнеп, аяктан язам дигәндә генә мине, ниһаять, чанага тартып алдылар.*

– Кызумы? – дип кызыксынды Хәй абый.

Миңа бик кызу иде.

– Юкса, чанада утырып, бозланып катар идең, – диде ул, толыбының бер өлешен өстемә ябып».

Икенче көнне Хәй Мушинский төн кунган йорт хуҗасыннан толып белән киез итек сорап ала:

– Энекәш салкын тидермәсен иде, дим. Казанга кайткач, кием-салымыңны кире җибәрербез.

Хуҗа берсүзсез ризалаша.

Бу урында, ихтимал, Хәй абыйның тагын бер күркәм сыйфатын ачып салырга кирәктер: һәр кунган йортта эскәтер астына ул, хуҗалар күрмәгәндә, бер сум акча (филармониянең «суточный» бәясе) яшереп китә торган булган: *«Кузгалгач та Хәй абый аңлатты:*

Рәбига һәм Хәй Мушинскийлар. 1974 ел

– Барыбер филармония акчасы бит ул. Күз алдында бирсәң, хуҗалар бу тәңкәне алмаячак, кыстый башласаң, үпкәләп тә куячак әле. Ә болай – күңелең дә тыныч, хуҗалар да разый кала».

Хәй Мушинский кунган йортта шаяртырга да яраткан. Берсендә ул, мәсәлән, хуҗабикәгә: «Бу – картыңнан калган ядкярдер инде?» – дип, чынаяк сорап ала, шуңа бүрек каплап, өстенә табуретка белән китереп суга. Хатын: «И Ходаем, кеше чынаягы иде», – дип, нишләргә белми ары-бире йөрергә тотынгач кына, «тылсымчы» теге чынаякны «терелтә»: «Алай булгач, менә, кире кайтарам».

СОҢГЫ СҮЗ

Тыштан шулай балкып-көлеп торган кешенең эчендә нинди утлар янгандыр? Балачак һәм үсмерчак хәсрәтләреннән арынгач та шактый кыен ашарга туры килә әле аңа: эш бирмиләр, вакыт-вакыт сәхнәгә якын китермиләр. «Җитди жанр» вәкиле булмагач, билгеле, Хәй аганы барлык премияләр, исем-атамалар да читләп уза. Боларны сөйләп кемне дә булса шаккаттыру мөмкинме икән? Гадәтилек ләбаса. Нәкъ бөек шагыйрьдәгечә: *«Бармыни бездә, гомумән, чын кеше кадрен белү?! Без аны кайдан белик, мискин үлеп аңлатмагач?!»*

«Әти 86 яшькә хәтле яшәде. Ул олыгайгач та кул кушырып утырмады, – дип искә ала артистның улы, язучы Әхәт Мушинский. – Сынлы сәнгать, рәсем ясау, дизайн белән шөгыльләнде. Фатирыбызның диварын да бизәп бетерә иде...»

Хәй Мушинский 1994 елның 15 декабрендә – яңа бәхетләре, яңа өметләре, аклыгы, тылсымы, могҗизасы белән ымсындырып торган Яңа елга кергәндә – бакыйлыкка күчә. Ул чорның ил тарихында нинди вакыт булуын һәммәбез дә яхшы хәтерли: җимереклек, башбаштаклык, имансызлык, акчасызлык, өметсезлек...

Мәкаләнең нокта куяр урынына җиткәч кенә бер моңсу мәзәк хәтергә килде әле.

Хәер, мәзәк, дип...

Нишләп кенә хәтергә килде икән?

Тәмам төшенкелеккә бирелеп, һәрнәрсәдән күңеле кайткан бер кеше табиб янына килә. «Тормыш аяусыз һәм гаделсез. Бу коточкыч караңгы, ямьсез дөньяда мин япа-ялгызым, киләчәктә дә уңай үзгәреш буласына, тормышым яктырасына ышанмыйм», – дип, зарын түгә ул. Табиб мыек астыннан елмая: «Мин сезгә искитмәле дару тәкъдим итәм. Бүген бөек клоун Пальяччи чыгыш ясаячак. Сез циркка барып, аны карап кайтыгыз. Һичшиксез, ярдәме тияр». Шулвакыт багы кешенең күзеннән яше чәчри: «Доктор, – ди ул, – Пальяччи... мин үзем бит инде». ■

Безнең мирас №4 апрель 2017

УТЛЫ КИСӘҮ

Лерон Гыйльфанов

(Истәлекләр, уйланулар)

КҮРӘСЕЛӘР АЛДА ИДЕ ӘЛЕ

Әни янына кайтып күп торылмады. Чиләбе өлкәсендәге Бреды районында әнинең бертуган апасы яши иде. Әни шуның белән сөйләшкәч, берүзем Бредыга киттем. Килүгә, МТСка бардым. Аның директоры Чиләбедән бик ерак түгел урнашкан киң профильле механизаторлар әзерли торган уку йорты адресын бирде. Ул уку йорты Пласт шәһәрендә иде. Кире Чиләбегә таба кайтып, бер тимер юл станциясендә төшеп, автобус белән 40 километр эчкә кереп, әйтелгән мәктәпне таптым. Бу мәктәп миңа ошады. Укулар башланган иде, монда 700 кеше белем ала, диделәр. Бару белән Вагин фамилияле, таза гына гәүдәле, уртачарак буйлы директор янына кердем. Казан ягыннан килүемне, армиядә булуымны, укырга теләвемне аңлаттым. Вагин абый мине укырга алды. Ә бит минем үзем белән бер хәрби билет кына бар, ул да Мөслимнән учёттан төшерелмәгән иде. Мөслимнән, хәрби учёттан төшерттереп, документ сорап алдылар. Шуннан җиң сызганып укый башладым.

Безнең төркемдә 32 укучы бар иде. Шулар арасында яңа гына армиядән кайткан солдат-матрос та. Дәресләр рус телендә барды. Без төркемдә 4-5 кенә татар идек, миннән кала, барысы да Чиләбе өлкәсеннән. Барлыгы 13 фән укыттылар. Укыту: трактор, комбайн, агрономия, слесарь эше һ.б. Мин дүрт кешелек бүлмәдә тордым. Бүлмәдәшләремнең берсе – 1938 елгы рус егете – Лаврухин фамилияле иде. Уку беткәндә, шул егет белән бар фәннәрне дә «5»легә биреп, Мактау кәгазенә лаек булдык. Икенче бүлмәдәшем моряк иде, безнең төркем старостасы. Өченчесе – армиядә булган рус егете Кудрявцев. Караваты ишек кырында. Дәрестән кайтуга, букчасын караваты астына атып бәрә иде. Дәресен юньләп карамады. Шуңа да уку беткәндә имтиханын көчкә «3»легә тапшырып чыкты.

Әйтергә кирәк, укытучылар белемле иде. Уку җиңел булмады. Безнең кебек авыл малаена – аеруча авыр. Аңласаң да, русча әйтү бик кыен. Шуңа да тырышырга кирәк булды. Мин үзем теләсә кая чыгып йөрмәдем. Кич белән сәгать 10-11 ләргә хәтле дәрес карадым. Тырышсаң, барысына да ирешеп була.

Укып бетергәч, кая барырга, дигән сорау туды.

1954 елда чирәм җирләрне күтәрергә дигән илкүләм эш башланды. Мондый эшләр Чиләбе ягында да киң колач алды. Уку чорында безнең төркем Варна районының М.Горький исемендәге совхозында (25 гектар җир) эшләде. Ул елны анда иген нык уңды, кызгылт сортлы бодай 30-35 центнер чыкты. Икмәкне хөкүмәткә тапшырып бетерә алмадылар, чөнки тарту көче аз. Җыелган икмәкнең иге-чиге юк: ачык һавада 50шәр метр озынлыкта, кеше биеклеге иде. Кырыйлары һәм асты шыта, чөнки 1956 ел анда нык явымлы булды. Без шунда эшләгән комбайнчылар белән палаткаларда тордык. Совхоз җитәкчелеге безнең төркем эшеннән канәгать калды. Тәртипсезлекләр булмады. Анда ай ярым булдык. Мин үзем, уку беткәч, Чиләбе өлкәсенең Троицк шәһәренә механиклар әзерли торган мәктәпкә дә керә ала идем. Совхозга эшкә җибәрәселәр иде. Үземнең авылга, әни янына кайтасым килде. Уку

Башы журналның быелгы 2 нче санында.

Лерон әнисе Хәмдия һәм әтисе Хөҗҗәт белән. 1935 ел

беткәндә, Мөслимдәге «Алга» МТСына хәбәр салдым, анда Күбәктән Сәйдел абый Вәлиев (узган гасырның 90 нчы елларында Казан шәһәре хакимиятендә җаваплы урыннарда эшләгән Ленар Вәлиевнең әтисе) МТСта парторг вазифасын башкара иде. Ул, мәктәпкә хат язып, мине Мөслимгә кайтаруны сорады.

Укуны яхшы гына тәмамлап, 1957 елның 10 февралендә әни янына кайттым. Мин кайтканда, әнинең эшләп алган бер пот икмәге бар иде.

Шулай итеп, туган якларда кабат «утлы, давыллы» көннәр башланды. Кайту белән МТСка эшкә килдем. Мине Иске Карамалыдагы трактор бригадасына, шул авыл кешесе булган Хәмдегали абыйга беркеттеләр. Ул 1929 елгы иде, өйләре – ферма урамында. Хәмдегали абый мине үз итте, какмады. Безнең эшләү урыны: Карамалы, Күбәк, Түреш авыллары. Трактор бригадиры – Иске Карамалыдан Газиз Абулов (Әбелов) иде. Берчакта да безне каты итеп сүкмәде, белмәгәнне тыныч кына өйрәтте. Мин үзем аннан бик күп нәрсәгә өйрәндем. Рухы тыныч булсын!

Ул чорда авылдашым Фазаел агай Усы янындагы «Үрнәк» колхозында «Нати-СТЗ» тракторында эшли иде. Шул тракторда Хәмдегали абый белән ел ярым эшләдем. Исеме генә трактор: кабинаның түбәсе бар, тәрәзәләре юк. Аннан соң Фазаел абый авылга кайтты. Һәм безне иске «Нати» тракторына эшкә куйдылар. Ул чакта Карамалы колхозы «Алга» исемендә иде. Хәмдегали абый белән эшләгәндә, иртән сәгать 4тә торып, көн дә җәяү бара һәм кайта идем. Күпме аралар узарга туры килде...

Шулай итеп, Фазаел абый белән үзебезнең авылда эшли башладык. Трактор төзек булса, эшсез торылмады. «Лотый» кордонынннан тиресне (кешеләр көрәк-сәнәк белән төйи иде) басуга чыгардык. Хәйбулла абыйлар янындагы чокырдан төяделәр. Шул иске трактор белән Күбәк-Карамалыда да тирес ташыдык. Чаллы янындагы Кызыл тау дигән җиргә барып, нарат агачы алып кайттык. Авылдаш Назиф, Салихҗан агайлар (инде мәрхүмнәр) грузчик иде. Бер барганда (февраль һәм март айлары бу) су радиаторын өч тапкыр сүтеп җыйдык. «Алга» колхозында председатель булып Ихсанов дигән 25 меңче эшләде ул чорда.

Менә дөнья үз мәшәкатьләре белән алга атлый. 1958 ел – яңалык елы иде. Бу елны МТС оешмалары бетерелеп, техникаларны колхозларга бүлделәр. Ә иң истә калганы – «Алга» колхозына яңа председатель куйдылар. Оештыру җыелышы июль аеның 5ләрендә булды бугай. Мөслимнән кара чырайлы кеше – башкарма комитет

Лерон танк экипажы белән. 1955 ел

рәисе килгән иде. Җыелыш Карамалы башлангыч мәктәбе ишегалдында булды. Хәзер анда почта йорты тора. Ихсанов абыйны эшеннән алып, Дусайда председатель булып эшләүче авылдашыбыз Гаттаров абыйны куйдылар. Аның аягы җиңел булды, ул елны ашлык бик уңды.

Әле шунысы хәтеремдә: безнең колхоз август аенда хөкүмәткә икмәк тапшыру планын үтәп, Күчмә Кызыл байрак алды. Аннан зәп сөрүне сентябрь аенда төгәлләдек. Шул булган барлы-юклы техника белән. Күбәктә бер ДТ-54 тракторы бар иде. Анда Шакир һәм Хәмит агай (Карамалыныкы) эшли. Иске Карамалыда ике трактор иде, Түрештә без Фазаел абый белән икәү. Фазаел абый белән 11 ел эшләдем. Миннән алты яшькә олы булса да, бер дә телгә килмәдек.

1960 елда Түрешкә өр-яңа ДТ-54 тракторы кайтты. Без шушы трактор белән бик күп гектарда басу эше башкардык. Кышын колхоз малларына азык ташу да безнең өстә булды. Юлларда бик күп кунарга туры килде. Трактор чанасына төяп, Бөгелмәгә икмәк ташыдык. Ютазыга ягулыкка бардык, Зәйгә, Бакалы районнарына маллар илтә идек – хөкүмәт планы белән.

Ул чорда да безгә рәтләп кино-концерт карау тәтемәде. Эштән соң тракторны хәзерге мәктәп артындагы котельный янына куябыз. Малларга җылы су белән башак бирәләр иде. Төнгә тракторның суын агызып, иртән парлаудан су ала идек. Шушында 2 кеше смена белән эшләде. Шул «бәндәләр» (исемнәрен әйтмим) тракторга җылы суны ялындырып кына, көч-хәл белән бирә иде. Татар күзен татар чукыр, диләр. Хактыр ул.

Күрәчәкләр алда иде әле.

Мөслим районын Сарманга, аннан Минзәләгә куштылар. Халыктан сорау юк. Маллар китте. Тагын колхозларны эреләндерделәр. Безнең «Алга»ны Баек белән бер колхоз иттеләр. Әле хәзергә председатель Гаттаров абый иде.

Менә шулвакытларда мине Газраил үзе белән алып китәргә чамалап йөри башлады... Ләкин Ходаем, бу кешегә якты дөньядан китәргә иртәрәк, дигәндер.

1961-1962 елның кышында Гаттаров абый Күбәктән Мирзанур, Кәндел һәм тагын берничә кешене Әгерҗе районына агач кисәргә җибәрде. Алар шунда ук кискән агачлардан колхоз кәнсәләре өчен йортлар бурадылар. Алар бурап бетергәч, безне – Күбәктән Шакир һәм Хәмит агайлар, Иске Карамалыдан – Фәхерлегаян абый белән Мирзагаян агай, Түрештән – Фазаел агай белән икәү – чаналы өч «ДТ-54» тракторы белән, Дусайдан – Әхәт агай (трактор белән), Баектан – Газизулла җизни. Бу ике трактор бездән соң килде. Юлда йокы аз эләкте. Сәгать икедә төнлә юлга чыга идек.

Бару юлы болай: Түреш-Симәк-Әтрәкле-Матвеевка-Аю авылы-Минзәлә. Кайтканда Матвеевка тирәсендә кичке сәгать 8ләр була иде.

1962 елның 18 феврале. Матвеевкада куна торган йортыбыз бар. Хуҗалары – татарлар. Ләкин бу кичне, Ык елгасын чыгып, 5 километр киткәч, Иркәнәштә кунарбыз, дип үзара килешкән идек. Ык аркылы салынган агач күпер су киткәндә сүтелә. Мөслимдә дә башта шулай иде. Без кайтуга күпернең бер өлеш такталарын сүткәннәр

Яшьлек дусты Диктат Галиев белән. 1953 ел

иде. Йөкләрне бер трактор белән алып чыкмалы түгел. Иң алдан баручы Шакир агайлар тракторы күпер уртасына кереп туктаган иде. Алга бер трактор чыгарып, Шакир агайларның чанасын 2 трактор белән чыгарырга уйладык. Без Мирзагаян агай белән, Ык елгасын астан боз аркылы җәяү чыгып, тегеләр янына бардык. Шул көнне бер трактор коры килеш чыккан булган, боз алай ватылмаган. Бозга кермәскә дигән билге дә юк, аркылы агач та юк.

Менә шушында мине Газраил саклап торган булган да инде.

Чанага йөк әйбәт төялгән. Чана өстендә – тракторга тагылган беләк юанлыгы тросс. Фазаел абый тегеләр янында иде. Су аркылы чыкканда сул як ишекне яба идем. Ул тиз генә ачылмый. Бу юлы да шулай иде. Мин трактор белән күпернең уң ягыннан чыга башладым һәм, 6-7 метр ара үтүгә, күз алды әллә нишләде: боз ватылып... трактор чана белән су астына китте. Бу хәлне искә төшерсәм, йөрәгем хәзер дә «жу» итеп куя. Ходай саклагандыр инде...

Шул елны Байсар ягыннан барып Чаллыда укыган бер иптәш су төбенә киткән...

Боз трактор кырыннан бер метрлап алдан һәм тирә-яктан ватылган иде. Әйткәнемчә, теге сул як ишек ачык булса, мин, бәлкем, исән калмас идем. Су мине кабинадан этеп чыгарды булса кирәк. Ничек өстәге кием рычагларга эләгеп калмады – хәзергәчә аңламыйм. Кабинадан чыгуга, боз кырыена ябышып кычкырганымны хәтерлим. Иптәшләр мине Матвеевкага элек куна торган татарларга алып керделәр, үзләре дә шунда ял иттеләр. Мине җылы мич башына яткырдылар. Иртән бер «С-100» тракторы яллап, тракторны һәм чананы бозлы судан артка сөйрәп алды. Анда халык күп иде...

Иртән марҗалар, елмаеп: «Здравствуй, тракторист» – диләр.

Трактор артык зыян күрмәгән иде. Су кергән җирләрен агызып, майларын карап, төялгән йөкне шул трактор белән Карамалыга алып кайттык.

Газраил тагын арттан килә...

Монысы болайрак булды. Җир сөргәндә прицеплы сабан иде. Берничә ел шулай сөрдек. Берсендә, җир сөргәндә, сабанда Фәйзыян иде. Завод урманы ягыннан Ка-

Ял итәргә туктаган вакыт. 1975 ел

рамалы юлын аркылы үтеп, Күбәк басуына хәтле буразна яра идек. Ул көнне яңгыр бер явып үткән иде инде. Урман ягыннан чама белән 50-60 адым калдырып, буразна ярып, Түреш-Карамалы юлы аша чыгып узгач, теге якның башы күзгә күренми иде. Менә шунда тракторның ишеген ачып, бер кул белән тракторга тотынып, җирнең башын карыйм, дисәм, аяк таеп китте һәм мин, трактор барган хәлдә, гусеница өстенә егылдым. Ничек кулым, башым, киемем эләкмәгәндер, җиргә әйләнеп төшеп калдым. Фәйзыян сабанда утырган килеш китеп барды. Җирдән торып, йөгереп барып, тракторның артыннан менеп сүндердем. Фәйзыянга, әнигә әйтә күрмә, дип әйттем...

Менә шулай «утлы кисәү» белән бергә һаман алга барабыз.

Менә тагын хәтердә калган бер вакыйга. 1964 елның 5 октябре иде булса кирәк, Карамалыда ремонтта идек. Сәгать 7ләр тирәсе. Диктатның әтисе Гали абый алар яныннан узганда Хрущевның тәхеттән киткәнлеген хәбәр итте (ул аны сөенеп әйттеме икән – белмим).

Власть алышынгач, тагын үзгәрешләр башланды. Бу юлы кабат Мөслим дигән район барлыкка килде. Халык өчен сөенеч иде, әлбәттә. Кабат колхозларны ваклый башладылар. Чират безнең колхозга да җитте. «Алга» икегә бүленде: Карамалы ягына Карамалы үзе, Күбәк, Түреш, Яңа Карамалы, Коммуна, Покровка авыллары керде. Баек, Дусай, Яңа Сәфәр, Горбуновка авыллары «Урал» колхозы булып берләште.

Бүленгән колхозларга яңа хуҗалар кую кирәк иде. Моны район җитәкчесе хәл итә, ә колхозчылар исә өстәгеләр алдында кул күтәреп тавыш бирү өчен генә кирәк. Халыкка файдага әйтсәң, күп вакытта өстәлгә сугып үзләренчә хәл итә иде «вожаклар».

Менә район җитәкчелеге «Алга» колхозына икмәк игүнең ни икәнен белмәгән, ни агроном, ни зоотехник, ни инженер булмаган кешене тәкъдим итте. Без, колларча буйсынып, кул күтәрдек һәм рәисле булдык.

Колхоз малларына ашатырга, асларына салырга салам да җитмәгән дәвер бу. Саламның күп өлеше, өяргә тарттырылып та, өелмичә кар астында череде. Әйтә алмыйм, бу хәл болай күпме баргандыр. Үзебезнең Түреш бригадасында 3 төркем тана бар иде. Шушы маллар аслык саламга нык интекте. Фазаел абый белән «ДТ-54»тә

эшли идек. 1966 ел тирәсе булгандыр. Ничә тапкыр барганыбыз хәтердә калмаган. Трактор чанасын такта белән төреп, Бакалы-Туймазы юлына урнашкан Җияш авылына (Бакалы районына керә) бардык. Анда киндер сугалар, ул чакта алар ягында әле киндер үстерәләр иде. Менә шул киндернең вакланган саламын без маллар астына алып кайта идек. 40-50 чакрым ара бу. Күпме ягулык яна. Колхоздан безне генә йөрттеләр. Ничәнче баруыбыздадыр, баргач, бер кеше минем янга килеп, кәгазьгә кул куярга куша. Мин ни өчен икәнен сорыйм. Ул кеше әйтә: без бу вакланган саламны сатып бирәбез, сезгә счёт җиткерәбез, ди. Хәзер кул куймыйм, хуҗа белән сөйләшкәч куярмын, дидем. Кайткач, хуҗага әйттем. Җияшкә яңадан бармадык. Менә нинди чорлар, кемнәр командалык итә... Авыл хуҗалыгын белмәгән килеш...

Сабирҗан агай учётчик иде. Беркөнне миңа әйтә бу: Күбәк-Карамалы почмагында чәчелгән 80 гектар борчакны бер эздән тырмала, ди. Мин кем кушканын сорыйм. Нәрәттә куштылар, ди. Барасы килми, ләкин нәрәт үтәлергә тиеш. Сугышта да приказны йә үтисең, йә дөнья белән хушлашасың. Менә шулай, борчак басуына теләр-теләмәс кенә барып, тырмаларны көйләдек. Борчак тишелеп чыккан, 3-5 см тирәсе. Басуда Сабирҗан агай белән икәү генә. Борчак басуының бер җиреннән китеп, икенче башыннан әйләнеп килдек. Көн аяз. 20 градус тирәседер. Тырмалаган җир кара балчыкка әйләнә, дияргә була. Борчаклар бик күп йолкынып чыккан. Чәчелгән җирне бик кызгандым. Сабирҗан агайга әйтәм: күрәсеңме, дим, борчак нишләп бетә? Мин болай тырмаламыйм, дидем дә агрегат белән кире авылга кайттым. Мондый хәл башка бригадада да булдымы икән – белмим. Яңадан минем янга агроном да, хуҗа да килмәде. Борчак җирен чәчкәч, бөтенләй тырмаларга ярамый. Менә мамык баш хуҗалар нишләтә. Бу хуҗа шулай да властьта 4 ел утырып, үзенең бу постта булдыра алмаганын аңлап, чирлегә әйләнеп, эш урынын җиңел генә алыштырды. (Андый хәлләр күп җирдә булды.) Аларга барыбер кул-өс пычратмый торган җир кирәк иде. Яңадан мондый эш кушкан кеше булмады.

Әйе, колхозда тагын власть алышынды. Колхоз отчёт-сайлау җыелышында безгә яңа рәис итеп «Карл Маркс» колхозының баш агрономы булып эшләгән Касыймов Наил билгеләнде. Урәзмәттә эшләгәндә «Хезмәт Кызыл Байрагы» ордены белән бүләкләнгән булган, башка орден-медальләре дә бар иде. Колхозда эшләү чорында ике кешенең (берсе – Гаттаров, икенчесе – Касыймов абый) чын җир кешесе булуын күрдем. Алар галстук тагып йөрмәде, гади киемнән булды. Касыймов абый гаиләле кеше иде. Сугышта катнашкан. Хатыны Бүләк авылында балалар укыта иде. Монда күченмәде. Касыйм абый Хәят апаларда яшәде. Мин аның салып йөргәнен хәтерләмим. Эш өченгә бик тә таләпчән иде. Кешеләрнең әйткәненә үпкә тотмады. Мин 10лап рәис белән эшләдем. Бары бер Касыймов абыйны гына булсынга эшләгән җир профессоры, дияр идем. Ул Урәзмәттән үзенең «Иж» мотоциклы белән килеп йөрде. Касыймов абый менә шушы «Иж» белән без тырмалаган, культиләгән җирне иртә-кич аркылыга-буйга әйләнеп чыга иде. Шунда җирнең ничек, ни хәлдә икәнен күреп, безгә тавыш күтәрмичә, башкалар янына китә. Матайда йөргәч, өс киеме тузанлы булыр. Бу кешегә ул заманда Ленин ордены бирерлек иде. Чәчкән чакта күмдерү тирәнлеген үз контролендә тотты. Район җитәкчелеге дә басуларда бик еш була иде. Зур кимчелекләр булганын хәтерләмим. Касыймов абый төзелешкә дә зур әһәмият бирә иде. Күбәккә яңа торак өчен Баек авылы янындагы тау астыннан таш чыгарып, шуны трактор белән алып кайта идек. Без күптапкыр бардык. Йөкчеләр – Миңсылу апа, Хәйдәфә апаның сеңлесе Люция. Касыймов абый кешеләрне аермады. Булсынга эшләгән кешене төрлечә бүләкләде, хөрмәт итте. Ул безнең якны бик ошатты, әмма тормыш иптәше безнең якка күчмәгәч, 4 елдан соң кире Урәзмәткә китте.

Дәвамы бар ■

Кәрим Тинчурин. 1934 ел

Кәрим Тинчурин
(1887-1938)

1937 елның 15 сентябрендә драматург, актер, режиссер Кәрим Тинчуринга 50 яшь тула.

Бәйрәмнәр үтеп, күңелендә яңа әсәрләр язу, шуларны эшләү дәрте белән илһамланып яшәгән әдипнең язмышы кинәт кенә фаҗигале борылыш ала. 17 сентябрь төнендә (туган көннән соң 48 сәгать узгач) НКВД хезмәткәрләре килеп, язучыны кулга ала һәм Казандагы ПлӘтән төрмәсенә илтеп яба. (Карарда: *«Булган мәгълүматларга нигезләнеп, Кәрим Тинчуринның, хәзерге вакытта репрессияләнгән халык дошманнары Толымбай, Сәйфи, Атнагулов, Нәҗми*[1] *һ.б. белән берлектә, шушы көнгәчә идеология фронтында һәм башка участокларда гамәли контрреволюцион эш алып баруы фаш ителде»*, – дип язылган.)

Ел да ике ай чамасы дәвам иткән «махсус тикшерүләр» нәтиҗәсендә Кәрим Тинчуринга җиде пункттан торган гаепләү акты игълан ителә. Алар арасында *«буржуаз милләтчеләр оешмасында әгъза булып тору»*, чит илдә яшәгән һәм *«советның явыз дошманы»* булган Гаяз Исхакый белән элемтә урнаштыру, Япония файдасына шпионлык итү кебек кеше ышанмаслык уйдырмалар да була. Төрмәдә кыйнау, мәсхәрә ителүләрдән тәмам саулыгын югалткан әдип әлеге нахак гаепләрнең берсен дә танымый.

1938 елның 2 ноябрендә тикшерүче Гатин Тинчуринны соңгы тапкыр сорау алуга чакыра. Бу вакытка махсус оешмаларның түземлеге төкәнгән була инде: ТАССР НКВД

[1] Гомәр Толымбай, Фатих Сәйфи-Казанлы, Сәлах Атнагулов, Кави Нәҗми – татар әдипләре.

Рәхәт чаклар. Сулдан уңга: Кави Нәҗми, Сәрвәр Әдһәмова, Заһидә Тинчурина, Кәрим Тинчурин. 1929 ел

Кәрим Тинчурин. 1937 ел

дәүләт иминлеге идарәсенең (УГБ) 4 нче бүлеге начальнигы М.И.Шелудченко, 3 нче бүлекчә начальнигы Марголинга шылтыратып: «Ни өчен Тинчурин эше һаман «тройка»га тәкъдим ителми?» – дип сорый. «Ул әле оформить ителмәгән» җавабын ишеткәч, Шелудченко эшне тиз арада җиренә җиткерергә боера. Гатин күрсәтмәне берсүзсез үти. Җәлладлар шулкадәр ашыга ки, хәтта гаепләү актын эчке эшләр комиссары В.И.Михайлов тарафыннан раслатырга да оныталар.

1938 елның 14 ноябрендә җыелган өч кешелек Махсус киңәшмә (ОСО) Кәрим Тинчуринны атарга (мөлкәтен конфискацияләп) дигән хөкем карары чыгара һәм шуның нигезендә 15 ноябрь төнендә – бер сәгать илле минутта әдипнең гомере өзелә[2].

НКВД тарафыннан 1938 елда кулга алынган Хәниф Гайсин искә алганча, кышкы салкын көннәрнең берендә тоткыннарны урманга алып чыгалар һәм зур алан уртасында чокыр казырга кушалар. Сакчылар, әледән-әле вәхшиләрчә көлеп: «Үзегезгә кабер казыйсыз!» – дип кычкыра.

Озакламый төрмәдән юкка чыгачак чокыр казучыларның берсе – тоткын Кәрим Тинчурин була.

Әдәбият:

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.434-435.
2. Когда на сцене погас свет.../ Ф.Н.Багаутдинов, И.И.Илялова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – С.22-30.

*Язманы **Рүзәл Мөхәммәтша** әзерләде.* ■

[2] Кызыксынучылар өчен: әдәбият исемлегендә күрсәтелгән «Когда на сцене погас свет...» китабында Кәрим Тинчурин «эше» тирәнрәк ачыла. – **Р.М.**

Безнең мирас №4 апрель 2017

САГЫНУ

Розалина Шаһиева

Февраль аенда Татарстанның һәм Россиянең халык рәссамы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Бакый Урманченың (1897-1990) тууына 120 ел тулды.



Шул уңайдан шәһәребезнең төрле мәйданчыкларында бөек иҗаткяр, мәшһүр рәссам, нәккаш, сынчы Бакый Идрис улы Урманче ядына багышланган җыеннар, искә алу кичәләре, күргәзмә һәм башка шундый тамашалар булып узды. Бөтен Казан аның турындагы хатирәләр нурына күмелде. Урманченың 93 еллык гомере халкының күңеленә мәдәни зәвык, илаһилык, гүзәллек хисе иңдерүгә багышланды. Аны иҗат халәтенә китергән төп ике этәргеч – дөньяны тирәннән танып белү, бу сыйфатны халыкка җиткерү һәм кешелек дөньясына, туган илгә, аның табигатенә, тарихына, гүзәл гореф-гадәтләренә мәхәббәт иде. Шунлыктан аның образы бүгенге көн сәнгать әһелләренең, шагыйрь-фәйләсуфларның хәтерендә мәңгегә калачак.

– Бу сумалалы, ямьсез, кара кәүсәләрдән ясыйсызмы мине?

– Һи, дустым, синең өчен минем менә дигән яшь алмагачларым бар!..

(Урманче остаханәсендәге сөйләшүдән. 1970 елның июне.)

Урманче – XX йөз башында шытып, уртасында шактый төрләнеп, чәчәк атып, гөлләнер дәрәҗәгә җиткән, милли күтәрелеш елларында исә дөньякүләм шөһрәт казанган, XX гасыр татар сынлы сәнгатенең иң лаеклы, иң мәшһүр әһеле, тылсымчысы, Алып-пәһлеваны. Ул бу төр сәнгатькә нигез салучы да, остаз да. Алмагачларын кадерләп үстергән бакчачы кебек, шәкертләренә гаять игътибарлы Урманчены, сәнгатьче-иҗатчыны, шагыйрь-көйчене, мәгърифәтчене – кыскасы, олуг шәхесне мин бик сагынам.

Дөньяның мәдәни күгендә Рерих, Лев Толстой, Сартр, Эрьзя кебекләр белән бер дәрәҗәдә торырлык, сәнгать өчен янып-көеп, дөрләп яшәгән бу кешенең татар дөньясындагы урыны да, һичшиксез, Тукай, Әмирханнар, Дәрдемәнд, Исхакыйлар, Сәйдәш, Исәнбәтләр белән бер сафта. XIX гасырның азагында туып, милли җирлектә гыйлем-әхлак, һөнәрчелек сәнгате сабакларын алган Бакый Урманче аңыбызның шәме һәм иманы иде. Аның иҗаты да профессиональ төс алган халык һөнәрчелегенең чагылышыдай булды. Әмма Урманче – яңарыш чоры кешесе иде. Тормышының эпик куәте дә, иҗатының күпкырлылыгы да шул хакта сөйли. Аның әсәрләрендә кешегә мәдхия, аңа ышану, соклану, камил шәхес, зыялы, гали зат идеяләрен алга сөрү ярылып ята. Иҗаты, бер яктан, юнан цивилизациясенең киңлеген, самимилеген һәм табигыйлеген, икенче яктан, Шәрык дөньясының мигъмарчылыгын, миниатюра сәнгатенең нечкәлеген берләштергән бер базис, монолит булды. Тик, урта гасырның караңгы идеологиясен яктыртып, дин сөременнән, социаль изүдән мәҗүсилеккә, табигать кочагына, хайванәт-нәфисәткә өндәгән Баты (Европа) Яңарышыннан аермалы буларак, Урманче инанган ретро – тоталитаризм потларыннан, динне, милләтне эзәрлекләүче совет мәҗүсилегеннән күңел сафлыгына, халык дөньясына, ирекле милләт хосусиятенә, тарихка, ата-баба теленә, сәнгать-әдәбиятына кайту иде. Моның мисалы: мең яшьлек агач тамырыннан юнып башкарылган «Кисекбаш», татарның үлмәс-бетмәслеген мәңгеләштергән гаҗәеп карт образы – «Сагыш», садәлек һәм самими гүзәллек идеяләрен гәүдәләндергән «Язгы моңнар», янә тарихи фаҗига чагылышы – «Сөембикә», үз дәверенең чикләреннән ашып, космик биеклекләр киңлегендә, илнең киләчәгенә инанып иҗат ителгән «Татарстан» триптихы.

Урманченың Яңарыш чоры шәхесләренә хас булган тагын бер кыры – аның гаять масштаблылыгы, колачлылыгы, Европа һәм Шәрык илләре сәнгатеннән хәбәрдарлыгы, бу халыклар мәдәниятенең дөньякүләм кешелек цивилизациясендәге тоткан урынын билгели алуы иде. Ул халкыбыз мәдәниятен төрки халыклар сәнгате һәм тәрәккыяте белән бәйләп ка-

рый белде. Аның телендә Күлтәгиннәр, Йосыф Баласагунлы, Мәхмүд Кашгарый, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр, Нәвои, Карачиоглан, Тәүфикъ Фикрәт, Хикмәтләр булды. Бөек төрек мигъмарчысы Ибне Синанны Урманче илаһи остазы күрде. Икенче яктан, фарсы шигърияте: Гомәр Хәйям, Хафиз Ширази, Сәгъдиләрнең кыйтга-газәлләре, робагыйлары, миниатюралары, нәкышләре аның остаханә диварларын бизәде, күңеленең гөл куагына әверелде. Аның зыялылыгы, зәвыгы дустуганны да, галим-голәмәне дә, яшьләрне дә тартып, чакырып, әсир итеп торды. Мондый дуслык кабатланмас дивар панкнолары, хикмәтле шәмаилләр пәйда булуга да куәт биргәндер. Халыкның интеллектуаль потенциалын, иҗади фикерләү үзенчәлекләрен, тормыш сөючәнлеген, эстетик зәвыгын һәм гуманистик пафосын образлы нәкыш ысуллары аша гәүдәләндергәндә әнә шундый очрашулар, әдәби багланышлар ярдәмгә килгәндер.

Халыкның орнамент һәм декоратив сәнгатенә, милли һөнәрчелек традицияләренә таянып, Урманче беренче адымнарыннан ук, туып килгән татар сынлы сәнгатенә җитлеккәнлек, халыкчанлык, тормышчанлык сыйфатларын бирү сәләтенә иреште. Әдәбиятка таянып, аны тоеп эш итү – останы әле яңа гына яралып килгән нәкышчелек эчендә адашудан, сулдан уңга тайпылуларыннан тотып калды, иҗади көчен саграк, акыллырак сарыф итәргә мәҗбүр итте. Казанда формаль авангард хөкем сөргән елларда ул, гасырлар буена билгесез хаттатлар иҗат иткән татар китабы традицияләренә ияреп, сурәтле басма китап иҗат итү эшенә кереп китте. Г.Тукайның 1923 елда җирле нәшриятта дөнья күргән «Шүрәле» поэмасын алыйк. Тышында – бармагын агач ярыгыннан йолкып бәргәләнгән, бер күзле, кеше гәүдәле, дию пәриенә охшаган урман мәхлугы. Ә эчтә – бабларда – шәрык миниатюралары тәэсирендә туган сурәтле ирсал эчендәге сюжетлар. Инкыйлабка кадәр сурәтчелекне мәгъкуль күрмәгән, традицион фикерләүдән арынып җитмәгән татар дөньясының сынлы сәнгать белән танышуы да «китап бизәге», сурәтле иллюстрация аша үтә. Һәм бу төр сәнгать халыкка Бакый ага иҗаты аша ирешә.

Мәскәүдәге югары сәнгать уку йортын, аның берьюлы берничә остаханәсен тәмамлаган Урманченың профессиональ осталыгына, тумыштан килгән сәләтенә үз-үзен аямыйча эшләү кодрәте дә өстәлә: ул, кул талганчы чүкеп, мәрмәр, агач сыннар, гүзәл шедеврлар иҗат итә. Иҗатының башлангыч чорында ук дөнья сәнгатеннән хәбәрдар Урманче үз чоры стихиясенә кушыла, татар сынлы сәнгате тарихында мәңгегә калырлык, хөррият хисләре белән сугарылган гүзәл нәкыш әсәрләрен иҗат итә. Импрессионизм алымнарын эшкә җигеп, шигърият тулы бу әсәрләрендә Урманче, беренче булып, милли характер үзенчәлекләрен, милли эстетика зәвыкларын бирергә тырыша. «Сепаратор янында» (1928), «Сары кием кигән хатын» (1928), «Идел буенда» (1929), «Җилкәнле көймәләрдә йөзү» (1929) һ.б. әсәрләре, мәсәлән, әнә шундыйлардан.

Иҗатының икенче этабы – сөргеннән соңгы чор – 1938-1960 елларга туры килә. Бу елларда ул, Башкортстан, Урта Азия, Казахстан җирләрендә йөреп, төрле милләт сәнгать традицияләрен күңеле аша кичерә, рухи һәм профессиональ яктан байый һәм «байлыгын» «Йөзем җыю», «Шара Җандарбәкова портреты», «Ала-Тау» пейзажлары кебек әсәрләренә төшерә.

Казанга кайткач, 1960-1970 елларда, Урманче иҗатының яңа чоры башлана. Бу чор татар реалистик сынчылыгы пәйда булу белән билгеле. Груша, чинар агачы, зирек һ.б. агачларны юнып, Б.Урманче мифологик һәм реалистик образлар иҗат итә. Татар мәдәнияте әһелләренең Урал мәрмәрендә сынландырылган җанлы панорамасы (Кол Гали, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Фатих Әмирхан, Дәрдемәнд, Галимҗан Ибраһимов, Габдулла Тукай, Муса Җәлил) хасил була, ил һәм милләтпәрвәр татар шәхесләренең илаһи галереясы туа.

Гаҗәп: еллар узган саен тышкы яктан чаларып, мәгърурланып барган Урманченың иҗаты саегу күрмәде. Татар сынлы сәнгате тәрәккыятендә үзгәрешләр, стильләр алмашыну сыман

катлаулы күренешләр туган һәр очракта, ул эзләнүләр дулкыны өстендә, новаторлык принципларын яклаучы булып кала бирде. Сиксәненче еллар башында татар сынлы сәнгатенең академик тармакларында билгеле бер торгынлык, конъюнктурачылык хөкем сөргән чакта да, ул сынлы сәнгатьнең тәэсир итү көчен арттыруга, яңача фикер йөртү, метафора, аллегория, символ кебек чараларны куллануга йөз тотты. Яшь рәссамнарның иҗади эзләнүләре, табышлары белән берләттән, аның әсәрләре дә сәнгатебезне баетты.

Урманченың бу елларда иҗат иткән «Уйланулар» сериясе – борынгы чорларда яратылып та, соңыннан онытылган минниатюра сәнгатен халкыбызга кайтару иде. Туган як табигатенең, милли йолаларның, тарих һәм бүгенге көн хезмәт күренешләренең шигъри гәүдәләнеше булган бу рәсемнәр, миниатюра принциплары буенча, сюжет белән сюжетны, буын белән буынны, узган гомер белән бүгенгене тоташтыра торган әсәрләр булды. Аларны иҗат итеп, Урманче халкыбызның туган илгә мәхәббәтен җырлады, бу эзлекле хакыйкатьтә бәхет һәм ләззәт тапты.

Рәссамның гаять киң колачлы иҗатының чагылышы – «Истә калганнар» сериясе (1979-1980).

Дүрт картинаны берләштергән әлеге серия үткән һәм бүгенге турында уйланулар буларак кабул ителә. Яшәү мәгънәсе... Төрле уйлар кузгатучы фикер җепләре менә шундый бер төенгә җыйнала. Әсәрләргә балачак хатирәләре нигез итеп алына, әмма рәссам үткәннәргә бүгенге күзлек аша карый, истәлекләргә хәзерге тәэсирләрен кушып, фантазияне үстереп җибәрә...

«Зәңгәр чиләк матур була, су белән тулса гына...» Уралтау эргәсендәге елгага су алырга төшкән кызларны күргәч, мәгълүм халык җырының әнә шундый сүзләре хәтергә килә. Кайтыр якка борылган зифа буйлы кызның бизәкле чиләкләре бәрхеттәй мөлдерәп тора. Тагын да ерактарак ике атлы үтеп бара. Казлар да елгага төшкән. Һәр тарафта аклык-пакьлек, шигъри атмосфера тантана итә. Бәрхеттәй йомшак буяулар, нечкә декоратив бизәкләр белән эшләнгән «Уралтау эргәсендә» һаман яшь булып калучы аксакал рәссамыбыз Бакый Урманченың яшәү мәгънәсен тыныч тормыштагы хезмәт ләззәтен татуда, җирдәге матурлыкны саклап ишәйтүдә күрүен тагын бер мәртәбә ачык итеп раслый. Аның Тукайга булган хисләре, хәтер гыймарәте шагыйрьнең Тукай-Кырлайдагы архитектур-мемориаль корылмасы масштабына кадәр үсеп җитте. «Шүрәле»гә соңгы елларда ясаган рәсем серияләре исә тамашачыны авторның яңача карашы, этик, экологик концепциясе белән әсир итте, тетрәтте: «Шүрәле» – явыз да, аңгыра да, кеше дә, хайван да түгел, ә гүзәллек сөюче җилбәзәк җан, табигать баласы. Татарның борынгы мифы, үлмәслеге, мәңгелеге.

Остаҗның сиксәненче еллар ахырында иҗат иткән әсәрләре дә, нәкыш булса – төсләрнең Ренуарча матурлыгы («Флора Әхмәтова», «А.Абызгилдин» портретлары), сын булса – Рембрандча мәгънә тирәнлеге, рәсем булса, тормышның кабатланмас мизгелләрен тотып алу осталыгы белән таң калдыра. Япон рәссамы Хокусай әйткәнчә, ул, еллар узган саен, серлерәк һәм чишә алмый торган гүзәл табышмактай, гаҗәеп бер хикмәткә әйләнә бара. 90 яшьлек оста тарафыннан иҗат ителгән «Тулпар» уймасы соңгы табышмакларының берсе булып килеп баса.

Әйе, Урманче калдырган бетмәс-төкәнмәс нәкыш әсәрләре, сыннар, гүзәл графика, китап иллюстрациясе, милли кием эскизлары, бер сүз белән әйткәндә, аның мирасы – үзе бер гаҗәеп академия. «Урманче» сүзе үзе дә бүгенге көн татар мәдәниятендә күләмлелек, колачлылыкны аңлата торган төшенчәгә әйләнеп бара. Ялган эстетика фанатиклары, хөкемдарлар алдында тез чүкмәгән, мәгърур шәхес Урманче, Хәйямнарча тормыш сөеп, җыр җырлап яшәде...

Ул – бөек рәссам, сынчы, нәкышбәнд кенә түгел, яшь бөреләрне саклап, сыйпап үстерүче бакчачы остаз да иде. Иншаллаһ, Урманче бакчасы корымас, чөнки аның тылсымы, әфсене бар...

Мин остазымны сагынам... ■

Безнең мирас №4 апрель 2017

АПАС ЯГЫ – КУРАЙ ЯГЫ

Эльмира Каюмова

Фәнни сәяхәткә чыгар алдыннан берникадәр фараз кыласың: бу төбәктә үзенчәлекле фольклор җыелырмы, юкмы? Кайчакта: «Менә бу җирдә борынгы мисаллар булырга тиеш», – дип барасың һәм өметләр акланмыйча кала. 2010 елны Татарстанның Апас районына оештырылган экспедиция барышында кызыклы материал табылыр, дип көтмәгән идем. Ни өченме?

Өммегөлсем Ситдыйкова (1917 елгы), Чирмешән авылы. 2010 ел

Беренчедән, бу як Казаннан ерак урнашмаган, димәк, шәһәр йогынтысы сизелергә мөмкин. Икенчедән, казан татарларыннан (ә Апас районы халкы шул этник төркемгә карый) күбесенчә барыбызга да таныш булган соңгы чор җыр-көйләрен язып ала идек. Ә бу юлы шактый бай материал тупланды. Мәсәлән, биредә инструменталь сәнгатьнең үсеш алуы ачыкланды. Хәзергәчә гармун, курай, кубыз, мандолинада уйнау традицияләре саклана. Элегрәк бу якларда скрипкачылар да булган. Алга таба сүз курайлар турында барыр.

Апас җирлегендә берничә төрле курай таралган булган.

Кыска агач курай. Апас районының туган якны өйрәнү музее күргәзмәсендә урнашкан үрнәгенең озынлыгы 19 см, диаметры 2,1-2,4 см, уйнау өчен ике тишеге бар. Бу курайда Зур Болгаер авылында туып, күрше Әҗем авылына килен булып төшкән Саймә Дәүләтша кызы Шәфыйгуллина (1898-1991) уйнаган. Курайны абыйсы Мөбәракша юкә ага-

Автор фотолары

Агач курайлар

Рамис Ногманов, Апас районының туган якны өйрәнү музее директоры. 2010 ел

чыннан XX гасырның 20 нче елларында, ягъни моннан 100 ел элек диярлек ясаган булган. Саймә әби бу музыка коралында еш кына халкыбызның «Гөлмәрфуга», «Зөлхиҗә» һәм төрле бию көйләрен уйнарга яраткан. Башкаручының туганнары 2006 елда курайны музейга тапшырган. Әлеге мәгълүматларны музей директоры Рамис Госман улы Ногманов җиткерде.

Озын агач курай. Экспедиция дәвамында бу төренең өч данәсен күрергә насыйп булды. Беренчесен Апас районы Чирмешән авылында яшәүче Өммегөлсем Галим кызы Ситдыйкова (1917 елгы) тапшырды. Курайның озынлыгы 59 см, диаметры баш очында 2,2 см, ахыргы өлешендә 1,8 см. Ике тишемле, өрер өчен сыбызгысы бар. Өммегөлсем әби сөйләве буенча, әнкәсе Хәмдебану курай уйнап кызларны биеткән, әбисе дә (Багыш авылыннан) бик оста курайчы булган.

Икенче озын курай тавышын Дүртиле (Мазиково) авылында ишетергә дә насыйп әйләде. Бүгенге көндә, белүемчә, Апас районында берләнбер традицион башкаручысы – Әсрар Нургали улы Һидиятов (1938 елгы). Аннан «Тәзкирә», «Кызыл, кызыл бөрлегән», әнисеннән отып калган «Авыл көе» язып алынды. Әсрар абзый фикеренчә, бу курайга 200 ел бардыр, чөнки ул нәселләрендә буыннан-буынга тапшырылып килгән. Аның әбисе дә (Шәмсезоха Хисаметдин кызы Галимҗанова (1880-1958), Җәйләү авылыннан), әнисе дә (Шәмсенур Гыйният кызы Һидиятова (1901-1978), тумышы белән Апас авылыннан) уйнаган.

Өченче үрнәк Апас музеенда саклана. Аның озынлыгы 49 см, диаметры 1,7-1,9 см. Бу өрәңге агачыннан ясалган курайда Дүртиле авылында гомер кичергән Мәгъсүмә әби Җантимерова (1888-1991), ул 103 яшькә кадәр яшәгән!), «Салкын чишмә» дигән көен зур осталык белән башкарган. Әлеге музыка коралына 150 ел тирәсе. Гомумән, Дүртиледә хатын-кызлар су буена төшеп, курай уйный торган булган. Тыныч, аулак җирдә шулай күңел ачканнар.

Хәзерге заманга кадәр сакланып килгән үрнәкләре – ике тишемле. Әмма өлкән буын вәкилләре 5-6 тишекле кыска һәм озынчарак курайларны хәтерли. Дәвеш авылында гомер итүче Фәхрелислам Фәтхелислам улы Закиров әйтүенчә, бабасы Хәсәнгата Һидият улы Һидиятуллинның (1876-1947) кечкенә курае булган. Чама белән 30 см, 5 тишемле, юкә агачы кабыгыннан эшләнгән.

Чүри-Бураш, Коштаулы һәм башка авылларда курай киң кулланышта йөргән.

Шулай итеп, бу – күптәннән килә торган җирле традиция. Әүвәл ир-атлар да, хатын-кызлар да курайда уйнаган. Бүтән төбәкләрдән аермалы буларак, Апас якларында әлеге музыка коралын үсемлектән (көпшә үләне, әрекмән) түгел, ә агачтан (юкә, өрәңге, чикләвек) ясаганнар. ■

ИЛЧЕ КҮЧТӘНӘЧЕ

Равил Вәли

Кәрим Тинчурин белән Салих Сәйдәшев. 1930 нчы еллар

Илче Хәбиб бәгыреннән ургылган сагышлы сагыну сүзләре, дөрестән дә, йөрәкләрне өтеп-өтеп алды:

Кайнаган диңгезгә чумам,
Дулкыннар арасына.
Бәлкем тынгы табалырмын
Йөрәгем ярасына.

Дулкын әйтә: «Ник белмисең
Йөрәгеңнең дәвасын;
Читтә йөрмә – кайтып сула
Туган илең һавасын!

Кайтам инде: тулды күңел,
Тарайды сулышларым.
Илем сагынып җырлый-җырлый,
Каралды тавышларым.

– Булды бу, бәгырь! – диде Сәйдәш, илче Хәбиб сузган яңа җыр текстын алып һәм аны язылачак көйләренең сүзләре сакланган папкасына бик кадерләп салып куйды. – Рәхмәт, Хәбиб энем: Алжирдан бирле апкайткан күчтәнәчләрең һәм аеруча булачак «Туган илнең һавасы» исемле яңа җырыбызның сүзләре өчен дә! Мондый сүзләрне бары тик үзе чит илләрдә каңгырып яшәгән кеше генә яза ала...

– Җылы сүзегез, якты йөзегез өчен сезгә дә бик зур рәхмәт, Салих ага! Ә хәзер мин китим инде. Кадерле вакытыгызны аласым килми. Тамашачыларыгыз белән хушлашу кичәсенә дә әзерләнәсегез бардыр.

– Ярый соң, алайса, бәгырь... Кайткала һәм тагын кергәләп йөр! Бу күрешү соңгысы була күрмәсен! Тик шымчылар күзенә бигүк чалынмаска тырыш: җаваплы һәм дәрәҗәле эшеңдә зыян сала күрмәсеннәр.

– Ә үзегезгә?

– Мин инде алардан курыкмыйм! Буясын буядылар, каралтасын каралттылар. Эштән кыскарттылар, музыкамны уйнатмыйлар, җырларымны җырлатмыйлар... Менә Камал театры сәхнәсенә соң мәртәбә менәсем һәм төшәсем генә калды... Ә аннары...

Үлем хәленә китереп җиткерелгән бөек композитор илче Хәбибкә кинәт бик кызганыч булып киттте:

– Юк, Салих ага! Сезне сәхнәдән төшәргә мәҗбүр итсәләр дә, әсәрләрегез халык хәтереннән мәңге төшмәячәк! – диде ул, атаклы иҗатчының саубуллашу өчен сузган кулын кысып.

Илче Хәбибнең хисләре ташып, күңеле тулып китте. Әйе, бу хушлашу, үлем чире якасыннан тоткан авыру Сәйдәш белән мәңгелеккә хушлашу иде...

Ахыры. Башы журналның быелгы 1 нче санында.

***

Кадерле кунагын озатып җибәргәч тә Сәйдәш бүгенге очрашу тәэсиреннән котыла алмады. Ачык капкачлы рояль каршында, тынгысыз һәм борчулы уйларына күмелеп, ул байтак басып торды. Аннары, кулларын картлар кебек артка куеп, бертуктаусыз әрле-бирле йөри башлады. Авырткан җирдән кул китмәс, дигәндәй, аның да борчулы уйлары һаман да шул Черек күл тарафына барып ялганды.

Черек күлдәге иминлек сакчылар, дигәннән... Һәрвакыт турысын әйтеп сөйләшергә күнеккән Сәйдәшнең бу оешмадагы кискен холыклы абзыйлар белән каршылыклы мөнәсәбәткә керүе егерменче елларда ук башланган иде. Мәгълүм ки, драматург Кәрим Тинчурин белән композитор Салих Сәйдәшев тарафыннан иҗат ителгән «Зәңгәр шәл» музыкаль драмасы 1926 елны беренче мәртәбә Камал театры сәхнәсендә күрсәтелде. Ил билендәге икътисади богаулар шактый бушатылган НЭП чоры иде бу! һәр тарафта ирекккә, азатлыкка омтылыш! Хөррият!

Күпме еллар, күпме гасырлар империя кысаларында интегеп яшәргә мәҗбүр ителгән татар халкының ирекккә, иркенлеккә омтылышы, ил өстенә инде кара канатларын җәя башлаган Сталин репрессияләренә протест буларак, «Зәңгәр шәл»нең һәр күзәнәгеннән бөркелеп, бәреп тора. Әсәр музыкасыннан бигрәк тә! Карагыз сез урмандагы качкыннар тормышы сурәтләнгән өлешне. Яки шахтерлык хезмәтеннән кайтып килүче Булатны якташлары каршы алу күренешен. Күпме ашкынып, ярсый-ярсый биюләр, күпме дәртләнеп җырлаулар!

Мондый халыкка коллык богауларын кидерергә мөмкинме?! Юк, һичкайчан!

Шулай итеп, алгы сафка чыгып, әсәрдәге музыка «Зәңгәр шәл»нең төп әйдәүче көченә әйләнде. Менә шушы хәл аны татарның мәңге искермәс милли символына әйләндерде, һәрхәлдә, «Зәңгәр шәл»гә татарның милли азатлык байрагын тоттыру өчен, Сәйдәш бөтен көчен, бөтен сәләтен бирде һәм ул моңа ирешә дә алды кебек, шөкер!

Ләкин моны тамашачы нәкъ менә шулай кабул итеп бетерә алдымы соң? Юк, һич кенә дә юк! Чөнки аның колагына һәрдаим тукый килделәр: «Зәңгәр шәл» диннән, аңа хезмәт иткән комсыз ишан-муллалардан көлә. Театр тәнкыйтьчеләре дөресен әйтергә курыккач, әлбәттә инде, тамашачылар да әсәрдә ярылып яткан асыл хакыйкатьне тиешенчә аңлап бетерә алмады.

Ә Черек күл әһелләренә тирәнгә төшеп уйларга наданлыклары комачау итте кебек. Аларга нәрсә: арба ватылса – утын, үгез үлсә – ит! Ярый әле, ул хәтәр елларда монысы шулай булган! Юкса, пьеса авторы Кәрим Тинчуринның гына түгел, тагын бик күпләрнең, шул исәптән музыка авторы Салих Сәйдәшевнең дә башлары Себер киткән булыр иде.

Ә менә утызынчы еллар азагында Кәрим Тинчуринны төрмәгә япкач, иминлек сакчыларының да наданлык сөреме баскан күзләре ачыла төште кебек. Алар атаклы халык дошманының иҗатташ-автордашы һәм җан дусты Салих Сәйдәшевкә карашларын тагын да салкынайттылар. Аңа эшендә һәм тормышында һәрдаим аяк чалып, комачаулыклар тудырып тордылар.

Бу урында, артык дулкынланудан ашказаны турысында көчле чәнчү тоеп, Сәйдәш коры сөяккә калган күкрәген хәлсез куллары белән сыпырып куйды. Аның кинәт тәмәке тартасы килеп китте. Тик өстәл тартмасында яткан портсигарның эче бупбуш иде.

Хурлык! Өйдә тәмәке сатып алырлык та акча калмаган! Ләкин Сәйдәш кеше авызыннан төшкән сасы төпчеккә һичкайчан үрелмәячәк! Тартырга теләнү өчен урамфәләнгә дә чыгып китә алмый. Чөнки сәхнә кешесен эте дә, бете дә таный. Ачуына чыдый алмагач, Сәйдәш буш портсигарны почмактагы чүп чиләгенә тондырды. Аш-

казаны авырткан кешегә тәмәке турында хәтта уйларга да ярамый, диләр. Бу сүзләр дөрестер, күрәсең.

Бераздан Сәйдәш азрак тынычланган кебек булды. Күкрәк турысы да чәнчеми башлады. Ләкин ачуы бөтенләй үк басылмады.

Менә ул почмактагы ачык капкачлы рояль каршына килеп утырды. Ләкин уйнамады. Аның бармаклары бу юлы аклы-каралы клавишларга түгел, ә янәшәдәге китап киштәсенә үрелде.

Әйе, илче Хәбиб белән бүгенге очрашу алда торган кичәнең бер бик мөһим өлешен ачыкларга булышты. Әлеге кичә, һичшиксез, алар иҗат иткән «Күзләр» драмасыннан Рәйсә җырын башкарып тәмамланырга тиеш икән бит! Чөнки тема уртаклыгы әллә кайдан күзгә ташланып тора: тегендә – авыл белән хушлашу, ягъни «Хуш, авылым!»; монда – Камал театры сәхнәсе, тамашачылар белән саубуллашу, ягъни, хуш, театр, хуш, сәхнә!

Тик мондый хушлашу гына Сәйдәш өчен аз булачак!

Илле, нибары илле яшен үтеп барганда яраткан эшеннән аерып, хәсрәтен тарату өчен тәмәкесе дә булмаслык хәлгә төшерүчеләргә күп санлы тамашачылар алдында чиксез нәфрәтен белдерү өчен, аңа ниндидер көтелмәгән адым ясарга кирәк икән бит! Ләкин хушлашу темасы белән бәйле нинди адым соң ул?

Сәйдәшнең сизгер кулы китаплар киштәсеннән үзенең иң яраткан һәм якташ шагыйре Габдулла Тукайның шигырьләр җыентыгын эзләп тапты. Кат-кат укылганлыктан, аның «Өзелгән өмет» шигыре урнаштырылган кирәкле битенә кәгазь тасма салып куелган иде. Тиешле битне тиз генә ачып, Сәйдәш аны ашыга-ашыга күздән кичерә башлады. Менә ул бер уку яки ишетүдә үк күзләрне яшьләндерә торган искиткеч илаһи юллар:

И мөкатдәс, моңлы сазым, уйнадың син ник бик аз:
Син сынасың, мин сүнәмен – аерылабыз, ахрысы...

Әйтерсең, Тукай бу юлларны үзен генә түгел, ә Сәйдәш язмышын да, аның үз тамашачылары белән хушлашу кичәсен дә күздә тотып язган! «Син сынасың...» – дип, хәтта ул кичәдә аның нишләргә тиешлеген дә тәгаен генә әйтеп-күрсәтеп биргән түгелме соң?! Әлбәттә, шагыйрь телендәге сыну ул – образлы сыну, Тукайның ни әйтергә теләве яхшы аңлашыла. Тик тамаша залында әнә шул сыну-сындыру гамәлен ничектер күрсәтеп биреп булса, бу бик урынлы, сәнгатьчә ышандыру көченә ия булыр иде. Ләкин сәхнә хәтле сәхнәдә нәрсәне һәм ничекләр генә сындырып булыр икән соң?

Уйлый торгач, монысының да җавабы табылды кук. Син бит дирижер! Әлбәттә, кичә азагында дирижер таякчыгын ялгыш кына кулдан төшереп җибәрергә кирәктер. Ул идәнгә төшкәндә нәрсәгәдер бәрелсен һәм шартлап сынсын! Бу сыну авазы скрипка кылларының өзгәләнеп елау, музыкаль тәлинкәләрнең бер-берләренә гөрсгөрс бәрелеп кую тавышларына ялганып китеп, еракларга таралсын! Аны тыңлап, тамашачыларның күңелләре тетрәнсен!

Һәм гадәти булмаган «яңалык»ның иң көтелмәгәне, иң бәгырьләргә тия торганы: тәртәгә сыймаган бу гамәлләрнең һәммәсе дә кара төстәге озын итәкле дирижер кәзәкиен кара галстуклы ак күлмәк өстеннән түгел, ә ялан тәнгә киеп башкарылачак! Уйлана торгач, дирижер таякчыгының да стандарт рәвешле – шома, матур очлы, ялтыравык итеп эшләнгәне түгел, ә чүплектә аунап яткан гап-гади таяк булырга тиешлеге ачыкланды. Гомере азагында пенсия яшенә дә җитмәгән Сәйдәшне шушындый мескен хәлгә төшерүчеләргә сәхнәдән ачыктан-ачык протест һәм чиксез нәфрәт белдереп!

Менә болар, ичмасам, театр тамашачылары белән соңгы тапкыр аерылышу-хушлашу темасын тагын да көчәйтеп, күңелләрдә сәнгати яңгыраш табачак!

***

Татарның атаклы композиторы Салих Сәйдәшев белән соңгы тапкыр хушлашу-саубуллашу кичәсе дә килеп җитте.

Менә оркестр каршына ялан тәне... өстеннән күлмәк-галстуксыз гына озын итәкле кара кәзәки киеп җибәргәч канатсыз карлыгачка охшап калган сәер Сәйдәш чыгып басты.

Ул шома, матур итеп очланган дирижер таякчыгы түгел, ә чүплектә озак вакытлар аунап яткан очраклы бер гап-гади таякны тузгыган чәчле башы өстенә күтәргән иде.

Сәер-ят киемле, башы өстендәге гап-гади таяклы Сәйдәшне күргәч, алма төшәрлек тә буш урын булмаган тамаша залы бермәлгә тынсыз калды. Ләкин гаҗәпсенгән берниндн чыш-пыш килүләр күренмәде. Әйе, тамашачылар аның бу минутлардагы рухи халәтен, гадәти булмаган һәм көтелмәгән гамәлләре белән авыру композиторның ни әйтергә теләвен аңлады кебек. Монысы – иң мөһиме!

Көчле алкышлар, чәчәкләр яңгыры белән аралаша-аралаша, Сәйдәшнең төрле әсәрләреннән өзекләр, көйләр яңгырады. Ә кичә, алдан уйланылганча, «Күзләр» пьесасыннан «Хуш, авылым!» җырын башкарып тәмамланырга тиеш иде.

Рәйсә җыры азагына якынлашып, «...Хуш, авылым, сау бул, сәламнар көт...» дигән сүзләр яңгырауга, Сәйдәш баш өстендәге таягын кинәт бер якка көчле генә селтәп куйды да аны «ялгыш» кына идәнгә төшереп җибәрде. Ул таяк, нәрсәгәдер эләгеп, шартлап сынды. Дөресрәге, сынмады, ә урталай өзелде! Өзелгән моң тавышын ишетеп, алдан сүз берләшеп куйгандай, бөтен оркестр кинәт тынып калды. Тик музыкаль тәлинкәләр генә, берсе өстенә икенчесе сугып, чаң каккандай шомлы авазлар чыгардылар һәм аларны тамаша залына очырдылар. Әйтерсең, ул авазлар бөтен җиһанга ишетелерлек оран салалар иде:

– Хуш, Сәйдәш, хуш-ш-ш!.. Сәйдәш китә – ник китә: аның урыны буш, буш-ш-ш!..

Оркестр, бер туктагач, инде бүтән уйнап тормады. Рәйсә җырын башкарган артистка Марзия Миңлебаева да, Сәйдәшнең көтелмәгән гамәлен күреп, җыр азагына барып җитә алмады. Менә тамашачылар дәррәү торып бастылар да гөрләтеп кул чабарга тотындылар. Кайнар кул чабулар моңарчы күрелмәгәнчә бик озак дәвам итте. Аларны сукыр Рәйсәнең яңадан күрә башлау шатлыгы гына түгел, мәшһүр композитор белән соңгы хушлашу ачысы да шулай тетрәтте кебек, һәрхәлдә, Сәйдәш бу минутларда Рәйсәнең генә түгел, үзенең дә күңел күзләре бик нык ачылып китүен ачык тойды. Кәрим Тинчуринны халык дошманы дип төрмәдә интектерделәр. Ялган гаеп тагып, биелми калган «Гөлнара» балетын да тимер читлеккә ябып куйдылар. Ярым тоткын хәлендә иректә яшәве дә җиңел түгел. Хәер, кулларга богаулар, аякларга тышаулар кидерелгән илдә нинди ирек ди инде ул?!. Бүген булмаса, иртәгә тотып ябарлар күк.

Татарның иң талантлы һәм булдыклы улларыннан берсе Кәрим Тинчурин – тоткын, куелмый калган «Гөлнара» балеты – тоткын, кая карама – гел тоткын да тоткын!.. Уйлап баксаң, бүген бөтен ил үзе тоткын икән бит!

Мондый тоткын илдә яшәү һәм иҗат итүнең бернинди кызыгы юк. Менә каты авыру хәлендә сине дә озакламый Мәскәү хастаханәсендәге үлем түшәгенә илтеп салачаклар.

Әйе, бу изге сәхнә белән һичшиксез соңгы тапкыр хушлашу-бәхилләшү иде.

Хуш, мөкатдәс, моңлы саз!

Уйнадың син ник бик аз?..

2016, гыйнвар-март. ■

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

Тартария картасы

ТАРТАРИЯ — Электә Көнбатыш Европа терминологиясендә Евразиядә татарлар яшәгән гаять зур территория. Европа тарихчылары төзегән карталарда *Бөек Тартария*, Идел-Урал буйларыннан алып, Себернең шактый өлешенә һәм Үзәк Азия төбәкләренә кадәр җәелгән. Рафаэль Хәким Тартариянең үзен аерым географик-территориаль берәмлек итеп карый һәм: «Килер бер көн, «Тартария» исемле кыйтганы да яңадан ачарлар», – дигән ышанычын белдерә.

ТАРТУ КӨЧЕ *тар.* — Минзәлә төбәгендә туй чыгымнары өчен егет ягыннан кызның ата-анасына бирелә торган акча. Механик мәгънәдә бу термин русча «тягловая сила»га (гадәттә ат көченә) туры килә. Тарту сүзе «кияүнең кәләшкә биргән бүләге» мәгънәсендә Котбта очрый. *//Шулай тарту җыеп, кәбен юнәтте, / Ширин килсен, дип, илчеләр юнәлтте.* Котб, «Хөсрәү-Ширин хикәяте».

ТАТАРЧА ЯЗУ МАШИНКАСЫ — Казанда Татарстан Матбугат һәм нәшрият комбинаты, 1925 елның 17 гыйнварында татарча язу машинкалары мастерское ачып, язу машинкалары җитештерү эшенә нигез сала. Татар (гарәп) хәрефләренең киңлеге төрле үлчәүдә булганлыктан, теге яки бу клавишка басканнан соң, тиешле хәрефнең киңлегенә карап, машинканың сикертмә киңлеген дә төрлечә ясавына ирешү өчен, комбинат хезмәткәре Әскәр Шәех-Алигә машинка конструкциясенә үзгәрешләр кертергә туры килә. Яңа машинкада аерым хәрефләр белән язарга, шулай ук баш, урта, ахыр һәм ялгыз хәрефләрнең һәммәсен дә урнаштырырга мөмкин. Ике телдә баса торган бу машинкаларның бәясе 400 сум чамасы була.

Башта комбинат көн саен берәр генә машинка эшләп чыгарган. ■

Дәвамы. 2014 елның 3 нче саныннан басылып килә.

Безнең мирас №4 апрель 2017

Дөрес яза беләбезме?

Гомәр Бәширов
(1901-1999)

Туган телгә ваемсыз караштa булып, ярар шунда, яз шунда, киртәсенә керсә, шул җиткән, диебрәк эш йөрткән кешеләр күңелендә бу сүзләр, бәлки, нинди дә булса берәр уй тудырмас та. Әмма тормышта телнең нинди әһәмиятле урын тотуын, аның матурлыгын, нечкәлекләрен аңлаучыларга бу фикер бик әйбәт киңәш булып хезмәт итә ала. Эш шунда ки, тел үзенең табигате буенча сизгер, тере организмга охшый. Ул өзлексез үзгәреп, яңарып тора.

Кайчакны шундый кызык хәлләр дә булгалый. Кайбер сүзләр, элеккеге эчтәлекләрен онытып, тора-бара бөтенләй яңа мәгънә аңлата башлый. Тормышта кирәге беткәнлектән, әйләнештән төшеп калган сүз һәм төшенчәләр дә бик күп. Менә бер мисал. Мин малай чагында, сабан өстендә басуга чыксаң, төрле яктан: «Ягалай, ягалай» – дип кычкырган тавышлар ишетә идең. Нәрсә дигән сүз соң бу «ягалай?» Сука белән сабан сөрүче агай заманында шушы сүз белән атына әмер бирә. Буразнага төшмә, ягадан, ягъни буразнаның кырыеннан атла, дип кисәтә иде. Билгеле, хәзерге заманда бу борынгы сүзнең кирәге калмады. Хәзерге игенче күбесенчә машиналар белән эш итә. «Ягалай» сүзе белән хәзер тарихи әсәрләр язучы әдипләр һәм халыкның гореф-гадәтләрен өйрәнүче галимнәр белән телчеләр генә кызыксынырга мөмкин.

Искергән сүзләр шул рәвешчә төшеп кала барса, икенче яктан тормыш телгә яңа сүзләр өстәп тора. Җәмгыять тормышындагы һәрбер зур вакыйга диярлек телгә дә яңалык кертә. Мәсәлән, Советлар Союзы җирнең беренче иярченен космоска чыгарган көнне планетадагы бик күп төрле телләргә «спутник» сүзе дә килеп керде. Бөек Ватан сугышы да телгә күп кенә яңа сүзләр, яңа төшенчәләр өстәп калдырды. Әмма торган саен камилләшә, баебарган телебездә колакны рәнҗетә, күңелдә канәгатьсезлек тудыра торган ямьсез сүзләр, шыксыз гыйбарәләрне дә бик еш очратабыз. Минемчә, телне чүпләндерә торган ул ялгышларның күбесе нигездә чит телләрдән кергән сүз һәм төшенчәләрне дөрес файдалана белмәүдән килә. Зур хаталар барыннан да бигрәк көндәлек матбугатта, аның да тәрҗемә өлешендә күбрәк очрый.

Мәгълум ки, рус теле инкыйлабтан соң башка милләтләр теленә бик күп яңа сүзләр, яңа төшенчәләр биреп, аларның сүзлек составын сизелерлек дәрәҗәдә баетты. Кайчандыр рус теленнән кереп тә, вакыт узу белән тәмам үзебезчә булып ишетелә башлаган аерым сүзләр һәм төшенчәләр безнең телдә хәтсез күп очрый. Әмма башка телләрдән файдалануның һич тә бозарга ярамый торган бик катгый һәм мәҗбүри бер кагыйдәсе бар. Ул да булса, чит телдән кергән сүз тулысынча татар теле кагыйдәләренә буйсынып, безнеңчә әйтелергә, безнеңчә язылырга тиеш. Мәсәлән Москва түгел, Мәскәү, шляпа түгел, эшләпә һәм башкалар. Әгәр дә инде чит телдән, бөтен бер гыйбарә, афоризм, мәкаль, әйтем кебекләр алына икән, андыйларны, кайберәүләр әйткәнчә, бер тиенгә бер тиен, ягъни сүзгә-сүз тәрҗемү итү генә җитми. Андыйларга нәкъ шул төшенчәне аңлатырдай җөмләне, образ-

Әгәр дә инде чит телдән, бөтен бер гыйбарә, афоризм, мәкаль, әйтем кебекләр алына икән, андыйларны, кайберәүләр әйткәнчә, бер тиенгә бер тиен, ягъни сүзгә-сүз тәрҗемә итү генә җитми.

ны, афоризмны туган телнең үзеннән табарга кирәк була. Мәгънәсез сүзләр, җансыз җөмләләр кулланып тел бозулар нәкъ шунда башлана да инде. Мәсәлән, Бөек Ватан сугышыннан соң көндәлек матбугатта еш кына «ул сугышта башын салды», «ул сугышта кулын» яки «аягын калдырып кайтты», дип яза башладылар. Көндәлек матбугатны әйткән дә юк, мондый әйтелеш шул килбәтсез хәлендә хәтта матур әдәбиятка да килеп керде. Хәзер инде шушы җансыз штампны, уйлап та тормастан, теләсә нинди әсәрдә кабатлый бирәләр.

Хәлбуки, гәрчә безнең сүзләребездән оешкан булсалар да, бу җөмләләр һич тә татарча яңгырамыйлар. Шул ук җөмләне, «ул сугышта аягын өздереп кайтты», «ул сугыштан кулсыз кайтты», дип язсаң, саф халыкча булыр иде.

«Баш салу» да безнеңчә үлемне аңлатмый. Бездә ул иркәләнүне белдерә. «Ул егетнең иңенә башын салды», – диләр.

Сүзләрнең туры мәгънәсеннән тыш, җөмләнең эчке мантыйгы да бар бит әле. Нәрсәнедер булса калдырып кайту турында сүз чыга икән, шунда ук аны кире барып алу мөмкинлеге дә күздә тотыла. Димәк, болай сүзгә-сүз тәрҗемә итү бу яктан да ялгыш булып чыга.

Шундыйлардан менә тагын бер мисал. Бер журналист телевидениедә беренче уку көненә багышлаган чыгышын һичбер кереш сүз, фәләннәр белән бизәкләп тормыйча, туп-туры, «тышта сентябрь», дип башлап җибәрде. Һич көтмәгәндә күктән килеп төшкәндәй бернигә дә бәйләнеше булмаган бу сәер сүзләрне ишетеп, тыңлаучылар аптырабрак калдылар. Русча «во дворе сентябрь» дип әйтү көз башлануын аңлатса да, шул ук җөмләне сүзгә-сүз безнең телгә тәрҗемә итү бер мәгънә дә бирми. Журналистның ни әйтергә теләве чыгышының дәвамыннан гына аңлашылды. Ул «менә көз дә башланды» яки «менә сентябрь дә җитте» дип әйтергә теләгән булса кирәк. Ләкин журналист, кеше колагына ятышлы булсын өчен, ул фикерне безнең телдә ничек әйтергә кирәклеге турында уйлап маташмаган, башына килгән русча шаблон җөмләне сүзгә-сүз генә аударып ташлаган.

Газетә-журнал яисә әдәби әсәрләр укыганда әледән-әле «юк-юкта» дигән сүзләр очрый. Башта гаҗәпләнеп каласың, чөнки бу безнеңчә түгел, чөнки безнең телдә ике «юк»ны янәшә куеп, аларга «та» кушымчасын өстәү бер мәгънә дә аңлатмый. Тик моның русчасын эзләп тапканнан соң гына төшенәсең, бу табышмак җөмлә русча «нет-нет, да и взглянет» яисә «нет-нет, да и вспомнит» дигән төшенчәнең сүзгә-сүз тәрҗемәсе икән ләбаса. Телгә карата ваемсызлык менә кайларга алып китә. Үз телеңне аңлау өчен, башта аны бүтән телгә тәрҗемә итү кирәк булып чыга.

Әдәби телнең тәэсир итү көченә, аның матурлыгына, тәрбияви роленә зарар китерә торган мондый калька җөмләләр, таушалып беткән штамплар соңгы елларда бик еш кабатлана башлады. Яшь язучы яисә яшь журналист җибәргән хата тагын бер хәл, аларны гафу итәргә дә мөмкин, чөнки алар телебезнең бик борынгыдан килә торган нечкәлекләрен белмәскә дә мөмкин. Кызганыч ки, кайвакыт калькаларны өлкән яшьтәге иптәшләр дә кулланалар. Бер автор, мәсәлән, өлкә газетасында: «Ул үзенең алыштыргысыз булуына ныклап ышана башлаган иде, күрәсең», – дип яза. Бит саен диярлек «бу аңлашыла да» дигән шаблон җөмлә очратасың. Нәрсә аңлашыла икән, дип гаҗәпкә калмагыз, сез аны русчага тәрҗемә итеп карагыз. Автор безнеңчә ничек язасын уйлап тормастан, «это и понятно» дигән русча җөмләне кабатлаган. Яисә укый торгач, һич көтмәгәндә һәм сүз сөрешеннән мондый сүз һич

кирәкмәгән бер урында «кирәк бит» дигән сүзләр күреп, аптырап каласың. Монысы русча «надо же» дип әйтелә. Рус телендә ул көтелмәгән хәл килеп чыгуны, гаҗәпләнүне белдерә. Шул ук төшенчәне сүзгә-сүз безнеңчәгә әйләндергәндә ул нәрсәнеңдер кирәклеген белдерә.Моны кистереп, өзеп әйтә торган, димәк, бөтенләй икенче мәгънә бирә торган башка җөмләгә әверелә. Инде башыңа шундыйрак төшенчә килеп кергән икән, аны бит халык аңлый торган итеп үз телеңдә дә әйтергә мөмкин. Мәсәлән, ул җөмлә безнеңчә «һич көтмәгәндә, менә сиңа, мә!» кебегрәк булыр иде. Нәрсәдән килеп чыга менә мондый хәл? Аның сәбәпләре бик җитди булса кирәк. Безнең заманда русча уйлап та, шул уйлаганын үз теленә әйләндереп язучылар вакыт узган саен арта бара. Билгеле, һәр кешенең теләсә нинди телдә уйларга хакы бар. Әмма уйларыңны ак кәгазьгә төшерергә, аны халыкка җиткерергә телисең икән, син аларны халык аңлардай итеп, әдәби тел нормаларына туры китереп яз.

Матбугатта һәм сөйләмдә тупас рәвештә тел бозу, үз телеңнең бай хәзинәсеннән файдаланмыйча калькалар, әзер шаблоннар куллану – ул техник хата гына түгел, ул язган әсәреңнең укучыга һәм тыңлаучыга тәэсир итү көчен, димәк, аның тәрбияви ролен юкка чыгару дигән сүз.

Күптөрле хаталар, калькалар, шаблон җөмләләр белән чуарланган язуны моңы булмаган җырчы авазы белән чагыштырырга мөмкин. Андый җырчының тавышы да көчле булуы ихтимал, ул нота билгеләрен дә дөрес куллана, һәртөрле борылышларны да нәкъ кирәк урында ясый, тавышы белән дә оста идарә итә, кыскасы, формаль яктан ул дөп-дөрес җырлый, әмма дә бөтен бәла шундадыр ки, табигый моңы булмау сәбәпле, ул тыңлаучыны дулкынландырмый, димәк, аңа тиешле ләззәт бирә алмый, димәк, аның җырлавы файдасыз, җилгә очкан хезмәт булып чыга.

Мәгълүм ки, һәр милләтнең теле аның тиңе булмаган иң кадерле рухи хәзинәсен, мирасын тәшкил итә. Күп-

Мәгълүм ки, һәр милләтнең теле аның тиңе булмаган иң кадерле рухи хәзинәсен, мирасын тәшкил итә. Күп кырлы бу хәзинәне халык үзенең мең елларга сузылган озын гомере буена берәмтекләп җыйган. Ул үзенең иң кадерле акыл байлыгын, талант ияләре иҗат иткән фольклор җәүһәрләрен, нечкә хисләрен, акыл ияләренең тирән фикерләрен, гореф-гадәтләрен берсен дә югалтмыйча саклау өчен ышанып телгә тапшырган.

кырлы бу хәзинәне халык үзенең мең елларга сузылган озын гомере буена берәмтекләп җыйган. Ул үзенең иң кадерле акыл байлыгын, талант ияләре иҗат иткән фольклор җәүһәрләрен, нечкә хисләрен, акыл ияләренең тирән фикерләрен, гореф-гадәтләрен, берсен дә югалтмыйча саклау өчен, ышанып, телгә тапшырган. Бәхеткә, тел халыкның шушы бөек ышанычын тулысынча аклаган, дип әйтер идем. Ул халыкның бу байлыгын үз башыннан узган мәрхәмәтсез сугышлар, иксез-чиксез афәтләр аша, ачлыклар, янгыннар, һәртөрле кысулар, изүләр аша, әрәм-шәрәм итмичә, безнең заманга кадәр саклап килгән. Шәт, киләчәк буыннарга да саклап алып барыр.

Димәк, телнең кадерен белмәү, аның белән тупас кылану, телгә карата ваемсызлык күрсәтү – үзен татар дип санаучы, үзен һәм халкын ихтирам итүче кешегә һич тә килешә торган эш түгел. Моны наданлык бәласе дип кенә атарга мөмкин.

Ред: *Г.Бәшировның бу язмасын, авторның үз тавышы белән, «Безнең мирас» сайтыннан тыңлый аласыз.*

Татарстан радиосының «Тел күрке – сүз» тапшыруына нигезләп, басмага ***Рөстәм Акъегет*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №4 апрель 2017

Әлмән шәхесләре

Әнвәр Кидрасов*

Курган өлкәсенең Әлмән авылындагы Ф.И.Шакирова исемендәге «Дуслык»музееен хәзер дә өлкән буын кешеләре «иске мәчет» дип йөртә. Дөрестән дә, XX гасырның 30нчы елларына кадәр биредә Әлмән авылының Төньяк мәчете урнашкан. Ике йөз, ә бәлки аннан да күбрәк еллар дәвамында анда азан тавышы яңгыраган, халык Коръән һәм намаз укыган.

Оренбург губернасының Эчкен волостена кергән Әлмән авылы халкы борынгыдан үзенең динилеге белән аерылып торган, хәтта совет чорында да кайбер «галимнәр» авылдашларымны дини фанатизмда гаепләгән.

Әлмән авылы гасырлар дәвамында төбәкнең рухи үзәге булган. 1867-1871 елларда биредә татар иҗтимагый хәрәкәтенең булачак лидеры, язучы һәм журналист, дин галиме Габдерәшит Ибраһимовның белем алуы әһәмиятле факт. Габдерәшитнең әнисе Гафифә

Фазыл хаҗи Тенәкәчевнең кабер ташы Әлмән авылының «Дуслык» музеенда саклана

*Әнвәр Кидрасов – Курган өлкәсе Әлмән авылының Мәдәният йортында төбәкне өйрәнү секторы мөдире.

Ибраһим кызы – Әлмән авылыннан, заманының күренекле абыстае. Г.Ибраһимов аның турында: *«Тара шәһәрендә яшәүче бөтен хатын-кызларның уку-яза белүләре беренче чиратта минем әнием казанышы»*, – дип язып калдырган.

Омск өлкәсенең Тара шәһәрендә яшәгәндә Гафифә абыстай улын үзенең туган авылына белем эстәргә җибәрә. Габдерәшит Урал аръягындагы авылга кышкы чатнама суыкта алты дусты белән килеп төшә. 500 кешелек мәдрәсәдә урын булмау сәбәпле, алар шәкертләрне үз өйләрендә бушка тотучы бер кешенең йортына кереп сыена. Шуны да әйтергә кирәк: бу заманда үз йортында бушлай мәдрәсә шәкертен тоту зур дәрәҗә һәм мәртәбә саналган. Габдерәшит Ибраһимов күңеленә әнисенең туган авылы, аеруча аның кешеләренең диндарлыгы хуш килә.

Булачак дин галиме биредә атаклы имам һәм мөдәррис Габделәхәт бине Габденнасыйр бине Сабит әл-Эчкени әл – Әлмәни (1814-1880) хәзрәттә белем ала. «Исагуҗи», «Шәрхе шәмсиясе», «Шәрхе Гакаид», «Тәүзыйх», «Талхыйс», «Мохтасарел-викайа», «Һидая», «Тәфсир Бәйзави» кебек борынгы мәдрәсәләрдә укыла торган китапларны өйрәнә.

Габделәхәт хәзрәтнең атасы Габденнасыйр бине Сабит бине Сәфәргали әл-Эчкени әл-Әлмәни (1742-1841) дә

Фазыл хаҗи Тенәкәчевнең сыны

авылыбызның зыялы, укымышлы инсаны булган. Ул Бөре өязендә Яугилде авылыннан Габденнасыйр исемле хәзрәттә укый, Дагыстанда белем эстәп кайта, ә аннары гомере буе шәкертләр тәрбияләү, китап язу белән шөгыльләнә. 1841 елда күчереп язган китабында остаз: *«Моның белән барлык язган китабым 223 җилд булды; 20 яшемнән китап яза башлаган идем, хәзер 95 яшемә ирештем, һич күзлек кимәдем, чыра яндырып яздым, хәзер гәрчә шәм дигән бер нәрсә чыкса да, берәр кич яндырырлык шәм алырга да акчам юк, инде картайдым, бәлки моннан соң язырга куәтем дә җитешмәс!..»*– дип теркәп калдыра. Аның тарафыннан күчереп язылган китапларны Әлмән мәдрәсәсе һәм мөгаллимнәре, аеруча улы Габделәхәт, нәхү, сарыф һәм мантыйк дәреслеге буларак файдаланган.

Авылның атаклы кешеләре турында сөйләгәндә зыялы шәхесләр, нәсел тамырлары Касыйм шәһәреннән булган Тенәкәчевләр турында да онытырга ярамый. Тарихтан шунысы мәгълүм: 1767 елда йөзбашлары Ибраһим Тенәкәчев һәм Мансур Сөбханколов Исет өязенең Эчкен волосте татарларыннан вәкил буларак, патшабикә Екатерина II нең чакыруы буенча, Мәскәүгә бара, анда «Уложенная комиссия»нең эшчәнлегенә катнаша.

Ибраһим Тенәкәчевнең улы Фазыл, Әлмән мәдрәсәсендә белем эстәгәннән соң, укуын Бәләбәй төбәгендә Габделваһаб бине Шәриф хозурында, ә аннары Каргалы һәм ерак Әфганстандагы Кабул мәдрәсәләрендә дәвам итә. Зур гыйлем туплап туган авылына кайткан Фазылны эчкен татарлары имам итеп сайлап куя. Аның турында Ризаэддин Фәхреддин менәниләр яза: *«Бу шәхес шул якның олуг затларыннан һәм ышанычлы галимнәреннән булып, Әбеннасыйр әл-Курсави фикерендә буларак, һәрвакыт аңа өстенлек биргән. Бохара шәһәренә илчелек сыйфаты илә барып, Истанбул вә Дагыстан тарафларында сәяхәт иткән. Ошбу вакытта хаҗ кылу бәхетенә дә иреште. Нәху, фикъһ, мантыйк, кәлям, гакаид, ысуле фикъһ, мәгънә һәм тәфсир фәннәреннән дәрес әйтеп, күпләргә гыйлем өйрәткән. Тройски, Кызылҗар төбәкләрендә вә Себердә күп мәртәбә сәяхәт итеп, сәфәр вакытларында үзе белән бергә шәкертләрен дә алып, һаман укыту һәм гыйлем тарату белән мәшгуль булган. Һәм йөргән җирләрендә, мөмкин булганда, шәкертләрен укыту өчен урнаштырып та калдырган. 1231/1816 елларда Тара ягына барып, гыйлем өйрәткән һәм шул тарафта булган галим-голәма берләшеп, дәресләр тыңлаганнар. Берникадәр вакыт шулай дәвам иткәч, Ибраһим бине Җәгъфәр атлы шәкертен дәрес әйтү өчен билгеләп, үзе асыл ватаны булган Әлмән авылына кайткан. Аның заманында Әлмәндә Габденнасыйр бине Сабит исемендә икенче бер галим вә мөдәррис булса да, бу тарафларда, күп сүзле, аз эшле халыклар булмагангамы, ни хикмәттер, аралары тәмам дуслык һәм ихтирам белән кичкән»*.

XIX гасыр башында Фазыл Тенәкәчев волостьның вәкаләтле заты булып сайлана, төбәкнең иҗтимагый мәсьәләләрен хәл итүгә үзеннән шактый өлеш кертә. Россия дәүләтенең махсус илчелеге составында, төрек солтаны белән килешер өчен Истанбулга, соңрак Бохара әмире янына бара. Тенәкәчевнең үтенече буенча, Чиләбе өяз идарәсе, «Эчкен волосте территориясе планы»н төзер өчен, җир үлчәүче җибәрә. Нәтиҗәдә, 1812 елда Эчкен волосте биләгән мәйдан үзгәртелә, чик буендагы бәхәсле мәсьәләләр хәл ителә.

Эчкен татарларының олы хөрмәткә ия шәхесе Фазыл Тенәкәчев 1826 елда 70 яшендә вафат була, Әлмән авылы зиратына җирләнә. Кызганыч, узган гасырның урталарында әлеге зират өстендә мәдәният һәм ял паркын оештыралар. Фазыл хаҗиның кабер ташы, җирдә берникадәр аунап ятканнан соң, Әлмән авылының «Дуслык» музеена алына һәм хәзерге көнгә кадәр шунда саклана. ■

КАЗАН СӨЛГЕСЕ

Татарстан Республикасы Милли музее фондыннан

«Казан сөлгесе»ндә татар чигү осталары эшләнмәләренең бар матурлыгы һәм милли үзенчәлеге тупланган.

Алтын җепләр белән чигелгән сөлге Сабан туенда ат чабышында беренче һәм иң соңгы килгән егеткә бирелә, яңа гына йортка төшкән яшь киләшне сөлгегә куелган «бал-май» белән каршы алалар. Бай татар йортларында матур орнаментлы сөлгеләрне Коръәнне төреп саклау өчен кулланганнар.

Казан сөлгеләре табигый ефәктән әзерләнгән, күпертеп, тоташтан, алтын белән чигеп бизәлгән. Чигү, гадәттә, яшел, сары, шәмәхә тукымаларга төшерелгән. Аны канитель ярдәмендә әйләнәсыман борылган юка алтын яки көмеш чигү энәләре ярдәмендә бормалы ефәк, йөгертелгән алтын яки йөгертелгән көмеш, бисер, энҗе белән чиккәннәр.

Ак ефәктә көмеш яки алтын җеп белән күпертеп чигелгән сөлгеләр аеруча матурлыгы белән дан казанган һәм чит төбәкләргә дә таралган.

Казан сөлгеләре милли сәнгатьнең символы булып тора, Казаныбызга килгән абруйлы кунакларны каршы алганда кулланыла.

Гүзәлия Җәләлева әзерләде. ■

Арча район хакимияте башлыгы Илшат Габделфәрт улы Нуриев чыгыш ясый. 2016 ел

Курсада – Курсавига мемориаль истәлек

Узган ел Арча районының Югары Курса авылында күренекле татар мәгърифәтчесе, галим, теолог Габденнасыйр Курсави (1776-1812) истәлегенә мемориаль такта ачылды. Бу күркәм эш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Таттелеком» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин җитәкчелегендә гамәлгә ашырылды.

Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин

Габденнасыйр әл Курсави (тулы исеме Әбүннасыйр-Габденнасыйр бине Ибраһим бине Ярмөхәммәд бине Иштирәк әл-Курсави) 1776 елда сәүдәгәр гаиләсендә дөньяга килгән.

Булачак галим башлангыч белемне Мәчкәрәдәге (Кукмара) Мөхәммәдрәхим ахуннан алган. Соңыннан Бохарага барып Ниязколый әт-Төрекмәни мәдрәсәсендә укыган. Аннан кайткач, Мәчкәрәдәге җизнәсе һәм аның уллары Гобәйдулла, Муса һәм Мөхәммәтҗан ярдәмендә зур мәдрәсә салдырып, шун-

да укыта башлаган. Шул ук вакытта Курсада имам-хатыйп вазифаларын да башкарган.

Габденнасыйр Курсави 1812 елда хаҗга дип чыгып киткән, барышлый ваба чире белән авырып, Истанбулда вафат булган һәм «Өскедар» зиратында күмелгән.

***

Югары Курса авылында Г.Курсави имамлык иткән мәчет саклана.

Икенче гильдияле сәүдәгәрләр – Муса, уллары Гобәйдулла һәм Габделкәрим (1813-1873) Апанаевлар акчасына XIX гасырның уртасында төзелгән. 1863 елда ике катлы, ике заллы, манаралы бу мәчет төньягыннан өч тәрәзә уемы озынлыгы зурайтыла. 1880 елда мәчеткә ремонт ясыйлар, түбә белән манараны яңарталар.

1930 нчы елларда манараны, әвәләп ясалган үсемле орнаментын вә заллар интерьеры элементларының полихром буяуларын юк итәләр.

Ядкярләргә – бер гасыр

Татарстан Республикасы Дәүләт архивы фондыннан

***

1917 елның 8 апреле

КАЗАН ГУБЕРНА КОМИССАРЫ МОЛОСТВОВНЫҢ ЧИСТАЙ ӨЯЗ КОМИССАРЫНА ТЕЛЕГРАММАСЫННАН

Җәмәгать куркынычсызлыгы губерна комитетының башкарма органы 19 мартта элекке губернаторның исерткеч эчемлекләр, ялган аракы һәм спиртлы сыекчалар җитештерүне, саклауны һәм башкаларга тапшыруны тыючы чараларын һәм карарларын көчендә калдыруны кирәк дип тапты... Аеклыкның халык арасында тәртип һәм тынычлык саклауда мөһим шарт икәнлеген танып, милициянең бөтен чиннарына алкоголь сатуда, җибәрүдә тәртип бозуларны һәм халыкка тыелган эчемлекләр эчертүне булдырмауны игътибар белән күзәтеп торырга кирәклеген сеңдерергә.

ТР ҮДА ТСД, ф.36, тас.1, э.147, 34б. Расланган күчермә.



КОПІЯ.

Почто-телеграмма
ЧИСТОПОЛЬ
Уѣздному Комиссару

Исполнительный Органъ Губернскаго Комитета Общественной безопасности 19 Марта призналъ необходимымъ оставить въ силѣ всѣ запретительныя мѣры и обязательныя постановленія бывшаго Губернатора въ отношеніи приготовленія, храненія, продажи и передачи крѣпкихъ напитковъ, суррогатовъ ихъ и спиртосодержащихъ веществъ, причемъ испрошены были по сему предмету указанія Министерства Внутреннихъ Дѣлъ, которое телеграммой № 112 сообщило, что принятіе необходимыхъ мѣръ, вызываемыхъ мѣстными условіями жизни въ предѣлахъ принадлежащихъ Губернатору власти всецѣло зависитъ отъ Губернскаго Комиссара и Комитетъ въ согласіи съ нимъ не только можетъ, но обязанъ всѣми мѣрами стремиться къ сохраненію порядка и безопасности.- Въ виду сего сообщаю, что обязательныя постановленія о крѣпкихъ напиткахъ и суррогатахъ, изданныя 26 Іюля 1916 года за № 8172 остаются въ силѣ, разсмотрѣніе и окончательное разрѣшеніе этихъ нарушеній въ предѣлахъ, указанныхъ въ томъ же постановленіи карательныхъ нормъ предоставляется уѣзднымъ комитетамъ общественной безопасности съ утвержденіемъ Уѣздныхъ Комиссаровъ.- Считая трезвость необходимымъ условіемъ для поддержанія порядка и спокойствія среди населенія, прошу внушить всѣмъ чинамъ милиціи самое внимательное наблюденіе за недопущенію нарушеній въ связи съ продажей, отпускомъ алкоголя и спаиваніемъ населенія запрещенными напитками.- 23 Марта 1917 года № 3075. Подлинную подписалъ Губернскій Комиссаръ Молоствовъ.-

Съ подлинной вѣрно:
Уѣздный Комиссаръ

Настоящую копію почто-телеграммы Г. Казанскаго Губернскаго Комиссара препровождаю въ Чистопольскій Уѣздный Комитетъ Общественной безопасности.-

Уѣздный Комиссаръ

№ 105

8 Апрѣля 1917 года.

***

1917 елның 9 апреле

ЧИСТАЙ ӨЯЗЕНЕҢ ЕГОРКИНО ВОЛОСТЬ КОМИТЕТЫ УТЫРЫШЫ БЕРКЕТМӘСЕННӘН КҮЧЕРМӘ

Рухани Романовның тантанада катнашмавы сәбәпле һәм аның элегрәк яңа дәүләт строена каршы законсыз гамәлләр кылуын искә алып, волость комитеты бертавыштан Романовны, кирәксез зат һәм иске режим тарафдары буларак, Егоркино волостеннан кууны сорарга дигән карар кабул итте.

Комитет рәисе имза

Сәркатип имза

ТР ҮДА ТСД, ф.36, тас.1, э.147, 37б.

Документлар урыс теленнән тәрҗемә ителеп бирелә.

Безнең мирас №4 апрель 2017


Вх. № 192.

Выписка
Изъ протокола засѣданiя Егоркинскаго Волостного Комитета отъ 9 апрѣля 1917 г. за № 1.

Въ виду отсутствiя священника Романова на торжествѣ и предыдущихъ его незаконныхъ дѣйствiй по отношенiю новаго Правительственнаго строя единогласно Волостной Комитетъ постановилъ просить, какъ лицо не желательное и сторонника стараго режима, удалить изъ предѣловъ Егоркинской вол.

Председатель Комитета

Секретарь Бурбашовъ

Чистай өязенең Егоркино волость комитеты утырышы беркетмәсеннән күчермә

***

1917 елның 9 апреле

ЧИСТАЙ ӨЯЗЕНЕҢ ЯҢА АДӘМ ҖӘМӘГАТЬ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК ВОЛОСТЬ КОМИТЕТЫ БЕРКЕТМӘСЕННӘН

...2 нче пункт.Дәүләт Думасы рәисе Родзянкога, Юстиция министры Керенскийга, Петроградтагы Эшче һәм солдат депутатлары советына котлау телеграммалары җибәрергә.

3 нче пункт. Ике заттан, бер урядниктан һәм бер атлы милиционердан торган милиция оештырырга, бу вазифаларга эшкә алуга хезмәттән гомерлеккә азат ителгән инвалидларга өстенлек бирергә...

ТР ҮДА ТСД, ф.36, тас.1, э.147, 30-31 б.
Расланган күчермә.

***

1917 елның 10 апреле

«РАБОЧИЙ» ГАЗЕТАСЫНДА (РСДРПНЫҢ КАЗАН КОМИТЕТЫ ОРГАНЫ) БАСЫЛГАН «ГОЛОС КРЕСТЬЯНСТВА» ДИГӘН МӘКАЛӘДӘН

Казан губернасының Собакино волосте Биектау авылының ирекле игенчеләре 5 апрельдә 120-150 кеше катнашында үткән җыенда революцион түнтәрелеш уңаеннан тулы канәгатьлек белдереп, бертавыштан карар кылдылар:

1. Россиядә демократик республика урнаштыруны таләп итәргә.
2. Вакытлы хөкүмәткә буйсынырга һәм аны эш-гамәлләре халык ихтыярыннан аерыла башлаганчы якларга...
3. Реформалар үткәрүне – җирне социалистик милеккә әйләндерүне таләп итәргә...
4. Бөтенроссия крестьян съезды һәм Учредительное собрание җыюга әзерлекне кичекмәстән башларга.
5. Гомумбелем бирүне һәм чиркәү мәктәпләрен юк итүне таләп итәргә.

Биектауда 5 апрельдә узган волость җыенында катнашкан крестьяннар А.Д.Керенскийга мондый эчтәлекле телеграмма җибәрергә карар кылалар:

«Казан губернасының Биектау крестьяннары, Россиядә үткәрелгән түнтәрелешкә тулы канәгатьлек белдереп, Вакытлы хөкүмәткә сәлам тапшыруны һәм аны эш-гамәлләре халык ихтыярыннан аерыла башлаганчы яклау турындагы карарларын җиткерүне сорыйлар.

Крестьяннар җибәрелгән 50 сум акчаны Сездән, иптәш Керенский, хәрби ихтыяҗларга тотуны сорыйлар».

ТР ҮДА ТСД, газеталар тупланмасы, №366.

Документларны басмага ТР Дәүләт архивы секторы мөдире
***Римма Садыйкова** әзерләде.* ■

E-mail: prm.archive@tatar.ru
www.arhiv.tatarstan.ru

«Кояш» газетасында **«Казан хәбәрләре»:** 1917 елның апрель ае

Сәхифәне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Мөселман приказчиклар карары

Кичә, көндез бер сәгатьтә Казандагы мөселман приказчик вә сәүдә хадимнәре бюросының җыелышы булып, түбәндәге резолюция чыгарылды. Мәҗлестә рус бәйрәмнәрендә ял итү мәсьәләсе мөзакәрә куелып, пасханың әүвәлге көнендә сату итү мәсьәләсе бәгъзе бер наразыйлыкка сәбәп булмасын өчен, күп мөзакәрәдән соң ачмаска һәм икенче көненнән иртәдән башлап һәммә кибетләрне ачарга вә моннан соң якшәмбе вә башка рус бәйрәмнәре урынына җомга вә башка мөселман бәйрәмнәрен итә башларга беравыздан карар чыгарылды. Шулай ук, гомуми сигез сәгать эш вакытын гамәлгә кую өчен, ризык вә ит кибетләрен ачу вә ябу сәгатьләре билгеләнгәнче, бөтен сәүдәгәрләрнең һәммәсенә иртә 9 сәгатьтән көндез бергә кадәр сату итәргә, бердән 3кә кадәр ашарга кайту өчен кибетләрен ябып, хидмәдкәрләрен азат кылырга һәм 3 сәгатьтән кич 7гә кадәр янә кибетләрен ачып, сәүдә кылырга гомуми карар бирелде. Бу карар Казандагы Гаскәри һәм рабочийлар шурасының гомуми карарына бинаән, беренче апрельдән башлап, закон куәтенә кереп, иҗраэ кылына башларга тиешле.

Мөселман социалистлар комитеты

Хәзердә дәвам итә торган төрле социалистлар партиясенең әгъзаларыннан Мөселман социалистлар комитеты тәшкил ителде. Комитетның максаты – эшче халык арасында социализм фикерен тарату вә шуның белән халыкны халык җөмһүриятен ясауга әзерләү.

Моның өчен мәзкүр комитет социализмга тәгаллекле рисаләләр [җыентыклар] таратачак, әгъзалары тарафыннан җәмгыятьләрдә шул тугрыда нотыклар сөйләнәчәк, революция аркасында алынган хөрриятне бетерергә тырышкан кара көчләр белән көрәшәчәк. Эшчеләр, шәкертләр, приказчиклар арасында югарыдагы фикерләрне тарату өчен түгәрәкләр ясалачак.

Кояш. – 1917. – №1100. – 2 апрель.

Фикер тарату курслары

Казан мөгаллимәләр вә мөслимәләр җәмгыяте, бергәләшеп, хатын-кызлар өчен «Фикер тарату курслары» ачарга карар бирде. Курсларның төп максаты – Казан вә әтрафындагы хатыннарны хәзерге хәл белән таныштырырлык вә Учредительное собраниегә сайлауларга хәзерләрлек ханымнар йитештерүдер. Уку 10 көн булачак.

Кояш. – 1917. – №1102. – 6 апрель.

Даталар иске стиль белән бирелә.

Матбага вә хәрефкә зур ихтыяҗ

Казанга төрле шәһәрләрдән, Төркестан вә Себер якларыннан матбагаларга вә хосусый кешеләргә хәреф сорап телеграммалар ява. Казандагы хәреф кою мәсьәләсе, кеше азлык вә әсбап юклык сәбәпле, бу таләпләрне үтәп бетерүдән гаҗиз. Идарәмезгә Төмәннән «Төмән мөхбире» дигән гәзитәнең 4 нче номеры килде. Гәзитә кечкенә генә кулда вә җилем матбагасында басылган. Алмата вә өязе мөселманнары җәмгыяте «Хитабнамә»сенең беренче нөсхәсе идарәмезгә тапшырылды. Бу «Хитабнамә» гәзитә рухында нәшер ителгән. Ташбасмада вә Казанда чыга торган гәзитәләр зурлыгында ясалган.

Кояш. – 1917. – №1105. – 13 апрель.

Мөселман бухгалтерлар вә конторщиклар бюросы

12 нче апрель, чәһәршәнбә көн 8 сәгатьтә «Болгар» залында мөселман бухгалтер вә конторщикларының икенче җыелышы булып үтте. Мәҗлестә каралган мәсьәләләр: әүвәл мәҗлеснең карары буенча сигез кешедән торган бюро тәшкил кылынды һәм мөселман социалистлары комитетына бер вәкил, мөселман приказчиклар бюросына бер вәкил һәм рус бухгалтер конторщиклар обществосының уставы комиссиясенә бер кеше сайланды. Мәҗлес өч сәгать дәвам итеп, сәгать унберләрдә таралды.

Кояш. – 1917. – №1106. – 16 апрель.

Мөселман хәрби комитетына

Төрле шәһәрләрдән вә сугыш мәйданыннан, татар полклары тәшкил итү фикеренә кушылганлыкларын белдереп, бик күп хат килмәктәдер. Шул ук йирләрдән хатлар ияләре, Казан мөселман хәрби комитетыннан организация эшләрен ничек юлга салырга кирәклеге хакында мәгълүмат бирүне һәм яңа агымга вә яңа хәлләргә даир матбугат йибәрүне үтенәләр.

Ярдәм банкысы

Апрель 16сында ачылган яңа Милли ярдәм банкының Проломныйдагы Докучаев йортында, Липанов квартирында 9 нчы гомуми җыены булып, беравыздан Кәлимулла Хөсәенов рәислеккә сайланып, шул банкының уставын тыңлап-карап чыгар өчен, ун кешедән комиссия сайланды. Шул ук мәҗлескә яңа әгъзалар килгәнлектән, җәмгысе, әүвәлгеләр берлә 80ләп әгъза булып, 6 мең сумлап пай акчасы булды. Хәзерге көндә һәр кешенең ошбу Милли ярдәм банкысына яхшы күз берлә каравына, Казанда игътибарлы сәүдәгәрләребезнең меңәр сум бирүләре шул ук мәҗлестә һәм бирергә вәгъдә бирүләре итсә кирәк. Әгъза Габдерахман Монасыйпов.

Кояш. – 1917. – №1107. – 18 апрель.

Солдатлар җомгасы

Өченчекөн, 21 нче апрельдә Казандагы һәммә мөселман гаскәрләренең беренче мәртәбә җыелышып «җомга укулары» булды. Гаскәрләрнең үзләренә мәсҗеде булмадыгыннан, мөселман гаскәрләренең бу җомгасы Юнысовлар мәйданында иҗраә кылынды. Җомгадан соң мәҗлескә мөнасиб рәвештә нотыклар сөйләнеп, гаять рухлы үтте.

Кояш. – 1917. – №1109. – 23 апрель. ■

Фотолар һәм видео **beznenmiras.ru** сайтында

● 3 нче мартта Яшел Үзән шәһәрендә Фаил Шәфигуллин исемендәге Төбәкне өйрәнү милли китапханәсендә укучылар белән очрашу булды. Очрашуда КФУ профессоры Флера Сәйфуллина, журналыбызның баш мөхәррир урынбасары Марат Закир, бүлек мөхәррире Ленар Гобәйдуллин һәм атаклы мәгърифәтчеләр Касыйм, Ибраһим Бикколовларны күреп белгән мөхтәрәм шәхес, 97 яшьлек Рауза апа Бикколова да катнашты.

● 15-16 мартта Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районында дин әһелләре һәм галимнәр катнашында уналтынчы мәртәбә «Кулаткы укулары» дип аталган фәнни-гамәли конференция уздырылды. Оештыручылар быел аны «Ана – бөек исем. Нәрсә җитә ана булуга?!» дип атаган.

● 17 мартта Казанның «Дуслык йорты»нда ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, аерым алганда «Идел» яшьләр үзәге тарафыннан мәктәп һәм урта һөнәри уку йортларында белем алучы укучылар арасында оештырылган «Дулкыннар» бәйгесенең Гала-концерты булды. Бу юлы ул Татарстанның халык шагыйре, «Безнең мирас» журналының киңәшче идарәсе әгъзасы Разил Вәлиев иҗатына багышланды. Әлеге күркәм чарада «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон һәм баш мөхәррир урынбасары Марат Закир катнашты.

● 17 мартта Казандагы 17 нче татар гимназиясендә Галимҗан Ибраһимовның тууына 130 ел тулу уңаеннан VIII республикакүләм фәнни-гамәли конференциясе үткәрелде. Чарада «Безнең мирас» журналы хезмәткәре, драматург Рәдиф Сәгъди катнашты.

● 18 мартта Кремльдә ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин бер төркем татарстанлыларга бүләкләр тапшырды. Бүләкләнүчеләр арасында «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон да бар иде.

● 21 мартта Буа районының Яңа Чәчкап урта мәктәбендә Г.Исхакый премиясе лауреаты, шагыйрь Әхмәт Рәшит исемендәге «Кояшлы ил» II республикакүләм фәнни-гамәли конференциясе уздырылды. Язучылар һәм шагыйрьләр (Рифат

Җамал, Рифат Сәлах, Гөлнур Айзатуллова һ.б.) катнашында узган әлеге җыенда «Безнең мирас» журналының баш мөхәррир урынбасары Марат Закир чыгыш ясады.

● 22 мартта Франциянең Тулуза шәһәрендә Татарстан һәм татарларга багышланган «Окситания һәм Татарстан» дигән чара узды. Әлеге очрашуның максаты – французларга гаҗәеп бай татар дөньясын таныту. «Татар теле ике миллион кеше генә сөйләшкән окситан теле хәленә калмасын иде», – ди чараны оештыручы Инера Сәфәргалиева (Рәсемдә: Инера ханым бөек вулканолог һарун Таҗиевның улы Фредерик Лавашри белән). Парижда яшәүче авторыбызның «Вулкан серен ачкан татар» язмасы белән «Безнең мирас»ның 2014 елгы 4 нче санында һәм www.beznenmiras.ru сайтында таныша аласыз.

● 23 мартта бертөркем әдипләр һәм журналистлар Арча районының Мирҗәм һәм Апаз авылларында булды. Арча төбәге язучылары җитәкчесе, шагыйрь Рифат Җамал оештырган әлеге очрашу-чарада Ринат Мөхәммәдиев, Фоат Галимуллин, Ркаил Зәйдулла, Алмаз Хәмзин, Вакыйф Нуриев, «Безнең мирас» журналы һәм «Безнең гәҗит» газетасы баш мөхәррирләре Ләбиб Лерон белән Илфат Фәйзрахманов чыгыш ясады.

● 24 мартта «Казан» милли-мәдәни үзәгендә, I Бөтенроссия татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр корылтае кысаларында, «Золотая орда в мировой истории» китабын тәкъдим итү кичәсе булды. Әлеге монографик хезмәтне Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының М.Госманов исемендәге Алтын Урданы һәм татар ханнарын өйрәнү үзәге белгечләре әзерләгән.



● 24 мартта «Казан» милли-мәдәни үзәгендә үткәрелгән I Бөтенроссия татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр (краеведлар) корылтаенда «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре Л.Лерон, М.Закир, Д.Нәүрузова һәм Л.Гобәйдуллин татар халкы, Татарстан тарихы һәм мәдәниятен пропагандалаганы өчен Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры Р.С.Хәкимов тарафыннан дипломнар белән бүләкләнде.

ДИПЛОМ

награждается

Губайдуллин Ленар Ильгизович

за активный вклад в деле пропаганды истории и культуры татарского народа и Татарстана, в рамках 25-летнего юбилея журнала «Безнең мирас».

Директор Института истории им. Ш.Марджани, академик АН РТ — Р.С.Хакимов

г. Казань, октябрь 2016 г.

Каһкаһәле өч мәзәк һәм бер парча

Габдулла Тукай

АКЫЛЛЫ БАШЛАР
(Өзек)

Бер татар прикашчигы: – Тамчы, тамчы тамар да күл булыр, – дип әйтте дә, ди, байның кассасын аз-азлап чиертергә тотынды, ди. Күп тә үтмичә, самавырчы малайлыктан «Печән базары бае»лыкка тәррәкъкый итте, ди.

Бер татар бае: – Асылынсаң асылын агачның асылына, – дип әйтте дә, ди, Мәскәүгә барып, йөз меңлек бурычка чумды, ди; шул елда ук шарт итте, ди.

Бер татар кызы: – Гыйшык тоту пигамбәрләрдән калган, – дип әйтте дә, ди, урамнан узган бер кәкре шәкерткә «гыйшык» булды, ди.

«Ялт-йолт», №6, 1 июнь, 1910 ел.

ИР, ХАТЫН

Әгәр ир башмакчы, йә кәвешче булса – ул хатыны табаны астына ятыр.

Әгәр ир гармунчы, йә скрипкәче булса – хатыны дудкасына биер.

Әгәр ир сәгатьче булса – хатыны бору белән генә йөрер.

Әгәр ир шагыйрь булса – хатыны диктовкасы белән генә язар.

Әгәр ир мулла булса – хатыны юллаган мәсьәләне генә юллар.

Әгәр ир солдат булса – хатыны кушканча гына маршавайт итәр.

Әгәр ир тирече булса – хатыны өчен үз тиресен дә базарга чыгарыр.

Әгәр ир ишан булса – хатыны кушкан төшләрне генә күрер.

Әгәр ир мөрид булса – хатыны төреп биргән акчаны гына ишанга илтер.

Әгәр ир озын колаклы яки озын борынлы булса – хатыны колагыннан яки борынынннан өстерәве белән генә йөрер.

«Ялт-йолт», №27,
1 сентябрь, 1911 ел.

КӨЛЕП ЯЗМЫЙБЫЗ, КӨЛЕП ӘЙТМИБЕЗ

Без «Ялт-йолт»та: «Зингер маржасының башын кырган өчен «Дин-мәгыйшәт» мөхәррире Вәли муллага: «Падсуд пайдуш!» – дисәк, көлеп әйтәбез.

Без «Ялт-йолт»та: «Бәянел-хак» мөхәррирләренең русчадан тәрҗемәләре ни төсле икәнен язып, «поднос» – «борын асты», – дисәк, көлеп әйтәбез.

Без «Ялт-йолт»та: «Чабаксар губернасы, Петербург өязеннән берәү хат язып, бездән мәсьәлә сорый», – дисәк, көлеп әйтәбез.

Без «Ялт-йолт»та: «Печән базар халкы итальяннар белән сугыша», – дип әйтсәк, көлеп әйтәбез.

Әгәр дә без «Ялт-йолт»та: «Журналымыз 15 көндә бер чыга. Бәһасе җылына 3 сум, ярты җылга тәнкә ярым, өч айга бер сум. Шул хакка алыңыз. Сезгә дә җәбер, безгә дә золым булмас дисәк», – көлеп әйтмибез.

«Ялт-йолт», №36, 31 март, 1912 ел.

Хаҗиморат Казаков. «Бәләкәй Апуш»

Хаҗиморат Казаков. «Автопортрет»



АПУШ БӘРӘҢГЕСЕ

Госман Гомәр

Морзалар нәселеннән килгән, заманында берничә сәнгать академиясендә белем алган рәссам Хаҗиморат Казаков Бауман һәм Кави Нәҗми урамнары чатындагы йортның икенче катында, бер тәрәзәле тар гына бүлмәдә яшәде. Гаҗәеп тыйнак, зыялы бер зат иде. Иҗаты тирән эчтәлекле, гаять үзенчәлекле. Ул, нигездә, татар халкының күренекле шәхесләрен тасвирларга, аларны киләчәк буыннарга җиткерергә омтылды. Рәссамның шагыйрьгә багышланган «Бәләкәй Апуш» картинасы тиз арада киң җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итте. Анда «Үксез бала»ның (картинаның икенче исеме шулай иде) фаҗигасе сурәтләнә, ул тирән психологик уйлануларга этәрә, бәгыреңне телеп-телеп ала. Соңыннан рәссам туганнан туган абыйсы, революционер Мулланур Вахитов портретларын ясады.

Мин бүлмәнең тарлыгына гаҗәпләнә идем. Оста үзе дә очын очка ялгап кына яши икән. Уңайсызланып, «Үксез бала» картинасына ишарәләп:

– Менә соңгы өч бәрәңгемне кечкенә Апушка бирдем әле, – диде.

Шундый тарлыкта яшәгән бөек рәссамның юмартлыгына сокландым... ■

Бакый Урманче һәйкәле. Казан. Сынчы – Мәхмүт Гасыймов. 1997 ел

«Безнең мирас»
елъязмасы / апрель

• 635 ел элек (1382)

Алтын Урда ханы Туктамыш Мәскәүне яулап алу сәфәренә кузгала.

• 235 ел элек (1782)

Шагыйрь, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Әбделмәних Каргалый (1782-1833) дөньяга килә.

• 95 ел элек (1922)

27 апрельдә Казанның Юнысовлар мәйданында Мулланур Вахитовка һәйкәл куела.

• 90 ел элек (1927)

20 апрельдә Шәриф Камалның «Таң атканда» романы китап булып басылып чыга.

• 85 ел элек (1932)

15 апрельдә Татар дәүләт академия театры Кәрим Тинчуринның «Кандыр буе» исемле яңа пьесасын сәхнәгә чыгара.

• 70 ел элек (1947)

22 апрельдә СССР Министрлар Советы каршындагы әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Ленин премияләре комитетының карары «Правда» газетасында басыла. Әлеге карар нигезендә «Моабит дәфтәрләре» өчен шагыйрь Муса Җәлил Ленин премиясенә лаек була.

• 60 ел элек (1957)

12 апрельдә шагыйрә, милләтпәрвәр җәмәгать эшлеклесе Сания Гыйффәт (1899-1957) Анкара шәһәрендә йөрәк авыруыннан вафат була.

• 50 ел элек (1967)

26 апрельдә күренекле рәссам Бакый Урманчега Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә.

Румыниядә Шукран Вуан-Мокану тәрҗемәсендә Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы румын телендә китап булып нәшер ителә.

• 45 ел элек (1972)

ТАССР Дәүләт музеенда татар әдәбияты бүлеге ачыла. ■

Мирасворд



Бармак киңлегенә тигез үлчәү берәмлеге

Драма-тург ... Шәкүров

Дүрттән бер өлеш, чирек; элекке авырлык, җир үлчәү берәмлеге

Алла тарафыннан пәйгамбәр күңеленә салынган фикер, хәбәр

Гарәп артикле

Язучы Рафаэль ...

Камытның ат муенына һәм түшенә тиеп торган аскы өлеше

Чыңгыз ханның законнар җыелмасы

Драма-тург ... Вахит

Мәҗнүн-нең сөйгәне

Тагын, яңадан

Башкорт телендә чыгучы юмор-сатира журналы

Уфада һәм Ульянов-скида татар телендә чыгучы газета

Шагыйрь ... Садә

Язучы ... Рәфыйков

Тел очына чыга

Соры корт (диал.)

Бүләк (иск.)

Җырларга кергән елга

... Исәнбәт

Дәүләт эшлеклесе, ТАССР Югары Советы Президиумы рәисе (1960-83)

Хат, записка (иск.)

Фәридет-дин ... (фарсы шагыйре)

... Скала (Милан опера театры)

Тәлгат Га-лиуллин романы

Коръән сүрәсендә тәмамланган шигъри җөмлә

Күренекле рус шагыйре

1930-1932 елларда Казанда чыккан әдәби-сәяси журнал

Казандагы бистә

Грециядәге тарихи өлкә

Кыл кебек тупас, тырпаеп торган чәч

Идел буе Болгары шәһәре

Елгада бик тирән урын, упкын, чоңгыл

Гурген ... (әрмән әдибе)

Борынгы грек скульпто-ры

Сәгыйть ... (башкорт әдибе)

Артыклык, өстенлек, яхшы хо-лыклылык (иск.)

Граж-даннар сугышы герое

... Зөлкарнәй

Шагыйрь Әнәс ...

... Гыйззәт

3 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Судан уңга: Раев, ап, саба, ички, Рәхмәт, мәте, шава, Хөсрәү, Гален, драм, «Ант», Әсма, Руа, Әй, «Уфтанма», өн, угыз, артак, би, тума, онта, абаз, ыра, аткы, әзи.

Өстән аска: Рахманкулова, хәситә, Хисам, йөзбашы, әбәдә, Рабит, Үрсу, Апач, амфора, тамга, Вәлиева, арата, талкан, кубыз, эму, мари, манара, наза.

Рәис Габдулла төзеде.

СОДЕРЖАНИЕ. АПРЕЛЬ 2017

Историческое наследие: «Странники» А.Мухаммадиев; «На пути сохранения высокой культуры: Габдельбари хазрат Исаев» А.Бустанов; «Полярная звезда исламского мира» Х.Валиахматов; «История деревни Атрач» Э.Салахова; положение творческого и научно-исследовательского конкурса «МОЯ ДЕРЕВНЯ»; «Татарские пленные в Финляндии» Ч.Сафиулла.

Религиозное наследие: «Исламский мир» Абдурашит Ибрагимов.

Литературное наследие: «Кутадгу билик» («Благодатное знание») Ю.Баласагуни; «Белое облако Чингизхана» Ч.Айтматов; «Голоса из могил» Х.Ушаклыгуль; «Есть большая надежда на развитие науки Тукая» Р.Рахман; «Жизнь, посвящённая будущим рассветам» Ф.Сайфулина.

В глубине памяти: «Сок горького яблока на устах...» М.Талипова.

Культурное наследие: «Тоска» Р.Шагиева; «Апастово – края курая» Э.Каюмова.

Слово – украшение языка: «Словарь национальных терминов» А.Тимергалин; «Умеем ли мы писать правильно?» Г.Баширов.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT

Historic heritage: «The pilgrims» by A.Mukhammadiev; «On the way of keeping high culture: Gabdelbari khazrat Isaev» by A.Bustanov; «The Polaris of the Islamic world» by Kh. Valiakhmatov; «The history of Atrach village» by E.Salakhova; thesis of creative scientific research competition «MY VILLAGE»; «The Tatar captives in Finland» by Ch. Safiulla.

Religious heritage: «The Islamic world» by Abdurashit Ibragimov.

Literary heritage: «Kutadgu bilik» («The blessed knowledge») by U. Balasaguni; «The white cloud of Genghis Khan» by Ch. Aytmatov; «The voices from graves» by Kh.Ushakligul; «There is a big hope on the Tukay's science developing» by R.Rakhman; «The life devoted to dawns » by F.Sayfulla.

From the deepest of memory: «Blood of bitter-tasted apple is on the lips ...» by M.Talipova.

Creative heritage: «Melancholy» by R. Shagieva; «Apastavo is a home of kuray» by E. Kayumova.

Word is a language's decoration: «Dictionary of national terms» by A.Timergalin; «Can we possess an accurate writing?» by G.Bashirov.

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation life.

Бакый Урманче.
«Биби ханым». 1952
Кәгазь, акварель

АЛДАГЫ САННАРДА УКЫГЫЗ:

- Оренбург казак гаскәриләре төркемендә нугайлар. Рөстәм Әминов
- Көйле иман. Шәмсетдин Күлтәси
- Тәзкирә (Кышкар мәдрәсәсе турында истәлекләр). Әхмәдвәли Мәңгәри
- «Рекрут итеп алдылар да...». Айдар Казаков
- Куркыныч һәм хәвефле еллар. Индус Таһиров
- Әтнә төбәгенең ташъязма истәлекләре. Раиф Мәрданов, Ирек Һадиев
- Урманасты Үтәмеш авылы тарихы. Фәйзелхак Ислаев
- Агуланган Мәрьям бәете. Индус Сирматов
- Себер киңлекләре ядкярләре. Фәнзилә Җәүһәрова, Гафур Сөнгатов
- Риваятькә лаек гомер. Илдус Фазлетдинов
- Кошлар өрекмәгән җирдә. Шәйхи Маннур
- Атилла Расихның туганы Хавис. Мөҗәһит Әхмәтҗанов
- ГУЛАГ тоткыны Ибраһим Салахов. Госман Гомәр
- Әбрар Кәримуллин хатлары

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
- *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман ур., 19; 29/11) кибетеннән, «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.